Ф.Ф. Исламов, Ә.М. Закирҗанов

Татар әдәбияты

5



Татар әдәбияты
5

Фәйзерахман Әминов. Тукай.

Фәйзерахман Әминов. Кырлай.

Ф. Ф. ИСЛАМОВ, Ә. М. ЗАКИРҖАНОВ

Татар әдәбияты

Рус телендә
урта гомуми белем бирүче мәктәпнең
5 нче сыйныфы өчен дәреслек
(татар балалары өчен)

Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы рөхсәте белән басыла

КАЗАН
«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 373.167.1:821.512.145*05
ББК 84(2Рос=Тат) я721
И80

Дәреслекнең *Татар халык авыз иҗаты*, *Мәҗит Гафури*, *Галимҗан Ибраһимов* бүлекләрен Ә. М. Закирҗанов, калган бүлекләрен Ф. Ф. Исламов язды.

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или её части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

Исламов Ф. Ф.

И80 Татар әдәбияты: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәкт. 5 нче с-фы өчен д-лек (татар балалары өчен)/ Ф. Ф. Исламов, Ә. М. Закирҗанов.— Яңадан эшләнгән 3 нче басма.— Казан: Мәгариф, 2004.— 223 б.
ISBN 5-7761-0879-9

БЗ 9(68) — 15 — 2002/2003

ISBN 5-7761-0879-9
© Исламов Ф. Ф., Закирҗанов Ә. М., 1998
© «Мәгариф» нәшрияты, 2004, үзгәрешләр белән

КАДЕРЛЕ БАЛАЛАР!

Сез 5 нче сыйныфтан башлап татар язучыларының тормышы һәм иҗаты белән шактый киң күләмдә һәм билгеле бер эзлеклелектә таныша башлыйсыз. Уку елы дәвамында, халык авыз иҗаты һәм аерым чорларда яшәп иҗат иткән әдипләрнең төрле жанрдагы әсәрләрен укып, халкыбызның бай рухи мирасын өйрәнерсез.

Әдәбият ул тормышны, иҗтимагый чынбарлыкны чагылдыра. Әдәби әсәрләрдә тормыш җанлы образлар, аларның яшәеше, уй-фикерләре, хисләре аша күрсәтелә. Без, ул әсәрләрне укыганда, андагы геройлар белән бергә шатланабыз, борчылабыз, тасвирланган вакыйгалар турында уйланабыз.

Сезнең кулыгыздагы дәреслеккә туплап бирелгән әсәрләр, әдипләр турындагы биографик мәгълүматлар, сөйләм телен үстерү максатында бирелгән сөйләшү темалары — барысы да белемегезне арттырырга, эстетик зәвыгыгызны баетырга ярдәм итәр дип уйлыйбыз. Татар сәнгатенең күренекле вәкилләре белән якыннан танышу да матурлыкны күрә белүгә, халкыбызның көй-моңын, рәсем һәм театр сәнгатен аңлауга нигез булып тора. Ә инде әкиятләр, табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр сезгә акыллы, тапкыр булырга, туган телебезнең образлылыгын, нәфислеген тоярга, фикерегезне тулы һәм ачык итеп әйтергә ярдәм итәр.

Республикабызда балалар өчен татар телендә чыгып килүче газета-журналлар, матур әдәбият китаплары, русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр дә сезнең якын дусларыгызга әверелсеннәр иде.

Хәерле юлга, кадерле дуслар!

ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

Аерым кешеләр тарафыннан иҗат ителеп, телдән телгә күчеп йөрү дәверендә төрле үзгәрешләргә дучар булган һәм шул рәвешле күмәк иҗат җимешенә әверелгән әсәрләр җыелмасы *халык авыз иҗаты* (фольклор) дип атала. Халык тормышындагы вакыйга-күренешкә, шатлык-куанычка, кайгы-хәсрәткә, теләк-омтылышка бәйле рәвештә, алар бик борынгы заманнарда барлыкка килгәннәр һәм язма әдәбиятның җирлеге булып торганнар. Гасырлар дәвамында татар халык авыз иҗатында төрле жанрлар: әкиятләр, җырлар, ырым, мәкаль-әйтем, табышмак, мәзәк, бәет, мөнәҗәт, легенда, риваять, эпос-дастаннар формалашкан.

Башлангыч сыйныфларда сез халык авыз иҗатының кайбер үрнәкләре белән танышкан идегез. Бишенче сыйныфта исә әкият, мәкаль, әйтем һәм табышмаклар турында тулырак мәгълүмат алырсыз.

ӘКИЯТЛӘР ТУРЫНДА

Халык авыз иҗаты әсәрләренең киң таралган һәм мавыктыргыч төрләреннән берсе — әкиятләр. Аларның нигезендә халыкның тормыш тәҗрибәсеннән туган зирәклеге, тапкырлыгы, өмет-хыяллары чагылыш тапкан уйдырма ята. Әкиятләрдә начарлык, явызлык гаепләнә, гаделлек, дөреслек яклана. Уңай геройлар идеаллаштырып бирелә һәм һәрвакыт, явызлыкны җиңеп чыгып, үз теләкләренә ирешә. Эчтәлекләренә карап әкиятләрне өч төргә бүлеп йөртәләр: *хайваннар турындагы әкиятләр, тылсымлы әкиятләр* һәм *көнкүреш әкиятләре.*

Хайваннар турындагы әкиятләр әкият жанрының иң борынгысы дип санала. Аларның төп геройлары — төрле кош-корт, киек-җәнлек, кыргый һәм йорт хайваннары. Мәсәлән, «Хәйләкәр төлке», «Шәрә бүре», «Әтәч патша» һәм башка әкиятләр шундыйлардан.

Тылсымлы әкиятләрдә чиксез бай фантазиягә корылган мажаралы вакыйгалар сурәтләнә. «Ак бүре», «Таңбатыр», «Алтын алма» кебек әкиятләрнең геройлары төрле серле әйберләр, хикмәтле көчләр ярдәмендә гаҗәеп эшләр башкаралар: җиде кат җир астына төшәләр, күз ачып йомганчы кара урманнар, океаннар аша үтеп чыгалар, бер төн эчендә гүзәл сарайлар салып куялар яки коточкыч аждаһаларга, диюләргә каршы сугышып җиңеп чыгалар.

Тормыш-көнкүреш әкиятләре халыкның көндәлек тормышына караган вакыйгаларга нигезләнә. «Шомбай», «Саран һәм Юмарт», «Солдат балтасы» һәм башка шундый әкиятләр күләм ягыннан кыска булып, аларда серлелек, арттыру, тылсым кебек алымнарга киң урын бирелми. Бу төр әкиятләрдә халыкның яшәешкә бәйле карашлары, уй-теләкләре чагыла.

Халык иҗаты традицияләрен файдаланып, әкиятләрне аерым язучылар да иҗат итә. Сезнең Г. Тукайның «Кәҗә белән Сарык», А. Алишның «Сертотмас үрдәк», Н. Исәнбәтнең «Мыраубай батыр» әкиятләрен укыганыгыз бардыр. Бу төр әкиятләрне *әдәби әкиятләр* дип йөртәләр.

ЗИРӘК КАРТ

(татар халык әкияте)

Элек заманда булган, ди, бер явыз патша. Ул җитмеш яшькә җиткән кешеләрне, «барыбер эшкә ярамыйлар» дип, үтертә торган булган, ди. Бер егетнең булган җитмеш яшьлек атасы. Бу егетнең атасын бер дә үтертәсе килмәгән, ди. Ул аны байтак вакытлар яшереп асраган, ди.

Егет көн саен атасы янына керә икән. Атасы моннан:

— Нихәл, улым, дөньяда ниләр бар? — дип сорый икән.

Егет күргәнен-ишеткәнен барын да сөйләп бирә икән.

Шулай беркөнне егет урамнан кайткан да әтисе янына кергән.

— Нәрсәләр күрдең, улым, ниләр ишеттең? — дигән әтисе.

— Әти,— дигән егет,— патша үзенең вәзирләре белән су буена төшкән. Су төбендә җем-җем итеп гәүһәр ялтырый. Шуны су төбенә төшеп эзлиләр — таба алмыйлар, менгәч карыйлар, тагын су төбендә ялт итеп күренеп тора. Шуңарга бик аптырадылар. Патшаның вәзирләре дә моның хикмәтен белә алмадылар,— дигән.

— Әй улым,— дигән карт,— анда берәр агач үсеп утырмыймы соң?

— Бер өянке үсеп утыра анда, гәүһәрне шуның тирәсеннән эзлиләр дә инде,— дигән егет.

— Өянке башында кош оясы да бармы?

— Бар.

Шуннан әтисе әйткән:

— Алайса, ул гәүһәр кош оясындадыр. Суга шуның шәүләсе төшкән булыр,— дигән.

Иртәгесен патша кешеләре яңадан су буена баралар. Карасалар, күрәләр болар, гәүһәр су төбендә җем-җем ялтырап ята, боларның суга чумулары була — гәүһәр тагын юкка чыга. Таба алмыйча, тагын аптырап кайтып китәләр. Болар таба алмагач, егет патша янына бара да әйтә:

— Падишаһым-солтаным, бер сүз сөйләр идем мин сиңа,— ди.— Бу гәүһәр су төбендә түгелдер, су буенда өянке бар, өянке башында оя бар, шул ояда булырга кирәк, шуны менеп карыйк әле,— ди.

Патшаның менүчеләре күп була, тиз генә агач башына менеп китәләр дә каз йомыркасы кадәр гәүһәрне алып та төшәләр. Патшаның исе китә моңарга. Вәзирләрен бик орыша инде бу:

— Үзегез укыган кешеләр, үзегезнең шул авыл малае кадәр дә акылыгыз юк,— ди.

Ә егеттән сорый:

— Моны сиңа кем өйрәтте? — ди.

— Үзем белдем,— ди егет.

Вәзирләрнең бу егеткә бик ачулары килә. Егет алардан өстен булып чыкты бит инде. Хәзер вәзирләр, егет өстеннән патшага әләкләп, аны ничек булса да үтертмәкче булалар. Патшага барып әйтәләр.

— Ул,— диләр,— миңа нәрсә күрсәтсәләр дә беләм, дип әйтә. Без аңа ике айгыр күрсәтик. Икесе дә бертөсле, икесе дә бертигез булсын. Авызларын да ачып карамасын, яннарына да килмәсен, кайсы карт, кайсы яшь икәнлеген читтән торып кына әйтсен ул егет,— диләр.

— Ярый,— ди патша. Шуннан соң егетне чакыртып ала да әйтә: — Иртәгә килерсең, без сиңа шундый-шундый ике айгыр күрсәтербез, син шуларның кайсысы карт, кайсысы яшь икәнлеген аерып күрсәтерсең,— ди. Егет бик кайгырып, «ярар» дип кайтып китә. Кайткач, атасы янына керә.

— Улым, нихәл? — ди атасы.

— Әти,— ди бу,— гәүһәр, син әйткәнчә, кош оясында булган,— ди.— Тик патша миңа бүген тагын шундый-шундый мәсьәлә бирде бит әле,— ди.

— Әй улым,— ди атасы,— аның өчен хәсрәтләнмә, ул бер ни түгел,— ди.— Иртәгә барырсың, яшь айгыр ерактан ук тузгып, уйнаклап килер, ә карт айгыр, башын борып, яшь айгырга юл биреп китәр,— ди.

Егет иртүк торып бара. Вәзирләре белән патша да килә. Болар ике айгыр китерәләр, икесе дә бертөсле, икесе дә бертигез.

— Моның кайсысы карт, кайсысы яшь? — диләр егеткә.

Ике айгыр ике яктан кара-каршы киләләр. Яшь айгыр әллә кайдан тузгып, уйнаклап килә, карт айгыр башын иеп кенә уза.

Егет әйтә:

— Менә бусы карт айгыр, бусы яшь айгыр,— ди.

Бу егет моны да белде бит инде. Хәзер икенче көнгә моңа тагын бер мәсьәлә хәстәрлиләр дә:

— Шушы агачларның кайсы башы оч, кайсы башы төп була, шуны бел,— диләр.

Егет бик хәсрәтләнеп кенә кайтып китә. Кайткач, тагын әтисе янына керә.

— Улым, бүген ниләр күрдең? — ди карт.

— Әти,— ди егет,— айгырны белдем, син әйткәнчә булды,— ди.— Миңа тагын мәсьәлә биреп җибәрделәр бит,— ди.— Бертигез юнылган ике агач, тышыннан бернәрсәсе дә беленми, шуның кайсы башы оч, кайсы башы төп икәнен белергә кушалар,— ди.

— Әй улым, кайгырма юкка,— ди атасы.— Син агачларны суга салырга куш. Суга салгач, оч башы өскә калкыбрак, төп башы төпкә батыбрак торыр,— ди.

Иртәгесен егет торып китә. Барып керә. Моңа шоп-шома итеп юнылган ике агачны әзерләп тә куйганнар.

— Менә сиңа ике бүрәнә, юнып та карама, күтәрмә дә, кайсы башы оч, кайсы башы төп икәнен болай гына бел,— диләр.

Егет:

— Суга салып карагыз әле,— ди.

Суга салалар, бүрәнәләрнең бер башы бата, икенче башы өскә калка.

Егет әйтә:

— Менә бу башы оч, бусы төп була,— ди.

Тагын белде бит инде бу. Патша бик гаҗәпләнә моңа. Гаҗәпләнә дә егеттән сорый:

— Моны сиңа кем өйрәтте? — ди.

Егет әйтә:

— Үзем белдем,— ди.

— Юк, син әле моны белерлек түгел, яхшылык белән әйтмәсәң, мин сине астырам,— ди патша.

Егет әйтмичә булдыра алмый:

— Минем җитмеш яшьлек әтием бар, мин аны үтертмичә яшереп асрыйм, миңа шул акыл бирә,— ди.

Шуннан соң патша әйтә:

— Яхшы, дөньяда картлар да кирәк икән, картлардан башка дөнья бармый икән. Моннан соң картларга тимәскә,— ди.

зирәк — тапкыр
гәүһәр — асыл таш
хикмәте — *монда:* сере (бу эшнең сере)
тузгып, уйнаклап — бик җитез, җиңел атлап
хәстәрлиләр — әзерлиләр
калкыбрак — күренебрәк, өскә чыгыбрак
батыбрак — *монда:* су өслегеннән түбәнрәк төшеп
хәсрәтләнмә — кайгырма

Сораулар һәм биремнәр

1. Әкиятне рольләргә бүлеп укыгыз.
2. Бу әкият нинди төр әкиятләргә керә? Ни өчен?
3. Түбәндәге сүзләрнең, сүзтезмәләрнең мәгънәләрен ачыклагыз һәм дөрес әйтергә өйрәнегез: *барыбер эшкә ярамыйлар, дөнья, күргәнен-ишеткәнен, падишаһым-солтаным, әләкләп.*
4. Охшаш вакыйгаларны табыгыз, үз эчендәге каршылыкларны билгеләгез.
5. Әкиятне каршы якларга бүлегез, һәрберсенә бәя бирегез.
6. Патшаның баштагы фикере үзгәрә. Ни өчен?

Әкиятнең эчтәлеге белән яхшылап танышканнан соң, аны анализлауга керешәбез. Фольклор һәм язма әдәбият әсәрләрендә ниндидер тормыш материалы алына һәм вакыйга-күренешләргә бәйле билгеле бер фикер үткәрелә, нәрсәдер яклана, нәрсәдер тәнкыйтьләнә. Әлеге әкият тә үзенчәлекле төзелешкә ия. Анда вакыйга-хәлләр, образ-геройлар бирелә, алар төрле бәйләнеш-каршылыкка керә. Ахырда исә бер нәтиҗәгә китерелә. «Анализ» төшенчәсе әкиятнең төрле өлешләрен аерып чыгаруны, аларны тикшереп бәяләүне һәм нәтиҗә ясауны аңлата. 4, 5, 6 нчы сорау-биремнәргә җавап рәвешендә бергәләп анализ ясыйк.

4 нче биремгә җавап. Әкияттә бер-берсенә охшаган өч вакыйга бирелә. Беренчесендә патша вәзирләре су төбендә ялтыраган гәүһәрне таба алмыйлар, ә егет әйтеп бирә, икенчесендә вәзирләр аны ике айгыр күрсәтеп сыныйлар, егет кайсы карт, кайсы яшь икәнлеген аерып бирә, өченчесендә егет тигез итеп юнылган агачның кайсы башы оч, кайсы башы төп булуын күрсәтә. Һәрбер вакыйгада егет вәзирләр белән каршылыкка

керә һәм тапкырлыкта сынала. Ул аларны уңышлы үтеп, җиңеп чыга.

5 нче биремгә җавап. Хәзер инде әкиятне каршы якларга аерабыз. Бер якта вәзирләр һәм алар артында торган патша, икенче якта егет һәм аның артында торган карт әтисе. Вәзирләр тәҗрибәсез, аларга осталык, акыл җитми, шуңа да егеттән көнләшәләр. Егетнең әтисе — тәҗрибәле, акыллы карт. Улы аның ярдәмендә тапкырлык, зирәклек күрсәтә.

6 нчы сорауга җавап. Башта патша җитмеш яшькә җиткән кешеләрне үтерергә дигән карар чыгара, соңыннан исә бу фикерен үзгәртә. Ул тормышта зирәклек чыганагы булган акылның тормыш тәҗрибәсе белән килүен аңлый. Шул рәвешле **кеше акылы** зурлана.

ҖИЛ АРБА

(татар халык әкияте)

Борын-борын заманда җиде тауның артында, җиде суның янында, җиде юлның чатында яшәгән, ди, бер карт белән карчык.

Болар үз кул көчләре белән гомер иткәннәр. Берәүгә дә тимәгәннәр, берәүгә дә усал сүз әйтмәгәннәр. Йомыш белән килгәннәрне кире борып чыгармаганнар, ялган сүз сөйләмәгәннәр, булдыра алмаслык эшкә керешмәгәннәр, шуның өчен аларны һәммә кеше яраткан, ди.

Карт белән карчыкның җиде улы һәм бердәнбер кызлары булган, ди. Угыллары үсеп җиткәч тә, ата-аналары белән саубуллашып, бәхет эзләргә чыгып киткәннәр, ди. Ә үзләре янында алтын алмадай матур кызлары Җилбикә генә калган, ди.

Угылларының чыгып киткәннәренә җиде ел тулып үтсә дә, бер хәбәрләре дә булмаган, ди. Бу хәл карт белән карчыкны бик пошындырса да, Җилбикәгә карап, алар кайгы-хәсрәтләрен оныталар, ярсыган күңелләрен юаталар икән, ди. Җилбикәнең дә бертуган абзыйларын күрәсе, алар белән сөйләшәсе, аларга иркәләнәсе килә икән, ди.

Бер дә бер көнне эче пошып, абзыйларын сагынып утырганда, Җилбикә шундый җыр чыгарган, ди:

Абзыйларым, җаннарым,
Минем алтынкайларым,
Кая, кая очтыгыз,
Нинди сулар кичтегез?
Нинди таулар артында,
Нинди җиргә җиттегез?
Нинди хәсрәт чиктегез?
Нинди сулар эчтегез,
Җиде елның эчендә
Нинди бәхет таптыгыз?

Җилбикә шулай моңаеп җырлап утырганда, аның янына атасы килгән дә:

— Матуркаем, Җилбикәм, сиңа ни булды, ник болай моңаеп утырасың? — дип сораган.

— Әтием, җаным, абзыйларымны сагындым, күңелем ташыгач җырлап җибәрдем. Кайда соң минем абзыйларым? Аларны күрәсем килә,— дип җавап биргән, ди Җилбикә.

— Ай-һай, кызым, башыңа юк уйлар кергән икән. Абзыйларыңның кайда икәнен мин дә белмим, алар моннан җиде ел элек, безнең белән саубуллашып, бәхет эзләргә чыгып киткәннәр иде, шуннан бирле бер хәбәрләре дә юк. Без дә анаң белән аларны сагынып кайгырабыз-кайгырабыз да, сиңа карап, күңелебезне юатып торабыз,— дигән, ди, атасы.

Атасының сүзләре генә Җилбикәне тынычландыра алмаган. Ул һаман абзыйлары турында уйлана, алар белән күрешер өчен төрле юллар эзли, кайгысыннан күз яшьләрен түгә икән. Бик озак уйлана торгач, кыз утырган җирендә йокыга киткән. Йоклар алдыннан:

— Ичмасам, абзыйларымны төшемдә генә булса да күрергә насыйп булсачы,— дип әйткән, ди, һәм төш күргән, ди.

* * *

Өнендә уйлаганны төшеңдә эшләрсең, дигәннәр картлар. Җилбикә дә шулай. Көне буе абзыйлары турында уйлап йөргәнгә, төшендә дә аларны эзли икән. Кырлардан, урманнардан, болыннардан, шәһәрләрдән эзләп йөри икән.

Бер атна эзләгән, бер ай эзләгән, һаман да абзыйларын таба алмаган. Шулай йөри торгач, ул бер тау тишеге янына килеп чыккан.

— Туктале, бу тау тишеге бушка гына уелмагандыр, монда берәр сер юк микән? — дип, Җилбикә тау тишегенә, эчкә кергән, ди.

Анда ни күзе белән күрсен, ап-ак сакаллы, ап-ак киемле бер бабай, алдына зур китап ачып куеп, йомшак мамык мендәр өстендә утыра, ди. Җилбикә башта куркынып киткән. Тик бабайның:

— Хуш килдең, кадерле кунагым, әйдүк, әйдүк. Үзем дә әле адәм баласын күрәсем килеп, бик сагынган идем. Хуш килдең,— дип, ачык йөз, йомшак сүз белән каршы алгач, Җилбикәнең куркуы бөтенләй беткән, ди.

— Исәнме, бабакаем, нишләп монда утырасың? — дип сүз башлаган, ди, Җилбикә.

— Бик сәламәт, балам, бик сәламәт. Китап карыйм, гыйлем эзлим. Син нинди йомыш белән йөрисең, кызым, сине нинди җил ташлады монда? Сөйлә, кызым, сөйлә, бер дә тартынма. Кайгың булса, уртаклашырмын, йомышың булса, ярдәм итәргә тырышырмын,—дигән, ди, бабай Җилбикәгә.

Җилбикә бабай янына якын ук килгән дә аңа үзенең теләген, кайгысын сөйләгән.

— Ай-һай, балам, теләгең зур икән, шулай булса да, ирешмәслек түгел. Син, балам, өеңә кайт та эткәңнән җиде канатлы җил арба эшләт. Шул арба эшләнеп беткәч, аңар син мин өйрәткән җырны җырларсың. Шуннан соң арба күтәрелеп очып китәр, сине абзыйларың тора торган җиргә илтер,— ди бабай.— Инде, кызым, өеңә кайтсаң да ярый. Юкса әти-әниләрең борчылыр, минем дә вакытымны алма. Әле укыйсым күп. Бушка үткәргән вакытны сатып алып булмый. Бар, балам, бәхетле бул,— дип әйткән, ди.

— Нәрсә соң ул бәхет, бабай? — дип сораган Җилбикә.

— Бәхет — берәр һөнәрнең хуҗасы булу ул, кызым. Берәр һөнәрең булса, син бәхетле, бер нәрсә дә белмәсәң, син бәхетсез. Шуңа күрә борынгы картлар: «Һөнәрле үлми, һөнәрсез көн күрми»,— дигәннәр. Бабайлар сүзне уйламыйча сөйләмәгәннәр, балам,— дигән бабай.

Шулвакыт Җилбикәне әнкәсе иртәнге чәйгә уяткан, аның төше шул җирендә бүленгән.

Чәй янында Җилбикә әтисеннән:

— Әтием, син миңа җиде канатлы җил арба ясап бир әле,— дип сораган.

— Нигә ул сиңа җиде канатлы җил арба? Аның белән нишләмәкче буласың?

— Абзыйларым бәхет эзләргә киткәннәр, ә мин, шул арбага утырып, аларны эзләргә барам, зинһар, эшлә инде, әтием,— дигән Җилбикә.

— Ярар, балам, алай булса эшләрмен,— дигән, ди, әтисе. Әти кеше җиде төн эчендә җиде канатлы җил арба эшләгән. Җилбикә исә, күрше кызы Сылубикәне чакырып, бүләкләр әзерләгән, җиде күлмәк, җиде ыштан теккән, җиде сөлге чиккән. Шуннан соң, әти-әнисе белән саубуллашып, Сылубикәне юлдашлыкка алып, икәү җил арбага утырганнар да:

Әй җил арба, җил арба,
Җиде агайга барамын,
Җиде агайга барамын,
Җиде күлмәк илтәмен,
Җиде ыштан илтәмен,

Җиде сөлге илтәмен,
Кузгал, арбам, оч, арбам,
Канатларың как, арбам,
Җиде көннең эчендә
Абзыйларны тап, арбам!—

дип җырлый-җырлый очып киткәннәр, ди.

Җилбикә белән Сылубикә бертуктамый алты көн, алты төн очканнар, җиденче көннең таңында, агымсуның янында коенырга дип, җил арбаны туктатканнар. Туктаганнар да су коенырга кергәннәр.

Җилбикә яхшы күңелле, эчкерсез кыз булган. Эчендәге серләрен барысын да Сылубикәгә сөйли икән.

Сылубикә исә үги ана кулында кысылып, җәберләнеп үскән, зәһәр, икейөзле кыз булган, бик көнче дә, алдакчы да икән. Су коенганда менә нәрсә уйлаган: алты төн, алты көн килдек инде. Бүген җиденче көн. Җилбикәнең абзыйлары янына барып җитсәк кирәк. Бәхет эзләргә киткән абзыйлары янында Җилбикә дә бәхетле булыр. Ә мин һаман элеккечә бәхетсез булып калачакмын. Туктале, тизрәк судан чыгыйм

да, Җилбикәнең киемнәрен киеп, җил арбага утырып, бер-үзем генә очып китим әле.

Ләкин эш Сылубикә уйлаганча барып чыкмаган. Арбаны урыныннан кузгатыр өчен, теге бабай өйрәткән җырны әйтергә кирәк, ә Сылубикә аны белми бит. Шулай да ул үз уеннан кайтмаган. Куркытып, көчләп Җилбикәгә үзенең киемнәрен кидергән, куркытып, аңардан теге серле җырны әйттергән, арба тагын күтәрелеп очып киткән.

Көн уртасында кызлар бер шәһәргә барып җиткәннәр, Җилбикәнең абзыйларын эзләп тапканнар.

Җилбикәнең абзыйлары, Сылубикәне үзләренең сеңелләре дип белеп, аны иркәлиләр, яңа киемнәр тектерәләр, энҗеле калфак эшләтәләр, үзләре белән бергә тәмле ризыклар ашаталар, баллы чәйләр эчерәләр икән, ди.

Җилбикәне начар ашаталар, үзләре эшкә киткәндә тары сакларга калдыралар, аның ашый торган савыты да ватык чүлмәк төбе икән, ди.

Сылубикә уйный, көлә, Җилбикәне, әгәр абзыйларыңа дөресен әйтсәң, кара аны, минем усаллыкны күрерсең дип, гел куркытып тора, ди. Җилбикә куркуыннан авызына су капкан кебек бер нәрсә дә дәшми, тик ялгыз калганда, тары саклаганда гына, үзенең моң-зарларын күктә очып баручы торналарга гына җыр итеп җырлый икән, ди:

Очыгыз, торналар, очыгыз,
Безнең кырга барыгыз.
Минем карчык анамны
Зинһар эзләп табыгыз.

Табыгыз да әйтегез:
Кызың тары саклыйдыр,
Абзыйларын тапса да,
Чирәптән аш ашыйдыр.

Бер дә көтмәгәндә, ниндидер эш белән Җилбикәнең җиденче абзыйсы өйгә кайткан булган. Ул сеңлесенең җырлавын ишеткән. Бу бала бер дә юкка офтанып җырламый торгандыр. Туктале, бу турыда абзыйларыма да әйтим әле, дип уйлаган да, ди, әйткән, ди.

Эшнең дөресен белер өчен, җиде абзыйсы, Җилбикәне яннарына чакырып, аңардан башыннан үткәннәрнең барысын да сөйләткәннәр. Эшнең төбе беленгәч, аларның Сылубикәгә

бик ачулары килгән. Кылган усаллыклары өчен аңа җәза бирмәкче булганнар, ләкин Җилбикә моңа риза булмаган, абзыйларына әйткән:

— Абзыйларым, минем юлдаш иптәшемне кыерсытмагыз, Сылубикәгә минем һич үпкәм юк,— дигән.

— Усаллыклары өчен аны нишләтик соң? — дип сораганнар абзыйлары.

— Мине дә, Сылубикәне дә бертигез бәхетле итегез, үзегез белгән һөнәрегезне безгә дә өйрәтегез,— дигән Җилбикә.

— Ай-һай сеңлем, теләгең изге икән. Әйдә, алай булса, Сылубикә безнең икенче сеңлебез булсын. Икегезне дә бәхетле итик, икегезне дә һөнәр мәктәбенә бирик, белемле дә, һөнәрле дә, бәхетле дә булырсыз,— дигән, ди, олы абзыйсы Җилбикәгә.

Һөнәр мәктәбен бетергәч, Җилбикә белән Сылубикә әтиәниләре янына кайтканнар, ди. Әле дә булса матур гына яшәп яталар, ди. Шатлыкларыннан зур мәҗлес кордылар, ди. Мәҗлестә мин дә булдым. Ике чынаяк чәй ашадым, бер телем икмәк эчтем. Сезгә күчтәнәч алып кайтасы идем, кесәм тишек булганга, юлда төшеп калган.

җил арба — һавада оча торган арба (әкияттә)
йомыш — кемгә дә булса кушылган эш; йөкләмә
насыйп булу — мөмкинлек булу, җай чыгу
тары — үсемлек (просо)
чирәп — балчыктан ясалган савыт
энҗеле калфак — татар хатын-кызларының затлы баш киеме

Биремнәр

1. Әкияттәге вакыйгаларны сөйләп чыгыгыз. Каршылыкны билгеләгез.
2. Җилбикәгә бәйле вакыйгаларда кызның эш-гамәленә бәя бирегез.
3. Сылубикәгә бәйле вакыйгаларны сөйләгез, бәя бирегез.
4. Каршылыкның хәл ителүенә бәйле нәтиҗә ясагыз.
5. Әкиятнең тәмамланган (бетем) өлешен аңлатыгыз.

Биремнәргә бергәләп җавап бирик

1. Вакыйгаларны сөйләү барышында әкиятнең төп каршылыгы ачыклана: яхшылык һәм явызлык конфликты. Яхшылык тарафдары булып Җилбикә, ата-анасы, ак сакаллы бабай, абзыйлары бирелсә, явызлык Сылубикәнең эш-гамәлендә чагыла.

2. Җилбикә ярдәмчел, тырыш ата-ана белән үсә, шуңа да күңеле һәрвакыт яхшылыкта. Ул абзыйлары өчен борчылып, аларны күрәсе килеп яши. Изге теләге төшендә дә яхшы күңелле бабай белән очрашуга китерә.

3. Сылубикә үги әни белән үсә, һәм күңелендә көнчелек, икейөзлелек, ялганлау кебек сыйфатлар өстенлек ала. Шуңа да ул дустына хыянәт итә.

4. Ахырда ялган-хыянәт ачылгач, Җилбикә Сылубикәне гафу итә. Ул начарлыкны яхшылык белән төзәтә. Әкиятнең темасы да шуннан чыга: игелек. Башкаларга игелекле булу кешегә игелек булып кайта. Тормышта яхшы, изге күңелле булып, ярдәмләшеп яшәргә кирәк. Каршылык шуның белән чишелә.

5. Бетем төп вакыйгага турыдан-туры катнашмый. Ул, берсдән, кызыклы, һәркемне елмайта, икенчедән, сөйләнгән вакыйганың әкият кенә булуын искәртә.

МӘКАЛЬЛӘР ТУРЫНДА

Мәкальләргә тирән һәм үткен фикерне җыйнак итеп, образлы формада әйтеп бирү хас. Алар сөйләмне матур, тәэсирле итәләр.

Борынгы заманнардан ук халык аерым кешеләрнең эшеннән, холык-гадәтеннән гыйбрәт алып яшәгән, билгеле бер нәтиҗә, хөкем чыгарган. Әнә шул рәвешле мәкальләр барлыкка килгән. Аларда халыкның тарихы, тормыш-көнкүреше, рухи дөньясы, иҗтимагый-сәяси карашлары сәнгатьчә чагылыш тапкан. Мәкаль элек-электән халыкның акыллы киңәшчесе, үгет-нәсыйхәт бирүчесе булып килгән. Мәкальләрнең бер төрлесендә халыкның әхлак сыйфатлары, матур гадәтләре, изге теләкләре яклана, мактала. Мәсәлән: «Эш сөйгәнне ил сөйгән», «Мал — торган җирен, ир туган илен онытмас». Икенче төр мәкальләрдә тормыштагы тискәре яклар: комсызлык, саранлык, мин-минлек, икейөзлелек, ялкаулык һ. б. начар гадәтләр тәнкыйть ителә. Мәсәлән: «Илен сатып ашаган — ике генә көн яшәгән»; «Кешегә чокыр казыма, үзең төшәрсең».

Язучылар тарафыннан әйтелгән тапкыр сүзләр, халык теленә кереп китәрлек матур тәгъбирләр дә мәкаль хәзинәсен даими баета киләләр. Мисалга Г. Тукайның «Эш беткәч уйнарга ярый» тәгъбирен китерергә була. Галимнәр исәпләвенчә, телебездә илле мең чамасы мәкаль бар.

Мәкальләрнең үзләренә генә хас сыйфатлары бар. Алар текстан аңлашылган вакыйга-күренешкә бәя бирә. Мәсәлән, «Тырышкан — табар, ташка кадак кагар». Бу очракта тырышлыкның теләгән нәтиҗәгә китерүе раслана. Ул ике өлештән торып, һәрвакыт чагыштырып бәя бирә. Мәсәлән, «Ашыккан — ашка пешкән». Ашка пешүнең нәрсә икәнен, ни сәбәпле икәнен һәр бала белә. Ашыгып эш-гамәл кылсаң, әнә шундый хәлдә калырсың, ди мәкаль.

Мәкальләр

- Ике тәкә башы бер казанга сыймый.
- Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.
- Берлек кайда — көч шунда.
- Эш сөйгәнне ил сөйгән.
- Бүредән курыксаң, урманга барма.
- Ни чәчсәң, шуны урырсың.
- Җаны теләгән елан ите ашаган.

ӘЙТЕМНӘР ТУРЫНДА

Кыска, җыйнак, үткен мәгънәне белдергән әйтемнәр халыкның осталык-тапкырлыгын күрсәтә. Алар нәрсәгәдер чагыштырып бәя бирә. Мәсәлән, «күз ачып йомганчы». Күз ачып йомуның бик тиз башкарылуын һәркем белә. Тиз үтәлгән яисә үтәлергә тиеш эш-гамәл дә шуның белән чагыштырыла. Әйтем теге яки бу әйбернең сыйфатын, сыйфат дәрәҗәсен ачыклый. Мәсәлән, «җиде төн уртасы». Әйтемнәр төрле вакыйгаларда төрле мәгънә дә алырга мөмкин. Мәсәлән, «ут борчасы». Ул шаярып та, үз итеп тә, тәнкыйтьләп тә әйтелә ала.

Әйтемнәр

- Аяклы каза.
- Бер чыбыктан сөрелгәннәр.
- Кырын карау.
- Эт белән мәче кебек яшәү.
- Борчак ата.
- Кырмыска оясына таяк тыгу.
- Йомырка тавыкны өйрәтми.
- Әйләнечтән юл якын.
- Күз өстендә каш булып.
- Чүп өстенә чүмәлә.

Биремнәр

1. Мәкаль һәм әйтемнәрне сәнгатьле укырга өйрәнегез. Аларның мәгънәләрен аңлатыгыз.
2. Мәкаль һәм әйтемнәргә хас сыйфатларны аерып, таблица төзегез.
3. Түбәндә бирелгән мәкаль һәм әйтемнәрне укыгыз. Дәфтәрегезгә әйтемнәрне сайлап языгыз.

Комнан аркан ишмиләр.
Бөркетнең канаты очканда ныгый.
Иленнән аерылганның канаты каерылган.
Үзе егылган еламас.
Арзанның буявы тиз куба.

Җиде кат үлчә, бер кат кис.
Киемгә карап каршы алалар, акылга карап озаталар.
Аш белән атканга таш белән ату.
Каш төзәтәм дип күз чыгару.
Олыласаң олыны, олылларлар үзеңне.
Мактанма, ат диеп сыерга атланма.
Туган телем — иркә гөлем, киндер сиңа күңел түрем.
Китап — тормыш көзгесе.

ТАБЫШМАКЛАР ТУРЫНДА

Халык авыз иҗаты әсәрләренең бер төре — табышмаклар. Тормыштагы нинди дә булса бер әйбер яки күренешне икенче бер әйбер яки күренеш белән чагыштыру аларның төп сыйфатын билгели.

Табышмаклар күптөрле булалар. Бер төр табышмаклар бер әйберне икенчесенә турыдан-туры охшату юлы белән иҗат ителгәннәр. Мәсәлән, *«Бәләкәй генә эт, өрми дә, җибәрми дә»* (йозак). Икенче төр табышмаклар сорау рәвешендә булалар: *«Берсе чәчә, берсе эчә, берсе үсә — ул нәрсә?»* (яңгыр, җир, үсемлек). Хисаплау-санау белән бәйләнешле табышмаклар да була: *«Ике сигез — уналты, тагы сигез, тагы алты»* (утыз).

Татар фольклорында әкият-табышмаклар да очрый. Аларга мисал итеп «Өч юлаучы», «Кем җиңүче?», «Акыллы бала» әкиятләрен күрсәтергә мөмкин.

Табышмаклар тормышны танып белергә, зиһенне үстерергә, хәтерне ныгытырга ярдәм итәләр. Алар кыска, җыйнак, рифмалы булалар.

Табышмаклар кешенең уйлау, фикерләү сәләтен, зиһенен сыныйлар. Аны әйтүче дә, җавабын табучы да үзен зирәк итеп күрсәтәсе килә. Табышмак җавабы уйлау-фикерләү, чагыштыру-охшату аша табыла. Мәсәлән, *«Таяк, таяк өстендә табак, табак өстендә кибет, кибет эчендә мең егет»*. Җавап болай табыла: таяк өстендәге табакка урнашкан кибеттә мең егет була алмый; димәк, табакка охшаган, эчендә

күп санлы (меңләгән) әйбер-предметлар булган башка бер предметны эзлибез. Таяк өстендә табакка охшаган нәрсә булырга мөмкин? Кош оясымы? Туры килми. Шул рәвешле, көнбагышның таяк өстендәге табакка охшаш булуы табыла. Табышмакның җавабы — көнбагыш.

Биремнәр

1. Мәкаль, әйтем һәм табышмакның охшаш һәм аермалы якларын билгеләгез.
2. Дәрестә «Табышмак әйтәм — җавабын тап» уены оештырыгыз.
3. Түбәндәге табышмакларны анализлап, җавапларын табыгыз.

Күтәреп була, ыргытып булмый.
Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач.
Агачтан биек, үләннән тәбәнәк.
Җәен урманга патша, кышын кардан да аста.
Әниегезнең сеңлесенең җизнәсе сезгә кем була?
Үзе бер дә ашамый, ашаганда бушамый.
Аягы бар, кулы юк, аркасы бар, түше юк.
Кечкенә генә бөкере, бөтен кырны бетерде.
Килеп керде бер кеше, маңгаенда бер күзе.

ӘКИЯТ-ТАБЫШМАКЛАР

* * *

Бер төркем киек каз очып барганда, каршыларына бер каз очрап:

— Исәнмесез, йөз каз,— дигән. Болар «саумысыз» дип, исәнлек-саулык сорашканның соңында, араларыннан берсе әйткән:

— Юк, сеңелкәем, ялгышасың, без йөз каз түгел шул әле. Әгәр дә безнең чаклы тагын бер булса, тагын безнең яртыбыз чаклы булса, чиregебез чаклы булса, аның өстенә син дә килеп кушылсаң, менә шул чагында булырбыз йөз каз,— дигән.

Беләсе иде: бу төркемдә ничә каз булды икән?

Җавап: Төркемдә утыз алты каз булган.

* * *

Бер кеше юлга чыкты, ди. Үзе белән алды, ди, бер бүре, бер кәҗә, янә кәбестә. Барадыр иде, ди, барадыр иде, ди, бара торгач, бу кешегә Идел кичәргә туры килде, ди. Иделне кичәргә кечкенә генә бер көймә бар. Көймә бик кечкенә, һәммәсен дә берьюлы күтәрә алмый. Инде ни эшләргә? Берәм-берәм генә чыгарыр иде, иң элек кайсын чыгарырга: бүренеме, кәҗәнеме, кәбестәнеме?

Бүрене теге якка чыгарып куяр иде, кәҗә кәбестәне ашый, кәбестәне чыгарып куяр иде, бүре кәҗәне ашый. Кәҗәне чыгарып куяр иде, икенчесен чыгарганда тагын кайсын алдан чыгарырга: бүренеме, кәбестәнеме?

Бүрене чыгарса, ул кәҗәне тотып ашый, кәбестәне чыгарса, анда чыгарып куйгач, кәҗә кәбестәне ашый. Менә шулай итеп бу кеше аптырашта калды, ди. Алай итте, ди, болай итте, ди, актыгында, күп азаплана торгач, җаен тапты, ди, барын да чыгарып бетереп, үз юлына китте, ди. Беләсе иде: ул кеше бүре, кәҗә, кәбестәсе белән Иделне ничек кичте икән?

Җавап: Бу кеше иң элек кәҗәне теге якка чыгарып куя. Аннан соң кайтып, бүрене алып чыга. Икесе бергә торганда, бүре кәҗәне ашамасын өчен, кәҗәне тагын үзе белән алып чыгып, бу яктан кәбестәне чыгара, кәҗәне калдырып тора. Аннан соң кире кайтып, кәҗәне дә алып китә.

ТИЗӘЙТКЕЧЛӘР ТУРЫНДА

Тизәйткечләр әйтү өчен авыр булган, бер-берләренә охшаш сүзләрдән төзеләләр. Шуңа карамастан, тизәйткечне бик тиз һәм ялгышмыйча әйтеп бирү таләп ителә.

Тизәйткечләр, беренчедән, уен-көлке, күңел ачу өчен кулланылсалар, икенчедән, алар сүз һәм иҗекләрне ачык әйтергә, чиста, дөрес итеп сөйләргә өйрәтәләр. Соңгысына бәйле рәвештә, тизәйткечләрне еш кына *тел төзәткечләр* дип тә йөртәләр.

Тизәйткечләр

1. Кара чананы карамаларга биргән идем, карамаладылар микән, карамаламадылар микән, карамаласалар да алып кайт, карамаламасалар да алып кайт.

2. Әйттем такмак, бастым так-так,
Идән таптап такмаклап.
Безнең эшләр такмак тапмак,
Син дә миңа тап такмак.

3. Иң алдан баручы бу,
Эштә дан алучы бу,
Тантаналы көннәрдә
Тантаналанучы бу.

4. Башта башлап таш баскыч башына бас.
Баскыч башына башыңны бәрмә.

5. Бүрәнәне басты бүдәнә,
Бүдәнәне басты бүрәнә.
Гаеп бүрәнәдә дә бар,
Бүдәнәдә дә бар.

абага — челтәр сыман зур яфраклы үсемлек
багу — карау
карама — *монда:* арба, чана кебек әйберләрдә тоташтыру-эләктерү өчен яшь карама агачын бөгеп ясалган җайланма
карамалау — арба-чанага шул җайланмаларны кую
такмак — кыска җыр
тантана — бәйрәм, максатка ирешү куанычы
тантаналанучы — хөрмәтләнүче
бүдәнә — бытбылдык (кош)
бүрәнә — кисеп аударылган агач

Сораулар һәм бирем

1. Ни өчен тизәйткечләрне тел төзәткечләр дип атыйлар?
2. Сез нинди тизәйткечләр беләсез?
3. Дәрестә, күмәк көч белән, тизәйткечләр төзеп карагыз.

ШАРАДАЛАР ТУРЫНДА

Шарада — табышмакның бер төре. Биредә табышмак итеп алынган сүзнең һәр кисәге мөстәкыйль сүз була ала.

Шарадалар, бер яктан, ял итү, күңел ачу өчен кулланылсалар, икенче яктан, сүзләрнең төзелешен, дөрес язылышын аңларга да ярдәм итәләр.

Шарадалар

1. Бер иҗеге аның — бер төс,
Икенчесе — сыеклык.
Өченчесе ул авылны
Шул әйбергә бик бай, ди. *(Аксубай.)*

2. Беренче иҗек — торган су,
Икенчесе — бер чәчәк.
Икесен бергә кушсалар,
Аны һәркем киячәк. *(Күлмәк.)*

3. Үзе биш хәрефтән тора. Баштагы өч хәрефен генә укысаң, татлы әйбер исеме килеп чыга, соңгы ике хәрефе — Татарстандагы елга исеме. Ике сүзне бергә кушсаң, суда яшәүчене аңлата. Бу нинди сүз? *(Балык.)*

4. Исеме ике сүздән тора. Беренчесе — җир йөзендә иң күп нәрсә, икенчесе — җир-су хайваны; икесен бергә җыйганда, өен үзе белән йөртә торган хайван исеме килеп чыга. *(Ташбака.)*

5. Түтәлдә нинди ике нота үсә? *(Фа, соль.)*

6. Беренче ике иҗеге — хайван.
Өченче иҗеге — боерык фигыль.
Барысы бергә — кош исеме. *(Сыерчык.)*

Табышмак-шарадаларның бер төре *логогриф* дип атала. Башваткычның бу төре тиешле сүзне уйлап табып, андагы аерым иҗекләрне яки хәрефләрне алыштырып кую, өстәү һәм төшереп калдыру юлы белән чишелә.

Мәсәлән:

1. Эчендәге вак җимешен
Һәркем яратып ашый.
Исеменә «а» өстәсәң,
Ул бик каты шартлый. *(Гранат, граната.)*

2. Киң болында чабып йөри,
Кешнәп дөнья тутыра.
Алдан бер хәрефен алсаң,
Күккә менеп утыра. *(Тай, ай.)*

3. Тугай кайчан сайрый? *(«Р» хәрефе өстәгәч.)*

түтәл — яшелчә яки гөлләр утырту өчен йомшартылган туфрак
шартлау — җимерелү
кешнәү — кычкыру, аваз чыгару (ат турында)
тугай — болын

Сорау һәм биремнәр

1. Нәрсә ул шарада?
2. Табышмак-шарадаларның бер төре буларак логогрифның үзенчәлеген аңлатыгыз.
3. Укытучы белән бергәләп, шарада һәм логогрифлар уйлап табыгыз.

Габдулла Тукай
(1886—1913)

ТУКАЙ НИГЕЗЛӘРЕ

Минем берничә нигезгә баш иясем килә. Беренчесе — Кушлавыч, Тукай туган нигез. Шунда туган, шунда дөньяга килгән. Әтисе йорты, әнисе йорты. Ул нигез нинди генә булмасын,— баймы, ярлымы,— барыбер изге. Туфрагы изге. Яшь Габдулланың «сәяхәте» шушы авылдан башлана. «Өзелгән өмид», «Тәфтиләү» — иң үзәк өзгеч җырлары әнисе Мәмдүдәгә багышланган... Икенче нигез — Кырлай, Кырлай урманы, Кырлай табигате, Сәгъди абзый йорты... Бер Кырлай булачак шагыйрь Тукай күңеленә күпме хис салган! «Шүрәле» шуннан, «Су анасы» шуннан. Кайчан, кайда язылуларына карамастан, «Туган авыл», «Туган җиремә», «Туган тел», «Пар ат», «Көзге җилләр» — барысы да шуннан. Табигать кешенең күңелен нечкәртә, сафландыра, рәхимле, шәфкатьле итә, баета. Шуның өстенә халыкның бәйрәмнәре, җырлары, моңнары, әкиятләре, гореф-гадәтләре...

Яшь Апуш, Габдулла, тугыз яшенә тикле шушы тирәдә әйләнеп йөргән. Кушлавыч, Өчиле, Сасна, тагын Өчиле, Казан, тагын Өчиле һәм Кырлай... Мин баш ия торган, иң хөрмәт иткән нигез — Сәгъди абзый йорты. Габдулла, Сәгъди абзый тәрбиясенә эләкмәсә, бәлки егерме җиде яшькә кадәр дә яшәмәгән булыр иде... Билгеле, Тукайны бер Кырлай, бер Казан арты гына Тукай итмәгән. Шагыйрьгә күп нәрсә кирәк.

Тукайны татар халкының тарихы, язмышы, бөек мәдәнияте тудырган. Тукайның Кырлайдан соң Җаекка элэгүен мин зур бәхет дип саныйм. Күп вакыт Тукайның бай теленә гаҗәпләнәләр. Каян ул? Татар теле — ана теле. Туган тел. Тукай төрки, гарәп, фарсы телләрен дә яхшы белгән. Тукайны укымышлы, талантлы кешеләр укыткан. Тукай Мотыйгулла хәзрәт мәдрәсәсендә укый. Ә Мотыйгулла үзе — Мисырда озак еллар белем алган кеше. Тукайдагы төрле шигырь формалары да әллә каян килмәгән. Шул мәдрәсәләр бит, Тукайдан тыш, татар әдәбиятына Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Кәрим Тинчурин, Нәкый Исәнбәтләрне дә биргәннәр.

Тукайның Җаекта рус классына элэгүе дә зур бәхет. Пушкин, Лермонтов, Некрасов, Майковлар белән ул шунда очраша. Шагыйрьгә күп нәрсә кирәк. Башта аңа табигый талант кирәктер. Тукай зирәклеге...

Шагыйрьне Казан артында тугыз ел, Җаекта унике ел, Казанда алты ел яшәгән дип бүлгәләп булмый. Тукай бу урыннарга гына сыймаган. Дөньясы гаҗәеп киң. Шагыйрь дөньясы — фикер дөньясы. Тукай — татар халкының бу җирдә барлыгын, бөеклеген, үлемсезлеген раслар өчен дөньяга килгән шагыйрь.

Нигезләр... Кайсында бер ел, кайсында ике ел, кайсында өч ел... Бер караганда, алай озак төпләнеп яшәгән нигезе дә юк кебек. Ләкин, уйлана торгач, шушы таралган вак-вак нигезләр минем күңелдә бер төшкә җыела башлыйлар да олы бер нигез хасил итәләр. Ул нигез — халык. Төп нигез. Тукайның төрле характердагы шигырьләрен укыганнан соң, аларның менә шушы зур нигездән үсеп чыкканын күрәсең. Узганы, тарихы, традициясе белән гасырлар буена салынган бер нигез алга баса. Кырлайга сәяхәт иткән саен, мин шул изге нигезләр турында уйлыйм. Тукай өчен күңелем рәхмәт хисләре белән тула.

Сибгат Хәким

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ — БАЛАЛАР ЯЗУЧЫСЫ

Балалар өчен иҗат иткән шигырьләре шагыйрь мирасының яртысын диярлек тәшкил итә. Үзе исән чакта дөнья күргән 34 китабының 16 сы турыдан-туры балаларга, мәктәп укучыларына атап чыгарылган: «Юаныч» (1908),«Энҗе бөртекләре» (1909), «Балалар күңеле» (1910), «Күңелле сәхифәләр» (1910), «Күңел җимешләре» (1911) һ. б.

Тукайның күп шигырьләрен үзе исән чагында ук мәктәп-мәдрәсәләрдә көйләп күмәк җырлый торган булганнар. Беренче дәрес аның илаһи «Туган тел»е белән башланып, уку елы беткәндә, соңгы дәрес тә шул җыр белән тәмамланган.

Тукай укучылар өчен дәреслекләр дә язган. Аның башлангыч сыйныфлар өчен төзелгән «Яңа кыйраәт» («Яңа уку китабы») исемле дәреслеге (1909, 1910) үзенең эчтәлеге һәм формасы белән ул чор өчен чын мәгънәсендә яңа китап булган һәм совет чорында да мәктәпләрдә яхшы дәреслек булып саналган. «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» (1911) исемле хрестоматиясе дә мәктәпләрдә озак еллар укытылган.

Сорау һәм биремнәр

1. Габдулла Тукайның балачагы кайда һәм нинди шартларда үткәнен хәтерегезгә төшерегез.
2. Шагыйрьнең нинди шигырьләрен беләсез? Яттан сөйләгез.
3. Тукай төзегән дәреслек исемнәрен әдәбият дәфтәрегезгә язып куегыз.

ЭШКӘ ӨНДӘҮ

Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә,
Аһ, оят, хурлык, түбәнлекләр иренгәннән килә.
Булса калдырмак берәү ошбу җиһанда изге ат,
Тир белән тапсын ашарын, итсен, әлбәт, иҗтиһад.
Һәр олугълар эшләгәнлектән олугълыклар таба,
«Уйнады»,—дип бирмиләр ошбу җиһанда мәртәбә.

И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә — эш,
Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китрер җимеш.
Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел,
Каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел.

1911

җиһан — дөнья, галәм
изге ат — яхшы исем
иҗтиһад иту — тырышу
олугъ — бөек
мәртәбә — дәрәҗә, исем, абруй
мөкатдәс — изге, бөек, мөһим, хөрмәтле

Сораулар һәм бирем

1. Кешеләргә бәхет яки хурлык китерүче сәбәпләрне шагыйрь нәрсәләрдә күрә?
2. *И сабыйлар! Эшләгез сез, иң мөкатдәс нәрсә — эш,*
   Эш агачы һәрвакытта бик юмарт китрер җимеш
   дигән юлларның асылын ничек аңлыйсыз?
3. Яшьлегендә тырышып эшләгән кешенең киләчәк тормышын шагыйрь ничек күзаллый?
4. Шигырьне ятлагыз.

САБЫЙГА

Һич сине куркытмасыннар шүрәле, җен һәм убыр;
Барчасы юк сүз аларның, булганы юктыр гомер.
Җен-фәлән дип сөйләшүләр искеләрдән калган ул;
Сөйләве яхшы, күңелле, шагыйранә ялган ул.
Һич өрәк, албасты булган сахралар, кырлар да юк;
Шүрәле асрап ята торган кара урман да юк.
Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын;
Мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын.

1909

шагыйранә — шигъри, поэтик
албасты, убыр, җен — мифик образлар — кешеләргә явызлык эшләүче көчләр

өрәк — мифик образ — үлгән кешенең башкаларга күренә торган рухы
сахра — басу, кыр
мәгърифәт — аң, белем

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз.
2. Шүрәле, җен, убыр, өрәк, албасты кебек мифик образларга шагыйрьнең мөнәсәбәте нинди?
3. Бу шигырьдә Тукай нәрсә әйтергә тели?
4. Мәгърифәткә, яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә шагыйрь ничек карый? Аның теләген белдергән юлларны укыгыз.
5. Бу шигырь кешедә нинди сыйфатлар тәрбияләргә ярдәм итә?

ЭШ БЕТКӘЧ УЙНАРГА ЯРЫЙ

Бик матур бер җәйге көн: өстәл янында бер Сабый
Ян тәрәзә каршысында иртәнге дәрсен карый.
Чын күңел белән укый ул, кат-кат әйтеп һәр сүзен;
Бик озак шунда утырды, бер дә алмастан күзен.

Шул чагында бу Сабыйны чакыра тышка Кояш:
«И Сабый, ди, әйдә тышка, ташла дәрсең, күңлең ач!
Җитте бит, бик күп тырыштың, торма бер җирдә һаман;
Чыкчы тышка, нинди якты, нинди шәп уйнар заман!»
Бу Кояшның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Тукта, сабрит, уйнамыйм, ди, уйнасам, дәрсем кала.
Көн озын ич, ул уенның мин һаман вактын табам,
Чыкмамын тышка уенга, булмыйча дәрсем тәмам».
Ул, шулай дип, кимчелек бирми укырга дәртенә,
Бик каты ихлас белән чынлап ябышты дәрсенә.
Өй түрендә шул заман сайрый ботакта Сандугач,
Ул да шул бер сүзне сайрый: «Әйдә тышка, күңлең ач!
Җитте бит, бик күп тырыштың, торма бер җирдә һаман,
Чыкчы тышка, нинди һәйбәт, нинди шәп уйнар заман!»
Сандугачка каршыга биргән җавабында Бала:
«Юк, сөекле Сандугачым, уйнасам, дәрсем кала.
Туктале, бетсен дәрес, ди, әйтмәсәң дә уйнарым,
Син дә сайрарсың матурлап, мин авазың тыңларым!»
Ул шулай дип, һич зарар бирми укырга дәртенә,
Бик каты ихлас белән чынлап кереште дәрсенә.

Шул вакытта өй түрендә бакчада бер Алмагач
Чакыра тышка Сабыйны: «Әйдә тышка, күңлең ач!
Бик күңелсездер сиңа эштә утырмак һәрвакыт,
Әйдә, чык син бакчага, җитте хәзер уйнар вакыт!»
Алмагачның сүзенә каршы җавабында Бала:
«Юк, сөекле Алмагачым, уйнасам, дәрсем кала.
Тукта, сабрит аз гына, ди, и кадерле Алмагач,
Һич уенда юк кызык, дәрсем хәзерләп куймагач».
Күп тә үтми, бу Бала куйды тәмамлап дәрсене,
Куйды бер читкә җыеп дәфтәр, китапны — барсыны.
Чыкты йөгреп бакчага: «Я, кем чакырды, дип, мине?
Әйдә, кем уйный? Тәмам иттем хәзер мин дәрсеми!»
Шунда аңгар бик матурлап елмаеп көлде Кояш,
Шунда аңгар кып-кызыл зур алма бирде Алмагач;
Шунда аңгар шатланып сайрап җибәрде Сандугач,
Шунда аңгар баш иделәр бакчада һәрбер агач.

1909

дәрсен — дәресен
сабрит — сабыр ит
ихлас белән — теләк белән, чын күңелдән
укырга дәртенә — укуга омтылышына
уйнарым — уйнармын

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз һәм эчтәлеге буенча план төзегез.
2. Баланың үз эшенә җаваплы каравы, өйгә бирелгән эшләрне вакытында, дөрес, чиста-пөхтә итеп үтәргә тырышуы сездә нинди тәэсир калдырды?
3. Балада нинди уңай сыйфатлар күрдегез? Аннан нәрсәләргә өйрәнергә теләр идегез?
4. Хезмәт турында мәкальләрне укыгыз һәм мәгънәләрен аңлатыгыз.

   Агач — җимеше белән, кеше — эше белән.
   Авыр эшкә беләк бар, кыю эшкә йөрәк бар.

Аннан-моннан эшләсәң, яңадан эшләрсең.
Башлаган эшне ташлама.
Бер яхшы эш мең яхшы сүздән артык.
Кешенең кемлеген төсеннән белеп булмый, эшеннән белеп була.
Хезмәт төбе — хәзинә.
Хөрмәт сөйсәң, хезмәт сөй.
Һөнәре бар үргә йөзәр.
Эшләгәнең илеңә яхшы, өйрәнгәнең үзеңә яхшы.
Эш сөйгәнне ил сөйгән.
Эш күрсәткән ирне ил онытмас.

СУ АНАСЫ

(бер авыл малае авызыннан)

I

Җәй көне. Эссе һавада мин суда коенам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сызам.
Шул рәвешчә бер сәгать ярым кадәрле уйнагач,
Инде шаять бер сәгатьсез тирләмәм дип уйлагач,
Йөгереп чыктым судан, тиз-тиз киендем өс-башым;
Куркам үзем әллә нидән, юк янымда юлдашым.
Бервакыт китәм дигәндә, төште күзем басмага;
Карасам: бер куркыныч хатын утырган басмада.
Көнгә каршы ялтырый кулындагы алтын тарак;
Шул тарак берлән утыра тузган сачен тарап.
Тын да алмыйча торам, куркып кына, тешне кысып,
Шунда яр буендагы куе агачларга посып.
Сачләрен үргәч тарап, сикерде төште суга ул;
Чумды да китте, тәмам юк булды күздән шунда ул.
Инде мин әкрен генә килдем дә кердем басмага,
Җен оныткан, ахры,— калган тарагы басмада.
Як-ягымда һич кеше дә юклыгын белдем дә мин,
Чаптым авылга, таракны тиз генә элдем дә мин.
Күрмимен алны вә артны, и чабам мин, и чабам;
Ашыгам, тирлим, пешәм һәм кып-кызу уттай янам.

Бер заманны әйләнеп баккан идем артка таба,—
Аһ, харап эш! Су анасы да минем арттан чаба.
Кычкырадыр: «Качма! качма! Тукта! тукта, и карак!
Ник аласың син аны,— ул бит минем алтын тарак!»
Мин качамын — ул куадыр, ул куадыр — мин качам;
Шулкадәрле кыр тыныч, һичбер кеше юк ичмасам.
Шул рәвешчә чабышып җиттек авылга бервакыт,
Су анасыны куарга күтәрелде барча эт!
Вау! да вау! да, һау! да һау — бертуктамый этләр өрә;
Су анасы, куркып этләрдән, кирегә йөгерә.
Инде эш җайланды, куркудан тынычландым, дидем;
И явыз карчык! тарагыңнан коры калдың, дидем.
Өйгә кайттым да: «Әни, алтын тарак таптым!» — дидем;
«Сусадым, ардым, әни, мин бик озак чаптым!» — дидем.
Сөйләгәчтен кыйссаны, алды тарагымны әни;
Курка үзе алса да,— уйлый эченнән әллә ни...

II

Яхшы, хуш. Батты кояш. Йокларга яттым кич белән;
Өй эче тулган иде кичке һава, хуш ис белән.
Юрган астында йокыга китми ятам мин һаман;
Шык та шык! — кемдер тәрәзәгә чиертә бер заман.
Мин ятам рәхәт кенә, тормыйм да кузгалмыйм әле.
Бу тавышка сискәнеп, торган йокысыннан әни:
— Ни кирәк? Кем бу? Кара төндә вакытсыз кем йөри?
Нәрсә бар соң төнлә берлән, и пычагым кергери!
— Су анасы мин, китер, кайда минем алтын тарак?
Бир! бая көндез алып качты синең угълың, карак!
Төшкән айның шәүләсе, мин юрган астыннан карыйм;
Калтырыйм, куркам: «Ходай! — дим,— инде мин кайда барыйм?»
Һич өзексез шык та шык! безнең тәрәзәне кага;
Ул коточкыч сачләреннән чишмә төсле су ага.

Әнкәем алтын таракны, тиз генә эзләп табып,
Атты да тышка, тизүк куйды тәрәзәне ябып.
Су анасыннан котылгачтын, тынычлангач, әни
И орышты, и орышты, и орышты соң мине!
Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым,
«Йә иясе юк!» — дип, әйберләргә тими башладым.

1908

шаять — ихтимал, мөгаен
төште күзем — күрдем
юлдаш — иптәш, дус
басма — елга аша чыгу өчен салынган такта
көнгә каршы — кояшта, кояш яктысында
тын да алмый торам — тик кенә, кыймылдамый торам
посу — сыену, качу
әйләнеп баккан идем — әйләнеп караган идем
тарагыңнан коры калдың — тараксыз калдың
кыйсса — вакыйга, хәл
хуш — ярый
андый эшкә кыймый башладым — андый эш эшләмәдем

Сораулар һәм биремнәр

1. Әкиятне сәнгатьле итеп укыгыз.
2. Шагыйрь Су анасын ничек тасвирлый?
3. Су анасының тарагын алып малай дөрес эшләгәнме?
4. Бу вакыйгадан малай нинди сабак ала? Шигырь эчтәлеге буенча фикер алышыгыз.

Әнвәр Бакиров
(1920— 2001)

Әнвәр Закир улы Бакиров 1920 елның 7 июлендә Казанда туа. Аның әтисе һәм әнисе — гармунда, ике апасы — мандолинада, абыйсы курай, кубыз, кларнетта уйнаган.

Кечкенәдән музыка сөюче Әнвәр 1934 елда Казан музыка училищесына укырга керә. Анда уку дәверендә ул үзе дә көйләр язарга хыяллана. 1937 елда аның Хәй Вахит шигыренә иҗат ителгән «Иртәнге серенада»сы дөнья күрә. Шуннан башлап композитор бөтен күңелен иҗат эшенә бирә.

1940—1946 елларда Ә. Бакиров армия сафларында хезмәт итә. Бөек Ватан сугышы елларында аның «Кыз сәламе» (М. Максуд), «Аппагым» (М. Садри), «Чәчәк җыям» (Г. Хуҗи), «Кемгә сөйлим» (Ф. Кәрим) кебек моңлы лирик әсәрләре, дәртле маршлары туа. Моннан тыш, композитор скрипка өчен поэма, виолончель һәм фортепьяно өчен сонатина, симфония, кантата, увертюра, музыкаль поэма һәм балет кебек зур, катлаулы әсәрләр дә иҗат итә башлый.

Иҗади омтылыш аннан музыкаль белемен үстерүне дә таләп итә. Ә. Бакиров 1947 елда Казан дәүләт консерваториясенең композиторлык классына укырга керә. Укуының икенче елында яшьләр җырына үткәрелгән конкурста аның «Яшьләр җыры» (М. Мазунов) беренче премияне ала.

1952 елда Ә. Бакиров консерваторияне тәмамлый. Аның өчен яңа иҗади эзләнүләр чоры башлана. «Тынычлык

турында җыр», «Ана җыры», «Галәм лачыны», «Яшьлек каласы», «Кыр казлары киткәндә», «Ямьле безнең Минзәләбез», «Әйткән идең» һ. б. җырлары зур вакыйгалар эзеннән туганнар. Аларда күңел күтәренкелеге һәм йөрәктән чыккан моң яңгырый.

Әнвәр Бакиров — Габдулла Тукай иҗатына гашыйк композитор. Ул үз иҗатында Тукайның бөеклеген, халыкчанлыгын тулысынча ачарга омтыла, халкыбыз күңеленә шагыйрь хисләрен тагын да тирәнрәк алып керә. Нәтиҗәдә аның «Алтын тарак» (1957), «Су анасы» (1970) балетлары дөнья күрә. «Су анасы» балеты Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында уңыш белән бара. Халык шагыйренең һәркем яратып укый торган бу әсәре, музыка һәм бию хәрәкәтләренә әверелеп, күпләгән тамашачыны дулкынландыра, рухи баета.

Ә. Бакиров — «Тукай» операсының, «Беренче факел» опереттасының, «Кама киңлегендә» ораториясенең, «КамАЗ» увертюрасының да авторы.

Татар музыкасын үстерүдәге хезмәтләре өчен композиторга 1969 елда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. 1973 елда Ә. Бакиров «Су анасы» балеты өчен Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының халык артисткасы Зөләйха Хисмәтуллина болай дигән иде: «Композитор Әнвәр Бакировның иҗатчы буларак бер бик күркәм үзенчәлеген билгеләп үтәсе килә: аның җырлары эчтәлекләре белән дә, музыкаль аһәңнәре белән дә актуаль. Алар көннең кадагына сугалар. Аларда күтәренкелек, рух байлыгы, оптимистик көч зур...»

музыкаль поэма — зур күләмле музыкаль әсәр
виолончель — дүрт кыллы скрипка рәвешендә эшләнгән музыка коралы
фортепьяно — пианино, рояль кебек клавишлы музыка коралларының гомуми исеме

соната — бер яки ике уен коралы өчен язылган, төрле тәрдәге өч-дүрт кисәкле музыкаль әсәр
сонатина — кечкенә күләмле соната
симфония — оркестр өчен язылган зур күләмле музыкаль әсәр
кантата — солистлар, хор һәм оркестр өчен язылган зур күләмле, тантаналы музыкаль әсәр
оратория — җырчы, хор һәм оркестр өчен язылган музыкаль әсәр
увертюра — 1) операга, балетка, кинофильмга һ. б. музыкаль кереш; 2) оркестр өчен язылган кечкенә күләмле музыкаль әсәр

Сораулар һәм биремнәр

1. Ә. Бакировның тормышы һәм иҗаты турындагы мәгълүматларга нигезләнеп, хронологик таблица төзегез.
2. Сез Әнвәр Бакировның нинди җырларын беләсез?
3. Дәфтәрегезгә ул иҗат иткән әсәр исемнәрен язып куегыз.
4. Габдулла Тукайга багышлап яки аның әсәрләренә язылган тагын нинди музыкаль әсәрләр беләсез?

Садри Ахунов
(1903—1990)

Садри Салих улы Ахунов 1903 елда Екатеринбург шәһәрендә туа. 1924—1927 елларда Уральскида художество-промышленность техникумында, 1927—1931 елларда Ленинградта (хәзерге Санкт-Петербург) рәсем сәнгате институтында укый. 1931—1951 елларда Казанда яши. Казан художество училищесында укыта һәм скульптура бүлеге белән җитәкчелек итә. Соңрак ул Мәскәүгә күчеп китә һәм 1961—1977 елларда Мәскәү технология институтының композиция кафедрасы мөдире булып эшли.

С. Ахуновның иҗади сәләте скульптор һәм портретчы буларак формалаша. Ул татар мәдәниятенең күренекле эшлекләләре Г. Тукай, Г. Камал, Ш. Камал, Һ. Такташ, С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов һәм М. Җәлил сыннарын ясый. Шунысы бик мөһим: Садри Ахунов—М. Җәлил әле үзе исән чагында ук аның образын ташка коеп калдырган бердәнбер скульптор.

1937 елда ул француз язучысы Ромен Ролланның бюст-портретын иҗат итә.

1958 елда С. Ахуновның күптәнге хыялы тормышка аша — Мәскәү скульпторлары Л. Кербель, Л. Писаревский, архитектор Л. Павлов белән хезмәттәшлеге нәтиҗәсендә Казанда Габдулла Тукайга һәйкәл ачыла. Шагыйрь сыны гаҗәеп камил: гәүдә торышы иркен, йөз сызыклары, куллар искиткеч осталык белән иҗат ителгән.

Һәйкәлнең тулы биеклеге 10 метр, шагыйрь сынының биеклеге 4,4 метр. Ул бронза һәм граниттан эшләнгән. Габдулла Тукай һәйкәленә һәркем сокланып карый, аның янына һәрвакыт чәчәк бәйләмнәре, гөлләр куела.

Казанда Тукай истәлегенә куелган тагын бер һәйкәл бар. Ул — Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы һәйкәл. Анда һәр елның 26 апрелендә Шигърият бәйрәме, Тукай туган көн билгеләп үтелә. Бу көнне иҗатлары белән аеруча зур уңышка ирешкән язучылар, рәссам, артист, композиторларга һ. б. әдәбият-сәнгать эшлекләләренә Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

ТУКАЙ ҺӘЙКӘЛЕ

Әй шагыйрем,— җырлар даһие!
Сиңа мәрмәр һәйкәл куелган.
Һәркем иртүк, сиңа сәлам биреп,
Эшкә атлый бакча буеннан.

Әй шагыйрем,— моңнар дәрьясы!
Үткен, уйчан, кыю карашың.
Дулкынланып, Идел анабыздай,
Гасырларга җырлап барасың.

Әй шагыйрем,— илһам кояшы!
Күңелләрдә һәрбер әйткәнең.
Җирдән түгел, халык йөрәгеннән
Күтәрелә синең һәйкәлең.

Мәхмүт Хөсәен

Сораулар һәм биремнәр

1. Татар рәсем сәнгате вәкилләреннән (рәссам, скульпторлардан) сез кемнәрне беләсез?
2. Кабан күле буендагы бакчада Тукай һәйкәле кайчан ачыла? Аның авторлары кемнәр?
3. Сез яши торган төбәктә (шәһәр, район һ. б.) нинди истәлекле урыннар бар? Шул турыда сөйләгез.
4. «Габдулла Тукай һәйкәле янында» дигән темага сочинение языгыз.

* * *

Казанда Габдулла Тукай музее шагыйрь исемен йөртүче урамның 74 нче йортында 1986 елның 11 июнендә ачылды. Әлеге ике катлы бина XIX гасыр ахырында төзелә (архитекторлар Т. Б. Руш һәм Ф. И. Амлонг проекты). Анда гасыр башында байтак еллар Төньяк Кавказ халыкларының милли-азатлык хәрәкәте җитәкчесе имам Шамилнең энесе Магом гаиләсе яши. Шуңа күрә бу бина халык телендә «Шамил йорты» дип йөртелә. Музейда китаплар, документлар, сәнгать әсәрләре, музыка уен кораллары, шагыйрьнең шәхси әйберләре, үзе исән вакытта басылып чыккан китаплары саклана. Тукайның дуслары, якыннарының фоторәсемнәре, чор күренешләре дә киң урын алган.

Габдулла Тукай музеенда темасына сөйләшү өчен сораулар*

1. Казанда Тукай исеме белән бәйле урыннар турында сөйләгез.
2. Тукай музее кайчан ачылган?
3. Тукай музее янындагы мәйданда кемнәр тарафыннан эшләнгән һәйкәл тора?
4. Тукай музеенда экспонатлар ничә залга урнаштырылган? Ул заллар ничек атала?
5. «Тукайның балачагы» дип исемләнгән залдан нинди экспонатлар хәтерегездә калды?

* Музейда булырга өлгермәгән читтә яшәүче укучылар әңгәмәне укытучы төзегән сораулар ярдәмендә шагыйрьнең аерым әсәрләре буенча уздыралар.

Әхмәт Фәйзи
(1903—1958)

Әхмәт Фәйзи (Әхмәт Әхмәтсафа улы Фәйзуллин) 1903 елның 11 мартында Уфа шәһәрендә вак һөнәрче (итекче) гаиләсендә туа. Ул 1911—1915 елларда мәдрәсәдә укый, аннан соң Уфадагы рус-татар мәктәбендә (1915—1917), татар гимназиясендә (1917—1921) белем ала.

Иҗат юлын 1916 елда шигырьләр язу белән башлаган Ә. Фәйзи сугышка кадәрге чорда ук үзен матур әдәбиятның төрле жанрларында актив эшләүче күпкырлы талант иясе итеп таныта. Аның иҗат уңышлары, беренче чиратта, поэзия белән бәйле. «Яңа җырлар», «Көрәш бара», «Чор турында җыр», «Эзләр», «Давыл җыры», «Дулкыннар ни сөйлиләр?» кебек җыентыкларындагы лирик шигырьләре шул хакта сөйли.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Ә. Фәйзи Мәскәү Әдәбият институтының өченче курсыннан үзе теләп фронтка китә һәм Волхов, Карелия, Дүртенче Украина фронт газеталарында хәрби корреспондент булып хезмәт итә.

Ә. Фәйзи — күп санлы сәхнә әсәрләре авторы да. Ул байтак кына комедияләр («Каеннар яфрак ярганда», «Беренче елмаю» һ. б.), сатирик пьесалар («Төтен», «Түрәкәй»), тарихи-биографик драмалар («Тукай», «Пугачёв Казанда») иҗат итә. Ә. Фәйзи татар операсына нигез салуда күп көч куя. Н. Җиһановның «Качкын», «Җәлил», М. Мозаффаровның «Зөләйха»

опералары, Р. Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балеты Әхмәт Фәйзи либреттосына язылган.

Ә. Фәйзинең тарихи-биографик жанрда язылган «Тукай» романы әдип иҗатында аерым урын били. Роман рус, казах, үзбәк һәм болгар телләрендә дә басылып чыга. Бу әсәре өчен аңа 1958 елда, язучылардан беренче буларак, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелә.

Ә. Фәйзи әдәби тәрҗемәләр авторы буларак та билгеле. Аерым алганда, А. Пушкинның «Борис Годунов» трагедиясен, «Братья-разбойники» («Юлбасар туганнар») поэмасын, Н. Гогольнең «Тарас Бульба» повестен, Т. Шевченко, В. Маяковский, А. Барто һәм башка шагыйрьләрнең күп кенә әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

ТУКАЙ

(романнан өзек)

Чыпталар өстендәге әлеге малайны асрамага Яңа бистәнең Мөхәммәтвәли исемле читекчесе алып кайтты.

Ул Сабитовларга читек тегә, ләкин чигүен-каюын Яңа бистәнең каючы хатыннарыннан эшләтеп ала, шул яктан ул бай белән ярлырак вак һөнәрчеләр арасында арадашлык итүче хәлле һөнәрче санала; шуның өстәвенә хатыны Бибигазизә дә шул ук Сабитовларга кәләпүш чигә иде.

Беренче хатыны үлеп, унсигез яшьлек Газизәгә яучы җибәргәндә, Вәли абзый кырыктан узган иде инде. Газизә, «бик карт түгелме соң?» дип, бераз чыгымчылап торды. Тик үзенең әнисе урынына калган апасы: «Газизә, тиләләнмә, чәченә-сакалына чал кермәгән кеше карт буламы? Шуннан да яшен табасы бар, тапкач та, әле аның дөнья күргән булуы, дәүләте, тәүфыйгы кирәк. Мөхәммәтвәлине һәммәсе мактый, үзе һөнәрле, үзе укымышлы, холкы әйбәт, үлгән хатынын да кадерләп кенә тотты»,— дигәч, аннан соң үзенең ятимлеген, апасының җилкәсендә гомер буе яши алмаячагын искә алып, Газизә риза булды. Торып киттеләр. Хәтта тора-бара Газизә бу кечкенә түгәрәк кара сакаллы, ягымлы гына соры күзле кешегә ияләшеп китте. Нәзегрәк озын төз буйлы, зур соры күзле, озынча алсу яңаклы һәм нәзек туры борынлы матур гына хатын иде Газизә һәм үзенә шактый ирләрне соклан-дыра иде. Шуны сизә торып, үзе берәүгә дә карамады. Күршеләренә кереп, әз генә утырса да: «Картлачым кайтыр, чыгыйм әле», яки «Вәлием кайтуына берәр җылы камыр ашы әзерләп куйыйм»,— дип тиз генә чыгып китү ягын карады. Ире өчен үлеп торды. Ике якның да көйсезләнеп алган чаклары булды. Әмма бу тормышның муллыгына, күңелләрнең тулылыгына күләгә төшермәде. Ал да гөл яшәделәр. Бер генә үкенеч икесенең дә йөрәген тырнады: бала юк иде. Мөхәммәтвәли абзыйның үлгән хатыныннан бер баласы булган иде булуын, әмма ул яшьләй дөнья куйды. И көйде, и көйде Вәли абзый. Газизәгә өйләнүенең төп сәбәпләреннән берсе дә бала булдыру иде югыйсә. Ә бала юк та юк! «Язмагандыр инде!» дип алар икесе дә язмышка буйсындылар, һәм бала булдыру хыялы асрарга бала алу нияте белән тәгәлләнде.

Менә бүген Мөхәммәтвәли алып чыккан читекләрен кибеткә тапшырып акча алган һәм, Газизә яраткан теге кытай марҗасы төшерелгән калай тартмалы чәй һәм аның янына бер кадак лампачи алып, Үтәмишевләр кибетеннән чыгып килә иде.

«Асрамага бала бирәм!» — дип кычкырды каршы яктагы арба өстеннән кемдер. Вәли абзый арбага якынлашты. Каптырмачы Мөхәммәтҗаннар әлеге кычкыручы сала кешесе белән кызу-кызу гына нидер сөйләшеп алдылар, Вәли абзый аны-моны ишетмәде. Балага карап аптырап калды ул. Дөрес, нәниләр һәммәсе диярлек бер-берсенә охшыйлар, әмма бу капчаган да куйган аның үлгән улы иде. Шундый ук моңсу кара күзле, калкурак борынлы, өске ирене алгарак чыгып, аскысы бераз эчкә җыелып тора. Ул хәтта аңа үз улының исеме белән дәшә язды, әмма вакытында исен җыеп:

— Исемең кем синең, улым? — дип сорады.

— Габдулла,— димәкче булды бала, әмма тавышы ни өчендер тамагында кысылып калды. Ул, күзәтү белән артык мавыгып, сөйләшергә әзерләнмәгән иде әле. Шуның өстенә Вәли абзыйның да соравы кинәтрәк булды. Шуңа күрә бала турында әлеге чыптачы сөйләп алып китте:

— Габдулла аның исеме, Габдулла, Кушлавычның мәрхүм Мөхәммәтгариф хәзрәт улы. Әтисе дә, әнисе дә вафатлар. Бик ипле, бик әйбәт бала...

«Миңа язган бала шушыдыр инде»,— дип уйлап алды Вәли абзый. Ул чыптачының арбасына менеп утырды, һәм алар өчәүләп Яңа бистәгә, Вәли абзыйның өенә юнәлделәр.

Йортлар һаман сирәгәя һәм вагая бардылар. Ниһаять, алар күлле һәм сазлы бушлыкка килеп чыктылар. Аннан авылныкы сыман бер катлы, иске өйчекләр тезелеп киткән урамга килеп керделәр. Үр менеп, дүрт-биш йорт үткәннән соң, ат искерәк кенә ике катлы агач өйнең ачык капкасына килеп керде. Вәли абзый, арбадан төшеп, Габдулланы кулына күтәреп алды, һәм алар, капка янындагы болдырның баскычын шыгырдатып, өскә — икенче каттагы фатирга менеп киттеләр. Вәли абзыйның хатыны Газизә апа аларны, күптәннән көтелгән кадерле кунак кебек итеп, бик ачык чырай белән каршы алды.

чыпта — мунчаладан сугылган тупас тукыма
читекче — читек тегүче
чигү-каю — материя яки күннең читен чигеп яки тегеп бизәкләр төшерү
арадашлык — якларның үзара килешүенә ярдәм итү
кәләпүш — түбәтәй
яучы — егеткә кыз димләп йөрүче
чыгымчылау — киреләнү
чәченә-сакалына чал керү — чәче-сакалы агару
дәүләт — *монда:* байлык
тәүфыйк — акыл
көйсезләнү — көе китү, бозылу
ният — теләк
лампачи — вак конфет (монпасье)

каптырмачы — кием һ. б. нәрсәләрдә эләктерү, каптыру өчен хезмәт итә торган җайланмалар эшләүче
исен җыю — фикерен туплау
хәзрәт — тиешле белеме булган указлы мулла
болдыр — өйалды баскычы

Сораулар һәм бирем

1. Вәли абзый кем ул? Аның һөнәре турында сөйләгез.
2. Вәли абзый һәм Газизә апа, үзара матур яшәсәләр дә, ни өчен борчылалар?
3. Асрамага тәкъдим ителүче малай кем ул? Вәли абзый ни өчен аны өенә алып кайта?

* * *

Өй түрендәге киезле сәке өстенә сары белән чуптарлап чиккән киҗеле ашъяулык җәелде. Бу Газизә апаның кайчандыр бирнә бүләге булып, хәзер шактый искергән, урта бер җиренә күк ямау салынган иде. Үзеннән зур бу томаннары бөркеп, пошкыра-пошкыра, табынга кечкенә җиз самавыр килеп утырды. Ул арада атын туарып өлгергән олаучы килеп керде һәм, сәлам биреп, кулындагы камыт белән шлеяларын ишекнең бер ягына сөяп куйды.

Үзеннән яшь икәнен күргәч, Газизә апа да аңардан качыпнитеп тормады, тик күтәреп бәйләгән яулыгын гына төшереп бәйләү белән чикләнде. Аннан ул самавыр янына килеп утырды һәм шаулатып чәй агызырга тотынды. Габдулланы ул үз янына утыртты, чынаяк тәлинкәсенә чәй салып бирде, шуның янына зур гына шакмак шикәр куйды. Аннан соң күмәч түтәрәменнән калын гына бер телемне каерып кисеп алды да:

— Юлда килә-килә ачыккансыңдыр инде син, улым, аша, туйганчы аша, җитмәсә сорап ал, үз өең кебек итеп утыр, яме,— дип, телемне Габдулла алдына куйды.

Мөхәммәтвәли абзыйның да, баланың күңелен табар өчен, бер-ике сүз әйтәсе килде:

— Аша, аша, минем улым буласың килсә. Тазарырга

тырыш. Беләкләрең хәзрәте Галинеке төсле булсын. Торткан җирдән ут чыгарырлык булып үс, пример әйтик...

Газизә апа олаучыны кыстый-кыстый чәй эчерә һәм Габдулла турында сораштыра. Олаучы Габдулла турында үзе белгәннең һәммәсен әйтеп бетерергә тырышып сөйли, сөйли... Үзе турында сөйләнгән хикәяне Габдулла үзе дә тыңлый, олаучы авызыннан бу бик кызык яңалык булып яңгырый, кайбер урыннары аны бөтенләй гаҗәпләндерә, шунда ул олаучыга карап-карап куя...

— Әтисе Мөхәммәтгариф Кушлавыч мулласы булган,— ди олаучы, хикәясен дәвам иттереп.— Мулла булса да, болай бик тормыш кешесе булган үзе. Чапанын салып, алъяпкыч кигән, җыеннарына җитешкән, уен-көлке сүзне яраткан... Урамда күмер сатучының: «Күмер! Күмер!» — дип кычкырып үтүен ишетеп, «Ишетәсезме, әнә ул да «Гомер! Гомер!» дип әйтә» дип, көлдерергә яраткан үзе...

«Гомер! Гомер!..» Бу сүз Габдулланың аңына томанлы үткәннең ерак төпсезлегеннән әтисен төсмерләтә торган бердәнбер сүз булып сеңеп кала.

Алтмыш чакрым арбада селкенеп килгән һәм бүген күргәннәренең һәм ишеткәннәренең тәэсире белән тәмам басылган хәлдә, Габдулла, табын янында утырган килеш, оеп йоклап китте. Аны, күтәреп, сәкегә илтеп салдылар... Икенче көнне иртән Габдулла уянып күзләрен ачты һәм, кайда ятканын төшенеп җитмәстән, үзен бабасы өендә ятадыр кебек тойды. Менә хәзер үги әбисе килер дә:

— Я, тор, мәрткә китмәгәнсеңдер бит,— дип кычкырыр төсле тоелды аңа. Әмма кемнәрдер шыпырт кына пышылдаштылар:

— Уяндымы әллә?

— Тимә, йоклый бирсен!..

Бу — Вәли абзый белән Газизә апа тавышы иде. Бу төн алар өчен тынгысыз төн булды. Алар әле берсе, әле икенчесе уянып, баланың өсте ачылмаганмы дип, торып карадылар, ачылмаган булса да, юрганын рәтләп яптылар, аның тәмле

йокы белән изрәп, кыска һәм җиңел генә тын алуын рәхәтләнеп тыңлап тордылар.

Габдулла аларның пышылдавына борылып карады. Вәли абзый аның уянганын күреп алды да:

— Ә! Уяндыңмы, разбуйник? Шулай диген! Я, я, шәп йокладыңмы? — дип кычкырып җибәрде һәм Габдулланың янына ук килеп утырды. Ул аның ябык аякларын тотып селкетеп куйды һәм сөйләнеп алып китте:

— Кәҗүл читек кигәнең юктыр әле синең, пример әйтик... Тегеп биримме үзеңә кәҗүл читек, ә? Әнисе, кара әле, читек тегеп бирим микән мин бу малайга? Әллә кирәк түгелме? Дәшми, пример әйтик... кирәк түгел, ахры...

Габдулла аның бу еш кабатлана торган «пример әйтик» һәм «ымм»ларына тора-бара ияләшеп китте, хәтта, әйтелешләренә карап, аларның төбендә нинди фикер ятуына хәтле төшенә башлады. Әмма хәзер аңа бу бик мәзәк тоела һәм ихтыярсыз көләсене китерә иде.

Газизә апа сәке янына килде дә, баланы Вәли абзыйдан көнләгән сыман:

— Я, кит әле, бала күзен ачып өлгермәгән, килеп бәйләнергә дә тотынды,— дип, ирен этәреп куйды, үзе Габдулла янына утырып, аңа әкрен генә дәште: — Я, күгәрченем, йокың туйдымы?

Габдулла дәшмәде, ул кичә җиделе лампа яктысында гына күргән бүлмәне бүген иртәнге кояш яктысында күреп өлгермәгән иде әле: менә нинди икән ул!

Озынчарак кечкенә бүлмә, түр тәрәзә, ян тәрәзә, тәрәзә төпләрендә чүлмәкләргә утыртылган тамчылы гөл, кына һәм яран гөлләре... ян тәрәзә янында кечкенә тәбәнәк өстәл, аның өстендә ниләр генә юк: чүкечләр, пычаклар, игәүләрме дисең, вак кына тимер һәм агач кадаклармы дисең, әллә нинди кәкре-бөкре агачлар, күн кисәкләре, шешәләрме дисең!.. Ә тәрәзә белән ишек арасында шүрлек, шүрлектә тезелеп киткән эрелеваклы калыплар. Шүрлек астында тактага тартылып куелган читек башлары...

— Синең кәжүл читегең нәрсә, менә мин аңа чуклы кәләпүш чигеп бирермен,— диде Газизә апа, һаман Габдулланың телен чишеп җибәрергә тырышты.

Габдулла күзен Газизә апага күчерде һәм аның калын гына кашлы моңсу күзләренә, ягымлы чыраена карап алды. Габдуллага кинәт бик, бик рәхәт булып китте. Аның бу рәхәтне озакка сузасы килде...

чуптарлап чигү — тукымага сугып төшерелгән бизәкләрне чигү
кижеле — киндер
бирнә — кияүгә чыккан кызның үзе белән алып килгән әйберләре, егеткә һәм аның кардәшләренә бирелә торган бүләге
камыт — ат муенына кидерелә торган җигү әйбере
шлея — ат күкрәген әйләндереп ала торган каешлардан гыйбарәт җигү әйбере
түтәрәм — дүрттән бер өлеш, чирек
хәзрәте Галинеке төсле — Гали хәзрәтнеке кебек
чапан — озын чабулы халат сыман кием
төсмерләү — хәтергә төшерү
табын — кунак, сый мәҗлесе
мәрткә китү — *монда:* тирән йокыга талу
изрәү — рәхәтләнеп йоклау
кәжүл читек — кәҗә күненнән тегелгән читек
игәү — металл, агач һ. б. әйберләрнең өске өлешен кырып шомарту өчен кулланыла торган эш коралы
калып — аяк киемнәре теккәндә кулланыла торган, аяк табанына охшатып агачтан ясалган форма

Сораулар һәм биремнәр

1. Өзекне укыгыз һәм эчтәлеге буенча план төзегез.
2. Газизә апа һәм Вәли абзыйга олаучы нәрсәләр сөйли?
3. Вәли абзый һәм Газизә апаның булачак уллары Габдуллага мөнәсәбәтләре турында сөйләгез.
4. Малай бу яңа йортны, аның хуҗаларын ничек кабул итә?
5. Тексттан файдаланып, Вәли абзыйларның өй эчен тасвирлагыз.

* * *

Аннан һәммәсе дә, йортка чыгып, олаучыны озатып калдылар. Габдулла әнисенең итәгенә тотынган килеш кире өйгә кермәкче булган иде, Газизә апа аңа:

— Габдулла, уйна шунда бераз,— диде һәм йортның түрендә балалар белән уйнап йөрүче ябык кына, сипкелле бер малайны чакырып алды:

— Әптелбәр, кил әле бире. Менә бу авылдан килгән бик әйбәт егет белән дус бул, яме. Йорт-каралтыны күрсәт. Кара, малайлар кагылып елата күрмәсен үзен, яме!

— Я,— диде Әптелбәр.

Газизә апа кереп китте. Әптелбәр буе белән үзеннән аз гына кайтыш Габдулланы кулыннан тотып тартты:

— Әйдә!

Габдулла тартылып куйды, ләкин урыныннан кузгалмады. Әптелбәр, шунда ук кулын Габдулладан ычкындырып, күлгә чыга торган капка янындагы иптәшләре янына йөгереп китте. Газизә апа әйткәнне ул шунда ук онытты, әлбәттә. Бераздан ул балалар белән урам капкасына йөгереп килде һәм әле һаман урыныннан кузгалмаган Габдулланы яңа гына күргәндәй:

— Карагыз әле, карагыз, сала малае! — дип кычкырды. Аннан соң ул ни өчендер, кулларыннан мөгезләр ясап, Габдуллага таба килә башлады:

— Мө-ә-ә-ә! Сөзәм, мө-ә-ә-ә!..

Габдулла урыныннан кузгалмады.

— Нигә качмыйсың? — диде Әптелбәр, гаҗәпләнебрәк.

— Сыер синнән көчлерәк,— диде Габдулла.— Безнең авылда сыер мәзин малаен сөзеп екты...

— Ә син ат кебек тибешә беләсеңме?

— Беләм,— диде Габдулла һәм белгәнен күрсәтергә ашыкты. Әптелбәр үз өстенә яны белән борылып тибенеп килүче кыю малайдан чигенеп куйды, ләкин бирешергә теләмичә:

— Ә синең тоякларың юк,— диде.

— Синең дә мөгезләрең юк,— диде Габдулла.

Бу әңгәмәне тыңлап торучы балалар көлешеп куйдылар. Әптелбәр гарьсенеп китте, ахры, Габдулланың башыннан кәләпүшен тартып алды да, аны өй түбәсенә ыргытырга җыенып, болгый башлады.

— Син тимә, тимә минем кәләпүшкә! — дип кычкырды Габдулла һәм бөтен көче белән Әптелбәргә ташланды.

Сәҗидә апасы үз кулы белән тегеп куйган корт башы бөтен авылда бер аның кәләпүшендә генә иде. Корт башын колакка куеп тыңласаң, анда әллә нинди ерак җил ыжылдавына охшаган тавыш килә. «Каф тавы артындагы дәрья шаулый»,—дип аңлата иде моны апасы. Аннан соң бу аның төсе иде. Ничек ул аны ыргытырга рөхсәт итсен?!

— Как не стыдно, Әптелбәр, нигә син кунак малайга тиясең? — дигән тавыш Әптелбәрне тыеп калды. Габдулла тавыш килгән якка карады... Өйнең өске кат баскычыннан сигезтугыз яшьлек сары чәчле кыз йөгереп төште дә Әптелбәр кулындагы кәләпүшне тартып алды һәм аны китереп Габдуллага киертте.

— Грубиян,— дип куйды ул, тагын бер тапкыр Әптелбәргә карап.

Бу — йорт хуҗасы Степан Иванович кызының кызы Аннушка иде. Ул, Габдулланың җиңеннән тотып, ярым русча, ярым татарча:

— Әйдә, мин сиңа кечкенә тавыклар күрсәтәм,— диде. Габдулла шунда ук берсүзсез аңа иярде. Калган балалар да аларга кушылдылар.

Аннан һәммәсе йорт түрендәге келәтнең артына чыктылар.

Монда бик куе булып кычыткан һәм әрекмән үсеп утыра, алар арасында үзенең кызгылт чәчәкләре белән, мин монда сезнең барыгыздан да матуррак дигәндәй, кукраеп, кырмавык басып тора иде...

Келәт артындагы койма почмагына барып җиткәнче, балаларга кычытканлыкны шактый авырлык белән үтәргә, берничә тапкыр: «Ай, кычыткан чакты»,—дип әрнеп алырга туры килде... Әптелбәр генә үзенең балчыкка катып чебиләп беткән аяклары белән юлны сайлап-нитеп тормый алдан бара бирде... Габдулла аның бу батырлыгын ошатты.

Ниһаять, алар зур әрекмәннәр белән капланган почмакка барып җиттеләр. Аннушка:

— Сез шуннан гына карагыз. Югыйсә чуар тавык үз янына кеше килгәнне яратмый,— дип кисәтте дә, алгарак чыгып, әрекмәннәрне аягы белән бер якка аерып куйды. Аннан «кур, кур!» дигән сукрану тавышы килде...

— Бу кыргый тавык,— диде Аннушка,— әни аны келәткә корзина эченә утыртырга тырыша, ә ул чыга да кача, чыга да кача. Бу урынны ул үзе табып утырган бит.

Кычытканлыктан чыккач, йортның икенче почмагында Габдулла эт оясы күрде. Аның янында йонлач кара эт башын ал аяклары өстенә куйган да йокымсыраган күзләре белән иренеп кенә балаларга карап ята... Габдулланың этне читләтеп баруын күреп, Әптелбәр аны тынычландырды:

— Курыкма, аның тешләре юк, хәзер ул карт инде, аңа чылбыр да кигезмиләр...

Аннары һәммәсе күл буена йөгерделәр, анда каз йоннары очырып һәм суга таш ыргытып «тәңкәләр» ясап уйнадылар. Әптелбәрнең «тәңкәләре» бөтенесенекеннән күбрәк чыкты. Габдулла аңа бу яктан да өстенлек бирде һәм аның баягы җәберләвен бөтенләй онытты. Ике арадагы ятсыну бик тиз бетте. Газизә апа Габдулланы өйгә чакыргач, Әптелбәр һәм Аннушка:

— Абдул, тагын чык,— дип кычкырып калдылар...

сипкелле — тәндә, күбесенчә биттә булып, бигрәк тә яз һәм җәй нык беленә торган саргылт яки коңгырт тимгелле
мәзин (мөәзин) — мөселман диненә хезмәт итүче кеше
гарьсенү — гарьләнү
дәрья — диңгез
кычыткан — чага торган үсемлек
әрекмән — киң, салынкы яфраклы үсемлек
кукраю — масаю
кырмавык — тигәнәк
сукрану — канәгатьсезлек белдерү
читләтеп бару — кагылмыйча, урап бару
чебиләү — аяк-кул тиресе яргалану

Сораулар

1. Габдулла ишегалдында кем белән таныша?
2. Әптелбәр Габдулла белән ничек сөйләшә? Алар арасында нинди бәхәс туа? Габдулла аңа ачуланамы?
3. Габдулланы кыен хәлдән кем коткара?
4. Аннушка кем ул? Ул балаларны кая алып бара?
5. Балалар анда нәрсә күрәләр?

* * *

Ян ишектән зур гәүдәле, бит-куллары һәм күн алъяпкычы башкаларныкы төсле кызыллы-сарылы буяуга каткан берәү килеп чыкты...

— Әнә, әнә минем әти! — дип, кычкырыр-кычкырмас, шатланып куйды Әптелбәр. Габдулла йотылып Әптелбәрнең әтисен күзәтте. Ул, чынлап та, киң җилкәле, озын һәм зур куллы, Габдулла бервакыт авыл җыенында күргән көрәшче кебек таза гәүдәле кеше иде. Кәрлә, кисмәккә күрсәтеп, аңа нидер әйтте. Нигъмәт ашыкмый гына кисмәк янына килде дә уч төбенә төкереп алды һәм, таза гәүдәсе белән янтая төшеп, кисмәкнең читеннән тотып тартты. Чуерны чуерга кырган сыман ниндидер тавыш чыгырдап китте. Кисмәк авыр гына кузгалып куйды. Аннан соң һәммәсе, хәтта әлеге кәрлә үзе дә: «Күтәрдекме? Күтәрдек! Әйдәме, әйдә!» — дип кычкыра-кычкыра, кисмәкне әкрен-әкрен кузгатып, тәрәзә ягына, башка кисмәкләр белән бер рәткә кучереп куйдылар.

Шундый көчле әтисе булган Әптелбәр Габдулла күзендә тагын да күтәрелде. Көчле булуы өстенә ул әле Әптелбәрнең үз әтисе бит... Бәхетле Әптелбәр!

Бу вакыйга Габдулланы Әптелбәргә тагын да ныграк бәйләде. Бүген Габдулла, дусының беренче чакыруы белән үк, кыстаусыз-нисез аларга керде.

Бүлмәгә килеп керү белән, ул аптырап калды.

Нигъмәтҗан абзый кебек галәмәт көчле кешенең баз кебек караңгы, дымлы һәм тар гына өйдә яшәве Габдуллага бик сәер күренде.

Дөрес, бүлмәнең җир идәне пөхтә итеп себерелгән, ике

тәрәзә арасына кәгазьдән киселгән челтәр ябыштырылган. Өстәл өстендәге калай самавыр агартылган. Тәрәзә төбендә яфраксыз гына булса да, кечкенә яра гөле тырпаеп утыра. Ләкин болар берсе дә бүлмәнең шыксызлыгын җуя алмыйлар, киресенчә, стеналарның дымлы караңгылыгын, кыйшаеп торган кечкенә тәрәзәләрнең моңсулыгын гына арттыралар.

Үз өендә тәрәзәдән кешеләрнең башларын гына күрергә өйрәнгән Габдулла өчен Әптелбәрнең тәрәзәсе чыннан да сәер. Аннан урамнан үтүчеләрнең аяклары гына күренә, һәм көн буе моннан кешеләр түгел, итекләр, кәвешләр, чабаталар, ботинкалар гына узалар...

— Безнең тәрәзә алдыннан үтүчеләрнең башлары да күренә,— дип, үзе дә сизмәстән, мактаныбрак куйды Габдулла. Әптелбәр кычкырып көлде:

— Нигә кирәк миңа аларның башлары?.. Мин аларны аякларыннан да таныйм,— диде ул.— Ә син танымыйсың... Менә бу кыйшык кәвеш үтеп китте, кем ул, беләсеңме? Һи, шуны да белми. Бу бит безнең күрше Шиһап. Ә менә бу итек башын өстерәп кем китте? Теге калыплар буйый торган Ванька... Аның атасы эчеп Кабанга батып үлде бит... Ә минем әти эчми... Әни аңа эчмәскә куша, ул тыңлый. Минем әни байларга күп итеп каеш каеп илтә. Ул аннан Нәсимә белән миңа бәлеш катылары алып кайта... Әй тәмле!.. Ә безнең Нәсимә беркөн сөт өстенә бармагын тыккан. Шуннан әни әй төшерде үзенә!..

Әптелбәр, сәке ягына карап, кемнәндер көлә башлады. Шунда гына Габдулла сәке өстендә, бизәге уңып беткән иске күк күлмәктән, тезләре өстенә ияге белән таянып, боларга моңсу гына карап утырган зур күзле, ябык кына кызны күреп алды.

— Бер дә төшермәде. Ә син әни шүрлеккә җыеп киткән борчак күмәчен урлап ашадың,— дип карулашты кечкенә Нәсимә. Шуның артыннан ук ул абыйсына телен чыгарып күрсәтте һәм, күрше малае алдында гарьсенеп, еларга тотынды. Әптелбәр аны үртәп алып китте:

— Елак, елкы колак! Елак, елкы колак!

Шул арада әниләре кайтып керде.

Ул кечкенә гәүдәле, күк күзле, арык кына хатын иде. Йорттагы кайберәүләр «теге чирләшкә хатын» дип кенә телгә алалар иде үзен...

— Тагын чыр-чу килеп беттегезме, җан көекләре! Чыгып китәр хәл юк инде миңа, үзәгемә үттегез инде сез минем, кадалып та бетмисез шунда,— дип әрнеде Әсма җиңги һәм йодрыгы белән балаларын дөмбәсләп алды. Аннан сәкегә утырды да кулы белән күкрәген тотып йөткерергә тотынды... Йөткереп туктагач, куллары белән тезләренә таянган килеш, хәл алыпмы, уйланыпмы утырды. Аннан балаларына борылып карады. Тегеләр икесе ике почмакта «мышык-мышык» елап торалар, шулай да бу аларга ара-тирә тел чыгарып, берберсен үчекләп алырга комачауламый иде. Әсма җиңги аларның икесен дә үз янына тартып китерде һәм икесен ике кулы белән кочаклап елый-елый сөяргә тотынды:

— Бигрәк бәхетсез булдыгыз шул, балакайларым, бигрәк бәхетсез булдыгыз... Элекке сәламәтлегем булса, мин сезне ал да гөл итеп кенә тотар идем дә бит. Нишләтәсең аны... дөньясы, каһәремә юлыккыры, дөньясы әшәке. Я, сөртегез күзләрегезне, җитте, менә хәзер самавыр куеп җибәрербез, байбикә дүрт шакмак шикәр төреп бирде, Алланың рәхмәте төшсен!..

Габдулла монда үзен артык хис итте һәм ишеккә юнәлде. Шунда гына Әсма җиңги, Габдулланы күреп:

— Кунак та бар икән, күрми торам, кая чыгып барасың, кунак егет, утыр әле,— дип, урыныннан торды. Бу вакыт Габдулла, чыгып, ишекне ябып өлгергән иде инде...

Ләкин бу ярлылык, чыр-чулы тормыш, «чирләшкә хатын» — берсе дә Габдулланың Нигъмәтҗан абзыйга карата күңелендә сакланган соклану һәм хөрмәт тойгысына кимчелек китерә алмады. Хәтта ул икенче көнне, Әптелбәрне күрү белән, үзе үк:

— Әйдә, синең этиеңне карарга барабыз,— дигән тәкъдим ясады. Алар тагын заводка киттеләр.

кәрлә — кечкенә буйлы
кисмәк — зур агач савыт, агач мичкә
чыгырдау — шыгырдау, яңгырау
галәмәт — искиткеч
сәер — гаҗәп
яра гөле — алоэ
шыксыз — ямьсез, күңелсез
кәвеш — йомшак күннән тегелгән кунычсыз аяк киеме, чүәк
төшерү — *монда:* дөмбәсләү, сугу, кыйнау
карулашу — каршы чыгу
каһәр — каргышлы җәза, каты ачу
тәкъдим ясау — *монда:* чакыру

Сораулар һәм биремнәр

1. Әптелбәрнең этисе Нигъмәтҗан абзыйны тасвирлагыз.
2. Әптелбәрләр яшәгән фатир, аларның тормышы Габдуллада нинди тәэсир калдыра?
3. Әптелбәрнең әнисе Әсма апа турында сөйләгез. Ни өчен ул балаларына «бигрәк бәхетсез булдыгыз» ди?
4. *Телгә алу, җан көекләре, үзәккә үтү, ал да гөл итеп тоту* сүзтезмәләрен сез ничек аңлыйсыз?

Нәҗип Думави
(1883—1933)

Нәҗип Думави (Нәҗип Сибгатулла улы Тахтамышев) 1883 елның 19 маенда Казан губернасы Чистай өязе (хәзерге Аксубай районы) Яңа Дума авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Авыл мәктәбендә һәм Кизләү мәдрәсәсендә башлангыч белем алган малай укуын Казанның Апанай («Касыймия»), «Иж-Буби» мәдрәсәләрендә дәвам иттерә.

Беренче империалистик сугыш вакытында (1915) Думави солдат хезмәтенә алына, фронттан яраланып кайта. Октябрь борылышыннан соң, 1917—1921 елларда Чистай шәһәре мәктәпләрендә, укытучылар әзерләү курсларында укыта, соңга таба өяз мәгариф бүлегендә инспектор булып эшли. 1921—1925 елларда туган авылында муллалык вазифасын үти, ликбезлар, төрле курслар оештыру өлкәсендә җитди эш алып бара.

Дагстан педагогия техникумында укытучы хезмәтен башкарган Думави 1925 елда гаиләсе белән Үзбәкстанга күченә, 1927—1933 елларда Сәмәрканд төбәгендәге уку һәм мәдәни-агарту йортларында, совет оешмаларында эшли.

Үпкә авыруыннан һәм ревматизмнан җәфа чиккән Нәҗип Сибгатулла улы 1933 елның 5 маенда илле яшендә Сәмәркандтан ерак булмаган Булунгур шифаханәсендә вафат була.

Думави — бай мирас калдырган әдип. Ул — шагыйрь дә, прозаик, публицист, әдәбиятчы-тәнкыйтъче, тәрҗемәче,

методика һәм педагогикага караган хезмәтләр язган автор да. Шагыйрь буларак, ул 1905 елгы революция тәэсирендә мәйданга чыга, изелгәннәр мәнфәгатен яклап «Революция заманы», «Государственная думага хитаб»(мөрәҗәгать), «Үтте, үтә...», «Себер», «Тавыш» һ. б. шигырьләрен иҗат итә.

Н. Думави матбугатта проза әсәрләре: повестьлар, хикәяләр, публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән дә актив катнаша. Аның «Болгар кызы Тойгы туташ», «Кем гаепле?», «Юкка үлде», «Алла тигезли», «Карт мөгаллимнәр» кебек әсәрләре үз вакытында аерым китаплар яки җыентыклар булып басылып чыга.

Әдипнең, балалар өчен язылып, мәктәп дәреслекләренә һәм хрестоматияләренә кертелгән «Авыл балаларының яңгыр теләве», «Яңгыр соңында», «Беренче кар» кебек шигырь һәм «Габдулла», «Зәки», «Мортый белән Мукай», «Бер баланың көндәлек дәфтәре» хикәяләре күп еллар дәвамында яратып укыла.

2003 елның маенда республика җәмәгатьчелеге Думавиның тууына 120 ел тулуны авторга олы ихтирам белән билгеләп үтте.

АЙЛЫ ТӨН

Йөзә тулган матур ай күк йөзендә,
Гаҗәп бер серле нур балкый йөзендә.

Шулай иркен, шулай бер серле балкый:
Көмеш сипкән кебек, җир өсте якты.

Күмеп ул йоклаган җирне көмешкә,
Нигә балкып тора соң ул? Ни эшкә?

Беләмсең, күз салып, ул саклый җирне,—
Бөтен урман, болынлык, кырны, илне.

Күрә ул барча әтраф, барча якны,
Күрә яхшы, яман, качкын, каракны.

Карый ул уңны, сулны, алны, артны —
Җитәрлек анда нур һәм серле якты.

Ниләр юктыр дисең аның күзендә:
Табарсың хәтта нур хайван эзендә!

Күрә ул өй эчендәге бишекне,
Карый һәм тар кабердәге тишекне...

1914

беләмсең — беләсеңме
этраф — тирә-як
яман — начар

Сораулар

1. Шигырьдә табигать матурлыгы ничек сурәтләнә?
2. Автор җир өсте яктылыгын нәрсә белән чагыштыра?
3. Табигать җисеме буларак кышкы төнге ай күренешен күзәткәнегез бармы?
4. Серле һәм нурлы ай турында халыкта нинди риваятьләр ишеткәнегез бар?

СИН — КЕШЕ!

Бирмә серне, бул гали — типсен йөрәк зурлык белән!
Булма мәхзүн —сынма төшенкелек белән, хурлык белән!

Бирмә тезгенне кара көчләргә — булма кол кеше!
Бул — батыр! Бул — нык кеше! Бул — ир кеше!
Бул — хөр кеше!

Син беләмсең синдә күпме көч барын, куәт барын?
Тип, очыр бу дөньяның барлык кара куәтләрен!

Син — бөек! Салган Ходай күктән сиңа үз орлыгын.
Бул — гали! Таптатма, зинһар, шул «Ходайлык»
зурлыгын!..

1916

гали — бөек, өстен, олы
мәхзүн — кайгылы, көенечле, моңлы
хөр — ирекле, бәйсез, азат
куәт — көч

Сораулар һәм бирем

1. Автор кешене, бөек зат буларак, нинди яхшы сыйфатларга ия булырга өнди?
2. Автор кешеләргә хас нинди сыйфатларны уңай, нindiләрен тискәре дип саный? Шуларны аерым-аерым билгеләп үтегез.
3. Шигырьдә авторның дингә мөнәсәбәте ничек чагыла?
4. *Таптатма, зинһар, шул «Ходайлык» зурлыгын!..* дигән шигъри юллар белән шагыйрь укучыга нинди фикер әйтергә тели?

Нәкый Исәнбәт
(1900—1992)

Күренекле драматург, шагыйрь, прозаик һәм галим Нәкый Исәнбәт (Нәкый Сираҗетдин улы Закиров) 1900 елның 10 гыйнварында хәзерге Башкортстан Республикасының Салават районы Малаяз авылында мулла гаиләсендә туа. Туган авылында, Уфадагы «Хөсәения», аннары Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрендә белем ала. Уфа, Харьков шәһәрләрендә төрле уку йортларын тәмамлагач, Казандагы химия-технология институтында татар теле һәм әдәбияты укыта. 1940 елдан, профессиональ язучы буларак, әдәби һәм гыйльми иҗат эше белән шөгыльләнә.

Нәкый Исәнбәтнең беренче шигырьләре 1914 елда «Ак юл» исемле балалар журналында басыла. 1914—1916 елларда аның поэмалары һәм драма әсәрләре дөнья күрә башлый.

Исәнбәтнең матур әдәбият өлкәсендәге иң зур уңышлары драматургия белән бәйле. Ул киң катлау укучы-тамашачыга «Һиҗрәт» (1923) исемле сатирик комедиясе белән таныла һәм алга таба комедия остасы булып китә. Аның тапкыр сүзле, юморга бай, гаделлек юлында теләсә нинди авырлыкларны да көр күңел белән җиңеп чыга торган мәшһүр фольклор герое Хуҗа Насретдин турындагы комедиясе татар сәхнәсендә берничә дистә еллардан бирле зур уңыш белән бара.

Нәкый Исәнбәт — татар халкының тел, әдәбият хәзинәләрен җыю, барлау, гыйльми өйрәнү һәм аларны бастырып чыгару өлкәсендә армый-талмый эшләгән зур галим дә. Аның тарафыннан әзерләнгән өч томлык «Татар халык мәкальләре», «Фразеологик сүзлек», «Татар халык табышмаклары» һәм балалар фольклоры җыентыклары — татар халык авыз иҗатын өйрәнүдә кыйммәтле хезмәтләр. Өч томлык «Татар халык мәкальләре» китабы өчен әдипкә 1968 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде.

Революциягә кадәр үк шигырьләр язып танылган Нәкый Исәнбәтнең күп кенә шигырьләре җыр-моң булып халык күңеленә күчә. «Уракчы кыз», «Син сазыңны уйнадың», «Туган ил» кебек җырлар шул хакта ачык сөйли.

Татар балалары өчен күп хезмәт күрсәткән, игелекле эшләр эшләгән, балалар дөньясын, аларның психологиясен яхшы белгән әдибебез ул — Нәкый Исәнбәт. Шигырьләр. Әкиятләр. Мәсәлләр. Уеннар. Җырлар. Табышмаклар. «Куян маҗаралары», «Мырауҗан агай хәйләсе», «Нәниләр шатлана», «Балалар дөньясы» исемле китаплар. Барысы да — балаларга булган тирән мәхәббәт нәтиҗәсендә туган иҗат җимеше.

Нәкый Исәнбәт — төрле милләт әдипләренең иң яхшы әсәрләрен татар укучыларына туган телендә җиткерүгә шактый көч салган сәләтле тәрҗемәче дә. Ул Пушкинның «Бакчасарай фонтаны», «Полтава» поэмаларын, «Таш кунак» трагедиясен, Мольерның «Тартюф»ын, Шекспирның «Гамлет»ы белән «Король Лир»ын, Грибоедовның «Акыллылык бәласе» комедияләрен татарчага тәрҗемә итте.

Нәкый Исәнбәт даими иҗат эше белән дәртләнеп, рухланып яшәде, татар халкының матур киләчәге өчен актив көрәш алып барды, иҗади хезмәт белән шөгыльләнде һәм яшь буынны белемле итүгә, тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертте.

ТУГАН ИЛ

Китми күңелемнән минем һич
Шул сөекле илкәем;
Анда сөйгән ярлы халкым,
Анда сөйгән әнкәем.

Анда таңнар җәйге диңгез
Балкуыннан нурлырак;
Анда җырлар сандугачның
Сайравыннан моңлырак.

Кайларга барсаң да, имеш, ди,
Бер кояш бар җиргә баш;
Юк, туган җирдә бүтән ул,
Анда тик чын, үз кояш!

Анда күк тә бик якын шул,
Җирдә үк йолдызлары.—
Күзләрен күрсәң, танырсың,
Нәкъ үз авылың кызлары.

Анда һәр кич киң басудан
Тәмле хуш ис аңкуы;
Анда айның җанга иркә
Һәм ягымлы балкуы.

Анда, сайрар кош шикелле,
Көй суза гармуннары,
Сызыла иркен тын һавада
Анда ил зар-моңнары.

Анда җырлый җирдә һәр таш,
Кул изи һәрбер агач.
Анда кайтсам, мин дә башка:
Анда мин дә сандугач!

1917

Сораулар һәм бирем

1. Туган илгә мәхәббәт нәрсә ул?
2. Н. Исәнбәтнең сөекле иленә, халкына, әнисенә мәхәббәте шигырьнең кайсы строфаларында аеруча ачык күренә?
3. *Анда җырлар сандугачның*
   Сайравыннан моңлырак
   дигән шигъри юлларның мәгънәсен аңлатыгыз.
4. *Анда җырлый җирдә һәр таш,*
   Кул изи һәрбер агач.
   Анда кайтсам, мин дә башка:
   Анда мин дә сандугач!
   дигән шигъри строфаның мәгънәсен ничек аңлыйсыз?
5. Туган җир, туган ил темасына нинди мәкальләр, җырлар беләсез?

СИН САЗЫҢНЫ УЙНАДЫҢ

Моңланып ай нурларында
Син сазыңны уйнадың;
Нинди кыллар чиртте, бәгърем,
Ул матур, яшь кулларың?

Бакчаның бер почмагында
Мин утырдым, тыңладым;
Тыңладым да мин ирексез
Яшьлегемне уйладым.

Уйладым мин яшьлегемне,
Син сазыңны уйнадың!

Кайгылы күңлем тавында
Яңгырады кылларың;
Яңрады ул моңлы кыллар...
Син сазыңны уйнадың.

Чыңлаган шул кылларыңдай,
Бер-бер үтте елларым;
Үтте айлар, үтте еллар,
Түзмәдем мин, егъладым.

Үтте айлар, үтте еллар,
Син сазыңны уйнадың!

Үткән ул даулы гомерләр,
Кан-көрәштә яңгырап,
Саклаганмын тик күңелдә
Шул көрәшнең моңнарын.

Аһ, терелттең син күңелнең
Бар күмелгән кылларын!
Яңрап үткән ул гомернең
Мин авазын тыңладым.

Яңгырап үтте гомерләр,
Син сазыңны уйнадың!

1925

саз — кыллы уен коралы
яңрады — яңгырады
егъладым — еладым

Сораулар

1. Кешенең күңелен нечкәртеп, тойгыларын уятучы, нәфисләндерүче һәм баетучы уен коралларыннан ниндиләрен беләсез?
2. Оста музыкантның сазда уйнавы шагыйрь күңеленә ничек тәэсир итә?
3. Тыңлаучының үткән тормыш юлын, башкарган эш-гамәлләрен хәтеренә төшерүдә, күз алдына китерүдә музыка коралының йогынтысы кайсы шигъри юлларда аеруча ачык чагыла?
4. Сез үзегез нинди музыка коралларында уйнаучы осталар чыгышын тыңларга яратасыз?

Гаяз Исхакый
(1878—1954)

Гаяз Исхакый 1878 елның 22 февралендә Казан губернасы Чистай өязе (хәзерге Чистай районы) Яуширмә авылында Гыйлаҗетдин мулла гаиләсендә дөньяга килә. Зирәк һәм сәләтле малай биш яшендә укырга өйрәнә. 1890 елда аны Чистай мәдрәсәсенә бирәләр. Анда алган белем белән генә канәгатьләнмичә, 15 яшьлек Гаяз 1893 елда Казанның Күл буе мәдрәсәсенә күчеп килә. Биредә ул төрек әдәбиятын тырышып өйрәнә, күп укый. 1898—1902 елларда Казан Татар укытучылар мәктәбендә белем ала, иҗат эше белән шөгыльләнә башлый. «Кәләпүшче кыз» исемле повесте, «Бай угылы» романы, «Өч хатын белән тормыш» драмасы аның беренче әсәрләреннән санала.

1902 елның көзендә Исхакый Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсендә мөгаллим булып эшли башлый. Ул анда табигать фәннәрен һәм рус телен укыта.

Хөкүмәткә каршы юнәлтелгән «крестьяннар арасында җинаятьчел агитация»дә гаепләнеп, Г. Исхакый 1907 елда Архангел губернасына өч елга сөргенгә җибәрелә. Мондый авыр шартларда да ул «Зиндан», «Солдат» повестьларын, «Теләнче кызы» романының 2 нче кисәген һәм «Алдымбирдем», «Тартышу», «Мөгаллим» кебек пьесаларын иҗат итә.

Сөрген елларының бер өлешен (1908—1911) Исхакый Төркиядә үткәрә, бу елларда әдәбиятыбызны төрле жанрда язылган зур күләмле әсәрләре белән баета.

Гаяз Исхакый — татар театрының тууында, үсешендә зур роль уйнаган шәхес. Рәсми татар театрының туган, тарихта теркәлгән көне Уфада 1906 елның 21 апрелендә аның «Өч хатын белән тормыш» драмасы куелуга бәйле.

1917 елгы Февраль революциясен шатланып каршы алган булса да, Исхакый Октябрь революциясен, Совет властен кабул итә алмый, чит илгә китә. Туган иленнән, үз халкыннан аерылгач, ул Харбин, Париж, Берлин, Варшава һ. б. шәһәрләрдә яши. Әдип, «Милли юл» дигән нәшрият булдырып, татар эмигрант язучыларын шул тирәгә туплый һәм «Милли юл», «Яңа милли юл», «Безнең байрак» дигән газета-журналлар чыгара. Татарча китаплар да шул ук нәшриятта басыла.

Эмиграциядә Г. Исхакый проза, драма өлкәсендә эшләвен дәвам итә. Алар арасында «Көз», «Өйгә таба» романнары, «Локман хәким» исемле хикәя-әкияте, «Дулкын эчендә», «Жан Баевич», «Олуг Мөхәммәд» кебек драма әсәрләре игътибарга лаек.

Гаяз Исхакый 1954 елның 22 июлендә вафат була, Төркиянең Истанбул зиратында күмелә.

Талантлы прозаик, драматург, публицист, журналист, җәмәгать эшлеклесе Г. Исхакыйның бай мирасы озак еллар махсус ябык фондларда бикләп тотылды, әдипнең эшчәнлеге бозып аңлатылды. Әмма хаклык җиңде, Гаяз Исхакый тулысынча акланды. Хәзер аның бай әдәби иҗаты укучыларга җиткерелде.

Татарстан Республикасы Язучылар берлеге 1991 елда Гаяз Исхакый исемендәге премия булдырды.

КӘҖҮЛ ЧИТЕК

(кыскартып алынды)

Минем әти бүген Казаннан кайта. Улмы? Ул миңа саплы калач китерә. Аннары миңа читек китерә. Өр-яңа читек.

Аның саурысы синең апаңның намазлык чигә торган үрнәге кебек чәчәкле була.

Аның олтаны — болгар олтаны, кырыеннан киселгән. Ярып ук киселгән. Үзе кып-кызыл төсле. Кура җиләге төсле кызыл түгел, зияб төсле кызыл.

Аның балтыры шадраланып тора, чем-кара.

Миңа әти кәҗүл читек китерә...

Иртәгә гаеткә мин кәҗүл читек киеп барам.

Беләмсең, Миңлегали?

Минем читекнең балтырының очы кып-кызыл иттереп тар сәхтиян токкан була, ул әнинеке кебек түгәрәкләнеп беткән булмый... тип-тигез киселгән була.

Ул әкертен генә шыгырдый. Солдаттан кайткан Фәхри малаеның итеге шыгырдаган кебек түгел, шыгыр-шыгыр шыгырдый...

Безнең әни иртәгә бәйрәм ашы пешерә. Әйдә, тизрәк чабыйк. Кәтү тиз керсен иде дә, сыерларны тиз табып кайтсак иде.

Әйеме, Миңлегали?

Миңа иртәгә гаеткә киеп барырга әби чапан тегә, минем чапан җем-җем итеп тора. Әби әйтә: «Мондый чапанны бохар патшасының угылы гына киядер,—ди.—Ул саранжы»,—ди... Ул әле өр-яңа! Өр-яңа! Әби әйтә: «Саранжы искерми»,— ди.

Ул этинең ашка йөри торган чапаны иде. Аның җиңнәре миңа нәни генә була.

Ямь-яшел!..

Мулла абый миңа иртәгә чалма чалып бирә.

Мин гаеткә барам...

Минем кәвешем әле өр-яңа... Өр-яңа... Мин аны кимәгәнгә, әзрәк кибеп киткән... Әби әле аны суга салып куйды. Аннан соң әби каз мае белән майлый, ул өр-яңа була.

5*

Өр-яңа!..

Әти миңа прәннек тә алып кайта.

Мин сиңа да бирермен...

Миңлевәли малаена бирмим... Бая туп уйнатмады.

Чү-кә!.. Әйе, әнә көтү күренә. Тиз бул. Чап! Син күпернең Шәмсиләр ягында тор, мин югары оч ягында.

Ишетәмсең, Миңлегали?

Әнә, әнә чылтыр-чылтыр тырантас чылтыраганы ишетелә.

Ул безнең тырантас.

Мөәзиннәрнеке бит тимерле түгел.

Мулла абый әтине Казаннан алып кайта.

Миңа читек алып кайта.

Йөгер. Әнә сыерлар су эчәргә төштеләр...

— Миңлегали, Әхмәдулла! Миңлегали, Әхмәдулла!

— Нәрсә?

— Минем ак башлы тананы югары очка җибәрмәгез әле... Иртәгә борчак белене бирермен...

— Миңа синең борчак белененң кирәкми, безнең әни коймак пешерә.

— Безнең әни кыстыбый ясый... Алып кайтыш инде. Җизниләр бакчасында көнбагыш бар, сезгә дә бирермен... Әйдә. Тиз! Миңа әти яңа читек алып кайта, кәҗүл читек...

— Әхмәдулла!.. Әхмәдулла!.. Әтиең кайтты!.. Әтиең кайтты!

— Әйдә ку, Миңлегали! Ку!

— Әби, сыерны куып алып кайтма, каймагы чайпала, ди. Минем әти кайткан, миңа кәҗүл читек алып кайткан... Өр-яңа кәҗүл читек. Әнә тырантас... Әй җаным, тырантас... Кара, алаша, мескен, тирләгән... Минем читек авыр микәнни?..

— Әхмәдулла, Әхмәдулла! Сыерларны алып кайттыңмы?

— Кайттым, әби, кайттым.

Әнә Рәбига тәрәзәдә, кулына нәни генә каймалы читекләр тоткан...

— Әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый. Яңа читегем, яңа читегем... Абый, абый, яңа читегем...

— Бик исем китте. Үземә дә әти яңа читек алып кайткан... Миңа — мулла абзыйныкы кебек — кәҗүл читек.

сауры — ат тиресеннән эшләнгән күн
зияб (зяблик) — кызылтүш
гает — мөселманнарның дини бәйрәме
сәхтиян — кәҗә яки сарык тиресеннән эшләнгән йомшак күн
саранжы — саржа (тукыма)
чалма — мөселманнар кия торган баш киеме

Сораулар һәм бирем

1. Әхмәдулла ни өчен әтисенең Казаннан кайтуын аеруча шатланып көтеп ала? Ул нәрсә турында хыяллана? Тексттан файдаланып, аның хыялын — читекне тасвирлагыз.
2. Гает бәйрәме турында син нәрсә беләсең?
3. Әхмәдулла, яңа киемнәрен киеп, кая барачак?

* * *

Әти түр башына утырган, аның янына — мулла абый. Самавыр гаеткә дип ачылган, самавыр көлә-көлә җырлый. Әни чәй ясый, әби әллә нәрсә сөйли.

— Әйдә, угылым, әйдә, угылым, әйдә, Әхмәдулла бәбкәм!

Әни баштан сыйпый, әби аркадан кага.

— Кил, угылым, үз яныма утыр.

Әти мине үз күршесенә утырта.

Рәбига нәни генә читекләрен кочаклаган да кулы белән сыйпап сөя, битенә китерә, үбә, тиле!..

— Әти, миңа читек алып кайттыңмы?

— Кайттым, угылым, кайттым. Әнисе, Әхмәдулланың саплы калачын бир әле.

— Саплы калач, саплы калач, әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый!— Мин Рәбиганы кызыктырам.

— Синең саплы калачың юк...

— Минем читегем бар, минем читегем бар.

— Минем дә читегем бар, минем дә читегем бар. Әти, читегем кая?

— Кәҗә Вәли килененең угылы кызамык чыгарган икән, угылым, ул сиңа дигәнне ураза гаетенә генә өлгертәм диде... Аннан Миңлесәхип апаларның кодаларыннан гына алдым.

Мулла абыйга:

— Кая әле, Фәхрулла, Әхмәдулла читеген бир әле. Зур булмаса ярар иде, угылым.

Абый көлемсерәде.

Мин:

— Юк, юк, булмый. Минем нәни генә читегем була. Нәни генә. Әти! Кәҗүлме?

— Кәҗүл, угылым. Менә читек...

Бу читек бөтенләй башка. Аның олтаны да кып-кызыл. Битлекләре, балтыры да дулкынланып тора. Ләкин... Ул ни дип соң Кәҗә Вәли килененең угылы кызамык чыгарган?

— Я, ки, угылым, я, ки, зур булмасмы? Зур булса, мулла абыеңа бирерсең...

Читекнең эченә тәпиләремне тыгам. Аның төбенә аягым барып җитми. Тирә-юньнәрендә минем балтырларым-чалтырларым кысылып, кочакланып тормый.

— Тор, угылым, тор...

Мин торып бастым. Читекнең куныч бот төбенә җитте. Аяк башым аның төбен барып таба алмады. Мин төбенә аяк җитми торган суга чумган кебек булып киттем.

— Зурракмыни?.. Тегүче Хисами да юк бит шуны кечерәйтергә... Анда ук әйттем, безнең Әхмәдулланың тәпиләре әле нәни генә булыр, дидем. Миңлесәхип абыстаңның кодасы: «Юк, булмас, хәзрәт, мәхдүм үсәр әле. Бу елгы гаеткә зур булса, киләсесенә чак булыр»,— ди.

Рәбигә, тиле, һаман: «Әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый!» — ди. Бик исем китә инде. Минем үземнең дә читегем бар... Бар шул!

Мин читекне әйләндереп-әйләндереп карадым... Тагы киярге аякларымны керттем, тагы икесе дә төбенә барып җитә алмады.

— Эч, угылым, чәеңне. Әнә саплы калачыңны ал.

Мин читеккә карадым, караган саен ул миңа дошман төсле күренә килде. Мәхәббәтсез читек, дәүкәди читек...

— Рәбигә, әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый... Минем чапаным бар!..

— Бар, бәбкәм, бар...

— Минем чыбыркым бар...

— Минем курчакларым бар...

— Тиле! Малайлар курчак уйныймыни? Мин катымша түгел.

— Эч, угылым, чәеңне. Иртәгә менә мулла абыең үзеңә чалма чалып бирер. Чапаныңны киярсең. Читегеңне әллә, угылым, гаеткә киеп барырга мулла абыеңа бирәмсең? Аның, мескеннең, гаеткә читеге дә иске...

Мин күземне күтәреп карадым, читек тә кызганыч, мулла абый да кызганыч. Бәхетсез читек, нәни түгел читек! Бу кәҗүл дә түгелдер әле... Түгел!

Мин читекләрне мулла абыйга суздым.

Әти, әни һәм әби һәммәсе:

— Менә рәхмәт, менә рәхмәт, мулла абыең сиңа чалма чалып бирер. Киләсе гаеткә Кәҗә Вәли килененең угылы кызамыктан терелер дә, сиңа нәни генә, үзеңнең тәпиләрең кебек кенә читек килер. Казанның үзеннән, «Ошбу читек тапшырылса иде Габдулла авылында Әхмәдулла мәхдүмгә» дип, атыңа язылып килер. Килер шул!

Мин ураза бәйрәмендә өр-яңа кәҗүл читек киеп гаеткә барырмын.

«Әти! Ураза гаете еракмы?» — дияргә башымны күтәрдем. Мулла абый, әти, әни бер-берсенә карашып елмаешып торалар.

Миңа, бердән, минем хәзер дә читегем юк, ураза гаетендә дә читегем булмас, аннары да булмас кебек тоелды. Тамагымны әллә нәрсә кытыклады, борынга әллә ни тулды, күзне әллә нәрсә юешләтте. Биттән кайнарланып әллә нәрсә агып төште...

«Минем читегем юк, кәҗүл читегем юк»,— дип, әллә кем минем эчемдә сыкранып кычкырына башлады.

Мин тавышланып еларга тотындым. Саплы калачны алмадым. Чәйне эчмәдем. Акырып барып мендәргә яттым; мине әти дә яратмый, миннән мулла абый да көлә; мине әни дә, әби дә сөйми... Читегем юк... Рәбиганың читеге бар, минем читегем юк.

Әни торды.

— Ни булды сиңа, угылым? Синең бит читегең бар, тик Кәҗә Вәли килененең баласы кызамыктан авырганга, нәни генә өлгермәгән.

Әби:

— Менә мин сине акыллы дип чапан тектем. Син зур башың белән елап утырасың.

Әти дә:

— Елама, елама! Алай булса, мулла абыеңны кызганмасаң, киеп бар.

Минем күз алдыма тагы шул мәхәббәтсез читек килде. Мин тагы кычкырып еладым.

Әни:

— Тукта инде, акыллы бул. Мә, алай булса, үз читегемне бирәм.

Әни каймалы зәңгәр җирлекле читек күтәреп килде:

— Мә, ки, үзеңә булсын.

Рәбига, почмакта читеген кочаклап:

— Мин бирмим, мин бирмим,— дип акырырга тотынды.

Тиле, мин катымшамыни хатыннар читеген кияргә!

Мулла абый:

— Мин сине зур булды, мәдрәсәгә алып барырмын дип тора идем. Син анда да шулай елап йөдәтерсең, алмыйм инде,— диде.

Әби:

— Мин сиңа үзем кәҗүл читек тегәм, үзем тегәм. Менә күр дә тор, үзем тегәм. Иртәгә чапаныңны киярсең. Читегеңне киярсең. Мәхдүм булып гаеткә барырсың.

Мин күземне ачтым. Рәбига, тиле, авызын ыржайтып елап утыра. Тиле! Гарәфә кичендә еларга ярыймыни?.. Тиле! Фәрештәләр тәсбих әйткәндә еларга ярыймыни? Әти авырсынмыймы ни?

Фәрештәләр тәсбих әйткәндә еларга ярыймыни? Әти авырса нишләрсең?

Мине җилтерәтеп самавыр янына алып киттеләр. Әни чәй ясады. Әти бал кашыгы белән бал алып бирде. Әби чапанымны, яшел чапанымны кигезеп карады.

— Бар да тәмам. Өр-яңа чапан, төймәсен генә тагасы бар. Иртәгә менә читек тә өлгертәм.

— Нәни читекме, әби?

— Нәни читек, угылым.

— Кәҗүл читекме, әби?

— Кәҗүл читек.

...Ындырлар артына сыерлар ашатырга чыктым. Иртәгә минем кәҗүл, нәни читегем була.

Караңгы төшеп өйгә кайтканда, әби түр башында утырган да, колак артларына җеп белән эләктергән күзлеген киеп, чынаяк астлыгында ак май белән корымны бергә изеп маташа. Аның янында әнинең иске читеге.

— Әби, нишлисең?

— Бар, ят, угылым, бар. Әнә Рәбига акыллы кыз, күптән йоклый. Иртәгә гает бит. Гаеткә тора алмассың. Бар, ят.

— Әби, читегем өлгермәдеме?

— Юк әле, юк. Мин аны намазымны укыгач кына тегәм. Бар, ят.

Әбинең миңа читек тегүен, кәҗүл читек тегүен күрәсем килсә дә, гаеткә тора алмам дип яттым.

Юрганның кырыеннан гына әбинең нишләгәнен карап яттым. Әби аркасы белән утырганга, нишләгәне күренмәде.

Бүлмә тактасының шәүләсендә генә аның калын бармаклары әллә нәрсә өстеннән бик кызулап йөргәне, аның әллә ни ышкыганы шәйләнде.

Минем күз алдыма нәни генә читек, кәҗүл читек килеп басты. Ул минеке.

Кил, кил, кәҗүл читек. Иртәгә гает, кәҗүл читек, иртәгә гает!

кызамык — авыру (корь)
балтыр-чалтыр — аякның тездән аскы өлеше
мәхдүм — дин башлыкларының ир балаларын шулай атыйлар
чак булу — ярау, туры килү
дәүкәди — зур
атыңа — исемеңә
гарәфә көн — гает алды көне
намаз — мөселманнарның көненә биш мәртәбә үти торган гыйбадәте

Сораулар һәм бирем

1. Әхмәдулланың сөенү һәм борчылу сәбәпләрен аңлатыгыз.
2. Әхмәдулла читеген кемгә бирә?
3. Малайның әти-әнисе, әбисе, өлкән абыйсы сездә нинди тәэсир калдырды?

* * *

— Тизрәк, угылым... Әтиең китте. Әнә мулла абыең сиңа чалма чалырга көтеп тора. Тор, балам, тор. Бүген бит гает.

— Әби! Читекне бетердеңме?

— Бетердем, бетердем...

Мулла абый калын гына тавыш белән:

— Тизрәк, Әхмәдулла. Миңа барырга вакыт!

Күлмәкне алай-болай киеп, кыска җиңле казакине кия-кия түргә чыктым. Анда әби чапан тоткан. Мулла абый чалма тоткан.

— Кил, утыр... Я, элгәре уң кулыңны бир!

Әби чапан кидерде.

— Утыр, Әхмәдулла, утыр.

Мин чәч ала торган тәбәнәк урындыкка утырдым.

— Башыңны туры тот!

Мулла абый акрын гына минем баш тирәсендә кызыл телемҗуллы ак чалманы сарырга тотынды.

Әби әллә кайдан балтыр чүпрәкләр белән читек алып килде.

— Әби, читекме?

— Читек, угылым.

— Кәҗүл читекме?

— Кәҗүл, угылым.

Мин күзем белән кәҗүл читекне эзләргә тотындым: кап-кара читек тора.

— Әби, күрсәт!

Мулла абый калын тавыш белән:

— Башыңны борма! Чалмаң бозыла.

Мин, яхшы айгыр кебек, муенымны туры тотам. Әби минем аякларга балтыр чүпрәк урады... Уң аякка читек кигезде.

Минем күңелгә рәхәт кереп китте. Мин тагы аягымны, кәҗүл читекле аягымны карарга башымны бордым. Мулла абый тагы: «Тик тор!» — диде.

Менә әби икенчесен дә кигезде.

Чалма да чалынып бетте,

— Я, тор, Әхмәдулла.

Тордым. Аяктагы читек кап-кара булып, җем-җем итеп тора.

Чапан — ямь-яшел.

Чалма — чуп-чуар.

Әби:

— Менә нинди зур шәкерт булды,— дип, аркамнан какты.

Әни килеп, ислемай сөртенә торган мулла абыйга:

— Әхмәдуллага да хушбуй сөрт,— дигәч, мулла абый ислемай шешәсенең тыккычы белән минем борын төбеннән бер сызып узды.

Борынга әти исе керде.

Мулла абый: «Я, тиз бул!» — дип кызулагач, мин әле чапаныма, әле читегемә карап өй алдына чыктым.

Анда минем әле өр-яңа, әби кичә генә каз мае белән майлаган кәвешем кечкенә булганга, мин әбинең яшел башмагын гына киеп киттем.

Мәчет йортында әллә никадәр халык җыелган. Мулла абый барып җитеп тамак кыргач та, бар да торып юл бирде. Ул алга, алга китте. Мин дә, малайлардан узып, аларның алдындагы сафка утырдым.

Мин мулла малае! Минем чалмам, чапаным, читегем бар!..

Иртә намаз укыдык. Әти вәгазь сөйләргә тотынды. Мөәзин абзый: «Сафланыгыз!» — дип, кешеләрнең аякларына тибеп йөрде.

Әтигә, мулла абыйга бөтен кеше, берсе арты берсе барып, акча биреп килделәр. Минем артта малайлар кызыгып карап торалар.

Ә шулаймы? Таз шайтан! Миңа шалкан бирмәгән идең. Ә алаймы? Минем чапаным бар! Минем читегем бар, кәҗүл читегем бар!

Мин кулым белән читегемне тотып карадым: йоп-йомшак, майлы кебек.

Менә кояш чыкты. Мәчет йорты тирәсенә киенгән-бизәнгән кызлар, хатыннар, малайлар тулды. Барысы да миңа карый: «Әнә Әхмәдулла! Әнә Әхмәдулла! Әнә аның чапаны ямь-яшел, әнә аның чалмасы чуп-чуар!» — ди.

— Туктаңыз әле. Гает намазына торыйк, аның кәҗүл читеген дә күрерсез.

Менә мөәзин абзый әллә нәрсә сөйләде. Менә зур тавыш белән әти: «Аллаһы әкбәр!» — диде.

Һәммә кеше кулын күтәрде, төшерде. Мин дә күтәреп төшердем.

Арттан теге Таз, аның артыннан тагы әллә кем, берәмберәм көләргә тотындылар.

— Әхмәдулла әнисенең читеген кигән, Әхмәдулла әнисенең читеген кигән!

Малайлар пырхылдады.

— Әнисенең читеген кигән, әнисенең читеген кигән...

Мин серне белдермәскә тырыштым.

Әти кычкырып «Әлхәм» укырга тотынды.

Малайлар һаман «әнисенең читеген кигән» дигәнне такмалаудан бушамадылар.

«Ә, Таз! Көнлисеңме? Кәҗүл читектән көнлисеңме?»

Менә рөкүгъга киттек.

Ни күзем белән күрим! Минем читегемнең битлеге бөтенләй кып-кызыл. Балтырының кайбер җирендә кап-кара нәрсә ялтырап торса да, кай җирләрендә кызылланып киткән, ул ала-кола.

Рөкүгъда малайлар «Сөбханә раббелгазыйм» урынына: «Әнисе читеген кигән...» — диләр.

Түгел, ул болай гына кызарган. Минем чапаным да бар. Чапаным ямь-яшел.

Менә тагы тордык. Малайлар «пырых-пырых» көләләр:

— Әхмәдулланың чапанына корым ягылган! Кап-кара корым...

— Әнисенең читеген кигән. Әтисенең чапанын корымлаткан...

Тагы рөкүгъга бардык.

Ни күзем белән күрим: чапанымның алгы чабулары дегеткә буяган кебек кап-кара булган.

Әттәхияттә малайлар:

— Әнисенең читеген кигән, әнисенең читеген кигән, әнисенең читеген кигән, катымша, катымша,— дип укыдылар.

Әти сәлам бирде.

Аллаһы әкбәр! Бөтен халык сикереп торды. Мине малайлар чормап алдылар.

Һәммәсе авызын җәйгән, һәммәсе көлә: «Әнисенең кызыл читеген кигән».

Мин һаваланып кына:

— Таз шайтан, айбагар карагы,— дип киттем. Барып башмакларны кидем.

Малайлар тагы гөж иттереп көлделәр.

— Әбисенең башмагын кигән, Әхмәдулла әбисенең башмагын кигән.

Карасам, чын да әбинең башмагы. Әнинең Сәрви әби өстеннән килгән кызыл читеге. Аның балтыры бешердәп төшкән. Аның эченнән балтыр чүпрәгенең очлары күренеп тора.

Яшел чапанның бер җире ямь-яшел, бер җире кап-кара булып корымлы майга буялган...

Бер малай төртеп җибәрде. Икенчеләре көлеп куйдылар. Тагы берсе төртте. Минем бер башмагым аяктан чыкты, аны кия алмаганга кулыма алдым. Берсе чалмамның койрыгыннан тотты. Ул сүтелеп китте.

Малайлар тагы көлә. «Әнисенең читеген кигән!» дигәнне көйләргә керештеләр. Мин кызу-кызу атларга башладым. Берсе чабуымнан тотты. Мин аның кулын тешләдем. Берсе сүтелә башлаган чалманың очын алып китте. Мин аны куа башлагач, икенче башмагым төште.

Капка төбенә җиткәндә әбинең:

— Оятсызлар, кая, колагын кисим! — дигән тавышын ишеттем. Күземә яшь тулды.

Умарта кортыннан качкан кеше кебек капкадан атылып кердем. Урамнан гөж итеп малайларның көлүләре, «әнисенең читеген кигән» дигән такмаклары мине озатты. Хушбуй исле сумса, пәрәмәч тәме чыккан өй каршы алды.

Әбинең:

— Бәйрәм мөбарәк булсын, угылым,— дип аркамнан кагуына, мин акырып елап җибәрдем.

элгәре — башта
казаки — озын камзулга охшаган, озын җиңле өске кием
сару — урау
вәгазь — үгет-нәсыйхәт
Әлхәм — Коръәннең беренче сүрәсе, Аллага дан җырлау
рөкүгъ — намазда иелеп тору, тезләнү
Әттәхият — намазда тезләнеп утырып укый торган дога

Сораулар һәм биремнәр

1. Әхмәдулла гает бәйрәмен ничек каршылый?
2. Туганнары Әхмәдулланы гает бәйрәменә ничек киендерәләр? Тасвирлап күрсәтегез.
3. Ни өчен иптәшләре Әхмәдулладан көләләр? Алар дөрес эшлиләрме?
4. Сезнең гаиләгездә дин тотучылар бармы? Мөселманнарның нинди бәйрәмнәрен беләсез?
5. Бүлекләргә исемнәр куегыз.

Мәҗит Гафури
(1880—1934)

Татар һәм башкорт халыкларының уртак язучысы Мәҗит Гафури 1880 елның 1 августында Уфа губернасы Эстәрлетамак өязе (хәзерге Башкортстан Республикасы Гафури районы) Җилем-Каран авылында туа. Мәҗит башта — үз авылында, аннары күрше авыл мәдрәсәсендә укый. Унбер яшендә ятим кала. Җәен ялланып төрле эшләр башкара, ә кышын укуын дәвам итә.

Мәҗит яшьтән үк тормышның ачысын-төчесен татып, халыкның кайгы-хәсрәтен, шатлык-юанычларын күреп үсә. Болар исә аның булачак әсәрләренә бай материал бирә. Мәдрәсәдә укыганда ук ул беренче әсәрләрен яза.

1904 елда Гафури Казанга килә. Аның бер-бер артлы шигырьләре, поэмалары, хикәяләре басылып чыга. Әсәрләрендә ул халыкның авыр тормышын, киләчәккә өметен чагылдыра. «Сарыкны кем ашаган?», «Үгез белән Бүре» һ. б. мәсәлләре белән татар әдәбиятында мәсәл жанрына нигез сала.

Аның әсәрләре рус, украин, казах һ. б. телләргә тәрҗемә ителгән. М. Гафуриның табигать матурлыгын сурәтләгән, тарихи вакыйгаларга үз мөнәсәбәтен ачык белдергән шигырьләре, «Шагыйрьнең алтын приискасында», «Кара йөзләр» һ. б. әсәрләре киң катлау укучылар тарафыннан яратып укыла.

М. Гафури 1934 елның 28 октябрендә Уфада вафат була.

ГӨЛЛӘР БАКЧАСЫНДА

Беркөн шулай гөлләр бакчасында
Чәчәкләрне кылдым тамаша;
Хуш исләре белән җан шатлана,
Нурларыннан күзләр камаша.

Нәфис төсләренә, буйларына
Хәйран калып, кызыгып карадым;
— Әй чәчәкләр, сезгә кемнәр дуслар?
Кемнәр дошманнар? — дип сорадым.

Гүя алар шунда җанландылар,
Нурлар чәчеп җем-җем көлделәр,
Әкрен генә искән җил аркылы
Миңа болай җавап бирделәр:

— Кемнәр эшли, кемнәр җирләр казый,
Кемнәр безгә сулар сибәләр...
Кемнәр чәчәк кебек саф күңелле,
Шулар безгә дуслар...— диделәр.

— Кемнәр кара эчле, тар күңелле,
Кемнәр чын эшкә кул бирмиләр,
Кемнәр килеп безне хаксыз өзә,
Шулар безгә дошман!..— диделәр.

Чәчәкләрнең шушы җавапларын
Алгач, «дөрес...» дидем аларга.
— Эшсез кешеләрнең хаклары юк
Сезне түшләренә кадарга...

Күңелле эш, матур тормыш белән
Ел артыннан еллар агарлар...
Эшчән егет белән эшчән кызлар
Сезне түшләренә кадарлар...

1927

тамаша кылу — карау, *монда:* сокланып карау
күзләр камаша — күзләр чагыла
хәйран калып — гаҗәпләнеп

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнегез.
2. Лирик герой чәчәкләргә нинди сорау бирә?
3. Чәчәкләргә кемнәр дус, кемнәр дошман? Шигырьдән шул юлларны табып укып күрсәтегез.
4. — *Эшсез кешеләрнең хаклары юк*
   Сезне түшләренә кадарга...
   дигән юлларны аңлатып бирегез. Фикер алышыгыз.
5. Авторның төп фикерен үз сүзләрегез белән әйтеп бирегез.

«Син чәчәкләр яратасыңмы?» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Син нинди чәчәкләрне беләсең?
2. Сезнең бакчада нинди чәчәкләр үсә?
3. Чәчәкләрне ничек тәрбиялисең?
4. Син кемнәргә, кайчан чәчәк бүләк итәсең?

Чәчәк исемнәрен исегездә калдырыгыз

дәлия — георгин
чалма чәчәк — пион
кашкарый — астра
гөлчәчәк — роза
алтын чәчәк — хризантема
миләүшә — фиалка
акбаш, акчәчәк — ромашка
күкбаш, күкчәчәк — василёк
канәфер — гвоздика
лалә — тюльпан

КЫР КАЗЫ

(кыскартып алынды)

Безнең авылдан ике генә чакрым чамасында җиргә төшкән ай кебек түгәрәк, көмеш тәңкә кебек ялтырап ята торган Ак күл дигән бик зур күл бар иде. Күлнең иңе 4—5 чакрым чамасында булганлыктан, аның бер ягыннан икенче ягында булган нәрсәләр күзгә чак-чак кына күренәләр иде.

Җәй көннәрендә күлнең тирә-ягы бөтенләй дип әйтерлек яшел үләннәр һәм төрле игеннәр белән уратылып алынганлыктан, күлдән ерак түгел тау башыннан караганда, бу күл яшел хәтфә палас өстендә яткан түгәрәк көзге кебек ялтырап ята иде.

Кич булса, күлнең кайбер урыннарында, өелеп-өелеп үскән камышлар арасында, төрле су кошлары төрле тавышлар белән кычкырып, чутылдашып, тирә-якны яңгыратып торалар.

Күлнең тирә-ягы җәй буенча шулай җанлы, күңелле булып торса да, көз якынлашып, салкын җилләр исә башлау белән, күл бу җанлылыгын югалта, әллә нинди моңсу бер хәлгә керә; кыр үрдәкләре һәм башка кошлар, өер-өер булып, җылы якка китәләр. Кояш нуры астында ялтырап, күл өстен бөҗраландырып уйный торган балыклар да, сикерүләреннән туктап, аска төшәләр.

Бу вакытта Ак күл буе төн ягыннан көн ягына (җәнүпкә) таба — җылы якка күчеп бара торган кыр казларының туктап хәл җыеп, тамак туйдырып, хозур кылып китә торган урыннары булып әверелә. Бу вакытта һәр көн өер-өер кыр казлары күлгә төшеп хәл җыеп, юынып, тагы да болыт кебек һавага күтәрелеп, кыйбла ягына очып китәләр. Аларның: «Кыйгак!.. кыйгак!..» —дип кагылдашкан, бер-берсе белән сөйләшкән тавышлары Ак күл буена ямь һәм җан биреп тора.

* * *

Мин шушы аулак күл буена, һәр көн дип әйтерлек, ат эзләп яки башка берәр эш белән барам. Анда һәр көн дөньяның бер чигеннән икенче чигенә бара торган кыр казларының

тезелешеп килеп кунарга төшүләрен карап торам һәм, аларның матур тавышларын тыңлап, аларны читтән карап, төрле уйларга чумам.

Менә иң элек бик ерактан, җиз таска көмеш бал кашыгы белән суккан кебек кенә, «кыйгак!.. кыйгак!..» дип, берәм-берәм генә кычкырган тавыш ишетелә; бу вакытта күзгә кебек ялтырап торган күктә бернәрсә дә күренми. Мин, кулымны җәеп маңгаема куеп, башымны югары күтәреп, тавыш ишетелгән якка карый башлыйм; барган саен тавышлар якынрак һәм ачыграк ишетеләләр.

«Күлгә җитәбез!.. Күлгә җитәбез!.. Төшәргә әзерләнегез!..» — дип, алдан башлап килгән кәрван башлыгы кычкыра торгандыр инде...

Менә бервакытта, һавада җилгә каршы тотылган ефәк тасма кебек, бер ягы озынрак, икенче ягы кыскарак каралҗым бернәрсә пәйда була.

Бу ефәк тасма кебек нәрсә, баштарак җилфердәп кенә күренсә дә, бара торгач ап-ачык күренә. Менә болар — бик ерактан — төньягындагы тундралардан кыйбла ягына китеп бара торган кыр казларының кәрваны.

Болар күлгә якынайган саен, тавышлары арта; алар тәртип белән генә түбәнәя башлыйлар. Менә узып кителәр инде дигән вакытта гына, кире уратылып, күлнең бер як читенә килеп төшәләр.

Алар, күл буена килеп төшү белән, ерактан килеп талган канатларын, чуалган йоннарын борыннары белән рәтлиләр, кагыналар, су эчеп, үз араларында нәрсәдер сөйләшәләр...

Алар кичтән, мин авылга кайтып киткән вакытта, күл буенда калган булсалар да, иртәнчәк баруда җилләр искән була. Алар иртә үк торып, җылы якка карап очып киткән булалар.

— Их, шулар кебек, канатың булып, ерак җирләргә очып китсәң иде,—дим мин. Аларның шулай дөнья күреп йөрүләренә кызыгам. Шул кыр казлары кебек, гелән җәй булып торган урыннарда гына йөрисе килә, алардан аерылып калуыма эчем поша.

Бүген аларның икенче, өченче кәрваннары килә, иртәгә алар да китәрләр...

чутылдашып — сайрашып
хозур кылып — сокланып
кыйбла — көньяк
каралҗым — кара төстәге, карасу
пәйда була — күренә

Сорау һәм биремнәр

1. Әсәрне сәнгатьле итеп укырга өйрәнегез.
2. Ак күлнең матурлыгын сурәтләгән урыннарны укып күрсәтегез.
3. Сезнең кыр казларының җиргә, суга төшкәннәрен күзәткәнегез бармы? Булса, әсәрдә сурәтләнгәннәр белән чагыштырып сөйләгез.
4. *Их, шулар кебек, канатың булып, ерак җирләргә очып китсәң иде* дигән юлларны аңлатып бирегез.
5. Укылган бүлекләр буенча өйдә рәсем ясагыз.

* * *

Беркөн, иртә үк торып, кояш чыккан вакытта, атларны эзләргә чыккан идем. Юлда Гариф малае очрап:

— Сезнең атлар Ак күл буенда йөриләр,— дигәч, туп-туры Ак күл буена киттем. Үләннәр, җир өстендәге камыллар чык белән капланган иде. Чык ярып, күл буена барып җиттем. Чынлап та, безнең атлар күл буенда, эшләрен искә төшерми, яшел курпы ашап йөриләр иде. Мин баргач, башларын да күтәреп карамадылар.

Мин, күл буенда өелеп үскән камышлар янына барып, тирә-якка карана башладым. Шул вакытта «кыйгак!.. кыйгак!..» дигән ялгыз гына каз тавышын ишеткәч, аптырап киттем. Күл буенда да, һавада да казлар төркеме юк. «Бу нинди каз тавышы?.. Бу кайда булырга кирәк?» — дип, колак салып тыңлый башладым. Тавыш бик якын, мин янында торган камыш арасында гына...

Бу нинди эш?.. Камышларны ике якка ярып, тубыкка чаклы суга кердем. Ни күзем белән күрим: камыш арасында, бер канаты белән генә талпынып, бер кыр казы очарга азаплана, ләкин булдыра алмый, туктый; йөгерәм дисә, камышларга эләгеп кала.

Ул, мине күргәч, куркуыннан бар көчен сарыф итеп талпына башлады. Ләкин һәммәсе бушка!.. Күп тә азапланмый, мин аны тотып алдым.

Ул куркуыннан, исән канатын кагып, минем кулымнан ычкынырга тырыша. Мине үзенә дошман дип уйлагандыр инде...

Бу каз, мотлакан, кичә бу күл буена иптәшләре белән хәл җыярга төшеп, шул чакта аңа берәр аучының ядрәсе тигәндер дә, шуннан качып, камыш арасына кергәндер һәм, бер канаты сынганлыктан, үзенең сөекле иптәшләре белән очып китә алмый, алардан аерылып, шушы камыш арасында калгандыр дигән уйга төштем.

Кулыма казны тотып, атларны җитәкләп, төш алдыннан гына өйгә кайтып кердем.

Озак йөрүем өчен өйдәгеләр ачулана башлаганнар иде дә, кулымдагы казны күргәч, ачуланмадылар. Әти бер дә уйлап тормый:

— Бу нәрсәне интектереп торганчы суярга кирәк, барыбер эшкә кермәс,— дип, казны суярга кушты.

Әтинең бу сүзләренә минем йөрәгем калтырап китте. Мин суюга каршы төштем:

— Горбәттә адашып калган гарип мосафир кунакны тот та суй, имеш!.. Бу ни дигән сүз? Мин аны асрыйм!—дидем.

Минем яшьле күз белән әйткән бу сүземнән соң әти дә мескен казны кызганды һәм:

— Ярый алай булса, асрап кара,— диде.

Мин шатлыгымнан нишләргә белмәдем. Кыр казын шунда ук йорт кошлары өчен ясалган ояга ябып куйдым. Табага су белән икмәк салып, кадерле кунагымның алдына китереп куйдым. Ләкин аның ашау кайгысы юк иде. Ул бик кайгылы рәвештә, бер як почмакка сыгынып, тик тора иде. Кечкенә чаклы казым тирәсендә әйләнеп йөрсәм дә, аның ашаганын күрмәдем; солы белән тары сибеп карадым — аларны да ашарга батырчылык итә алмады.

Кояш баер алдыннан, су буенда йөргән бер көтү йорт казлары какылдашып, бик күп эш бетергән кебек, ашарга сорап кайтып керделәр. Аларның тавышларын ишеткәч, кыр казы дәртләнеп, «кыйгак!» дип кычкырып җибәрде. Ахры, ул аларны үзенең иптәшләре дип белгәндер. Аның тавышын ишетү белән, безнең кызыл күзле, озын муенлы усал ата казыбыз, канатларын кагып, өзлексез кычкырып, кыр казы торган ояга таба йөгерде. Моның артыннан башка казлар да, әллә нинди зур бер вакыйга булган кебек, дөнья куптарып кычкырыша башладылар. Минем кунак казым боларның бу чаклы тәртипсез кычкырышуларыннан курыкты булса кирәк, бер почмакка сыенды.

Ата каз шул чаклы кызды, әгәр дә ихтыяр бирелгән булса, теге гарип мосафирны талап үтерәчәгендә шик тә юк иде.

Боларның һәммәсе дә каз җенесеннән була торып та, берберсенә бу чаклы дошман булуларына исем китте. Ләкин, болар бара торгач дуслашырлар әле дип, күңелемне юаттым. Шунда да кызыл күзле, тәкәббер ата казга бик нык ачуым килде:

— Чит кеше дип, шул чаклы ямьсез кыйлану, шулай әдәпсезлек итү ярый торган эшме соң инде?! Үзең шул хәлгә төшсәң нишләр идең? — дип уйладым.

Кунагым кыр казының күңелен табар өчен, теге йорт казларын икенче якка куалап җибәрдем. «Көчсезләрне рәнҗетмәгез, алай ярамый ул, мин аны якlармын!» — дип уйлап, өйгә кереп киттем.

камыл — иген сабагының урганнан калган өлеше
курпы — печән чапкач, яңадан үскән үлән
тубык — аякның балтыр сөяге белән табан сөяге тоташкан урыны
мотлакан — һичшиксез
интектереп — тилмертеп, газаплап
горбәттә — чит җирдә
мосафир — юлчы
сыгынып — сыенып
тәкәббер — масаючан

Биремнәр

1. Өзекне укып чыгыгыз һәм план буенча эчтәлеген сөйләгез.

   План

   Мин атларыбызны эзләргә чыктым.
   Камыш арасында яраланган кыр казы күрдем.
   Әти казны асрарга рөхсәт итте.
   Йорт казлары кыр казын кабул итмәделәр.

2. *Көчсезләрне рәнҗетмәгез, алай ярамый ул, мин аны яклармын!* дигән җөмлә буенча фикер алышыгыз.
3. Сүзтезмәләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз: *йөрәгем калтырап китте, дөнья куптарып, күңелемне юаттым.*
4. Булеккә исем куегыз.

* * *

Мин бүген төндә, гарип кунагымны уйлап, рәтле йоклый алмадым; бигрәк тә аның монда ялгыз калуын, иптәшләреннән аерылу хәсрәтен күрүен уйлап кайгырдым.

Мин торып тышка чыкканда, йорт казлары, ашарга сорап, келәт тирәсендә кычкырынып, дөньяны куптаралар иде. Мин чыгу белән, алар мине сырып алдылар. Ләкин мин, аларга әйләнеп тә карамый, үземнең кунагым янына йөгердем.

Мине күргәч, ул башта тайчанса да, бераз торгач, өйрәнә башлаган кебек күренә башлады. Мин кичтән салган азыкларның беразын ашап, суны да бераз эчкән иде. Моны күргәч, мин бик шатландым, шунда ук табадагы суны алмаштырдым һәм яңадан солы белән тары китереп салдым.

Кунагым, башта мин салган азыкларны тартынып кына ашый торган булса да, көннәр үтү белән, акрынлап өйрәнә, салган азыкны шунда ук ашарга керешә башлады; шуның белән бергә, ул үзе дә мине үзенә якын күргән кебек була, борынгы кебек мине күрү белән читкә тайчанмый иде.

Шулай итеп, безнең көннәр күңелле уза башлады. Ул миңа яхшы ук ияләшеп китте. Мин бу эштән бик шатландым.

* * *

Кыш керер алдыннан, казның сынган канаты яхшы ук төзәлде; сирәкләп булса да, канатын күтәреп, аркасына сала башлады; күрәсең, канат сөяге бөтенләй эштән чыкмагандыр. Бөтенләй сынган булса, бу рәвешле төзәлә алмас иде.

Казның бу рәвешле сәламәтләнгәнен күргәч, бик вә бик шатландым. Бервакыт очып йөрерлек бер хәлгә килер әле дип уйлый башладым.

Кунагым һәрвакыт тар урында торып күңелсезләнә торгандыр дип, көндезләрен үз карамагым астында гына алма бакчасына алып кереп йөртә идем. Ул, бакчага керсә, иркен тын алган кебек була, рәхәтләнеп китә, һавага карап, очарга иткән кебек дәртләнеп куя.

Безнең бу эшебез кар яуганчы шулай барды. Кар яугач, мал өендә кунагым өчен аерым, үзе генә торырлык урын ясадым. Иртән сабакка киткәнче, төштән соң сабактан кайткач, аның алдына солы, тары кебек азыклар салып, су биреп кунак итә торган идем. Мин аны шулай кыш буена тәрбия кылдым, кунак иттем.

Озын күңелсез кыш үтте. Карлар эреп, сулар ага башлады. Җир йөзе кояш нурына манчылды. Җылы якка киткән кошлар безнең илгә килә башладылар. Менә беркөн иртән торуга:

— Сыерчык килгән дә!.. — дигән сүзне ишеттем. Шунда ук урынымнан торып, тәрәзәгә карадым.

Чынлап та, иртәнге кояшка каршы, өй янындагы сыерчык оясы өстендәге чыбыкка бер пар сыерчык кунган: алар, канатларын кагып, талпына-талпына сайрыйлар иде. Безне бик сагынып килгәннәр алар. Дәртләре, шатлыклары эчләренә сыймый: шулай күңелләнеп сайрыйлар.

Көннәр барган саен матурланды. Кырларда карлар бетеп, кара җир өсте яшәрә башлады.

Менә беркөнне иртәнчәк, бик югарыда, еракта кыр казларының «кыйгак!.. кыйгак!..» дигән тавышлары ишетелә башлады.

Мин, кулымны маңгаема куеп, аяз күккә карадым. Чынлап та, төшлек ягыннан, бик югарыдан, ефәк тасма кебек җилфердәп, кыр казлары төн ягына таба үтеп баралар иде.

Шуларның «кыйгак!.. кыйгак!..» дигән тавышларын ишетү белән, минем кунагым булган кыр казы үзе дә: «Кыйгак!.. кыйгак!..»—дип кычкырып җибәрде һәм, дәртләнеп китеп, канатларын кагарга һәм бик җитезлек белән әрле-бирле йөрергә керешә.

Бу вакытка чаклы аның һичбер болай ук дәртләнгәне юк иде.

Мин аның бу чаклы дәртләнүенә һәм шатлануына аптырап карап тордым.

Шул вакытта аның дәртләнүе тагын да артты. Теге, һава-

дагы кыр казлары безнең авыл турысыннан узып барганда, ул, артык уйлап та тормый, йөгереп алга табан бераз барды да югары күтәрелеп оча да башлады һәм теге кыр казларына таба карап очып та китте. Мин гаҗәпсенеп карап тордым да калдым.

Ул, күздән югалганчы, бик моңлы иттереп: «Кыйгак!.. кыйгак!..» —дип кычкырды.

Аның бу кычкыруы миңа иң соңгы сәламе һәм минем белән саубуллашуы иде.

Мин аның тарлыкта, кеше кулы астында яши алмавына, киң дөньяны артык күрүенә хәйран калдым.

Ул, шулай итеп, үткән ел аерылып калган иптәшләренә барып кушылды.

Мин бу гарип кунагымны көз булган саен искә төшерәм, аны сагынам; ул миннән мәңге аерылса да, мин аны оныта алмыйм.

Бәлки, ул да мине шулай искә төшереп куя торгандыр.

хәсрәт — кайгы, борчу
тайчанса да — читләшсә дә
төшлек ягы — *монда:* көньяк
тарлык — тар, кысан урын

Сораулар һәм биремнәр

1. Өзекнең эчтәлеген өченче зат исеменнән сөйләгез.
2. Малай кыр казын ничек тәрбияли?
3. *Мин аның тарлыкта, кеше кулы астында яши алмавына, киң дөньяны артык күрүенә хәйран калдым* дигән юлларны ничек аңлыйсыз?
4. Малай сездә нинди тәэсир калдырды? Өйдә аңа кыскача характеристика язып килегез.

Кошлар турында табышмаклар

- Югары менә чылбырсыз,
  Түбән төшә баскычсыз,
  Өйләр сала балтасыз. *(Кош.)*
- Йомры йомшак сары йомгак
  Йөгереп йөри чирәмдә. *(Чеби.)*
- Гөлдер-гөлдер-гөлдер бу,
  Кызыл тәпи — кемдер бу? *(Күгәрчен.)*
- Соскы борын бакылдык,
  Күп сөйләшә — такылдык. *(Үрдәк.)*
- Суда юынып алды,
  Өсте коры калды. *(Каз.)*
- Башы тарак, койрыгы урак,
  Кычкыртып быргысын, уята барысын. *(Әтәч.)*
- Пыяла түгел — ватыла,
  Гәүһәр түгел — сатыла. *(Йомырка.)*
- Үзе йомырка басмый,
  Баласын да бакмый. *(Күке.)*

«Кошлар — безнең дусларыбыз» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Безнең якларда яшәүче нинди кошларны беләсез?

2. Ул кошларның кайсылары, язын безнең якларга килеп, көзгә таба яңадан җылы якларга китә?

3. Нинди кошлар безнең якларда кышлый?

4. Янәшәгездә яшәүче кошларның оя корулары, бала чыгарулары, аларны үстерүләре турында сөйләгез.

5. Сез кошларга оялар, җимлекләр ясап әләсезме? Аларга нинди кошлар килә?

6. Күзәткәнегез бармы: кошлар нинди азык белән туеналар?

7. Кыш көне сез кошларга ничек ярдәм итәсез?

8. «Кошлар — безнең дусларыбыз» дигән темага өйдә сочинение язып килегез.

Кошлар турында мәкальләр

- Кош сайравыннан билгеле.
- Аккош ялгыз яшәмәс.
- Бөркетнең канаты очканда ныгый.
- Карга килсә, кар китәр.
- Карлыгач сандугачка ияргә алмас.
- Сандугач үз кадерен үзе белер.
- Сыерчык бала чыгарганчы гына сайрый.
- Торна торган суына кайта.

Галимҗан Ибраһимов
(1887—1938)

Халкыбызның олы язучысы, публицист, галим, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимов авыр, катлаулы тормыш юлы үткән. Ул 1887 елның 12 мартында Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе (хәзерге Башкортстан Республикасы Авыргазы районы) Солтанморат авылында туа. Галимҗан табигать кочагында үсә; иптәшләре белән урманга, болынга — җиләккә, елга-күлләргә балыкка йөри. Балалык елларындагы матур истәлекләре аның күп кенә әсәрләрендә чагылыш таба.

Галимҗан башлангыч белемне әти-әнисеннән ала (әтисе дә, әнисе дә укымышлы кешеләр булалар). Аннары авыл, Оренбург мәдрәсәләрендә укый. Соңрак Уфадагы «Галия» мәдрәсәсендә белем ала.

1909 елның ахырында Г. Ибраһимов университетка керү теләге белән Казанга килә, ләкин максатына ирешә алмый. Шулай да күңел төшенкелегенә бирелми. Фән нигезләрен, тарих һәм философияне өйрәнә, дөнья әдәбияты классикларының әсәрләре белән таныша.

Октябрь вакыйгаларыннан соң ул Мулланур Вахитов белән бергә Мәскәүдә Үзәк Мөселман комиссариатында эшли.

Илдә тыныч төзелеш башлангач, Ибраһимов Казанга кайта һәм үзенең талантын, иҗат энергиясен яңа тормыш төзү

эшенә багышлый. Хикәяләр, өч повесть, дүрт роман, бер пьеса һәм бик күп фәнни хезмәтләр иҗат итә.

Авыр тормыш шартлары, киеренке иҗат аның сәламәтлеген какшата. Г. Ибраһимов каты авырып китә, һәм соңгы ун ел гомере Кырымда дәваланып үтә. Илдә репрессияләр башлангач, халык дошманы дип гаепләнеп, кулга алына.

Г. Ибраһимов 1938 елның 21 гыйнварында төрмәдә үлә.

50 нче еллар уртасында Г. Ибраһимов тулысынча аклана. Аның исеме, бай әдәби мирасы халкыбыз күңелендә яши.

ЯЗ БАШЫ

(кыскартып алынды)

I

...Ул арада минем кайтканны ишетеп, күрше малайлар — борынгы дуслар да килделәр. Башта алар ятсыныбрак, мине өлкәнсенебрәк торып, күрү белән бәйләнешеп китә алмасак та, бер-ике минут үтү белән, арадагы пәрдә югалды. Без тагы элекке Апрай, элекке Салих булып уенга ябыштык.

Нинди уеннар башлап ташлаганбыздыр, анысын ачык хәтерли алмыйм. Шулай да үзебезгә мәгълүм «Туп», «Кыекбаш», «Ат-ат»ларның берсе дә калмады; «Әке, пәке, ышкылаган сәке, чәүкә, чыпчык, син кал — бу чык» дип санаша торгач «Урам аша куяннар»га да җителде булса кирәк.

Ләкин болар гына минем кыш буена җыелып килгән уен дәртен баса алмады. Ни дә булса тагы да кызыграк, тагы да җанлырак, бәйләгечрәк бер кызык, бернәрсә эзли башладык. Төрледән-төрле сүз китте. Арадан берсе:

— Җил дә юк, балыкка барсак шәп төшәр иде,— диде. Бу киңәшне иң элек мин күтәреп алдым. Балык каптыру минем бик бәләкәй чактан ук сөйгән эшемдер. Мин җәйнең бөркү, озын, эссе көннәрендә ерак суларга балык каптырырга барып, көн буе әлсерәп, талып йөри, шунда үземә зур рәхәт таба идем. Шуңа күрә теге малай «балык» дигән сүзне авызына алу белән:

— Ну, таптың, малай! Китәбез, валлаһи, китәбез,— дип кычкырып җибәрдем.

Арада киреләнгән иптәшләр бар иде, аларны да димләп күндердем.

Шулай итеп, балыкка китмәкче булдык.

Мин тиз генә өйгә кердем дә: «Әни, мин балыкка барам»,— дидем.

Аның йөзендә, тавышында җибәрәсе килмәгәнлек билгесе булса да, мин куймый сорагач: «Ярар, барсаң бар инде, берүк саклана күр, тирәнгә якынлашма, мурдага кагыла күрмә»,— диде.

Былтырдан калган әзер кармак бар икән, шуны алдым да, кая басканымны белмичә, малайлар янына чаптым.

Ну, валлаһи, бу малайларны! Сыер кебек йөриләр, аяклары атлый алмыйлар. Тимеркәй белән Апрай әле һаман килеп җитә алмаганнар!

Бүген минем гел чабасым, чаптырасым гына килә, атлап йөрүне бөтенләй оныттым. Тәнемдә тиремә сыймаган бер көч, бер дәрт бар төсле: сикерәсе, дулыйсы, әллә нинди биек җирләргә менәсе, егыласы килә иде. Шуңа күрә малайларның акрынлавына ачуым килде! Әле һаман юклар! Алар артыннан барырга яисә, кычкырып, тавыш белән чакырырга миңа килешеп бетми инде, шунлыктан янымдагы Ибрайдан бертуктамый тегеләргә:

— Тизрәк! — дип кычкырта торам.

Әнә алар да килә инде. Хәзер китәбез.

Балыкка кая барырга?

Бу турыда сүз чыкты. Ялкауrак иптәшләр авыл янындагы инешкә барырга димлиләр. Ләкин мин аңар барлык көчем белән каршы тордым. Чөнки бу, бердән, бик сай, пычрак. Икенчедән, анда кечкенә балыктан башка бернәрсә дә капмый. Малайлар да икегә аерылып, бераз тарткалаштык. Шулай да азактан безнең як җиңде. Авылдан байтак читтә, ялан-урман уртасында булган Кондызлы күлгә юнәлдек.

Авылдан чыгу белән, күңел тагын киңәйде. Кыш буена

мәктәпнең тар бүлмәсендә, китаплар, кара такталар эчендә генә көн уздырган адәмгә, миңа, бу — яшьтән үк өсләрендә аунаган кырлар, яланнар, таулар аерым бер якынлык белән каршы алган кеби тоелалар. Шуларның һәрберсе мине куандыралар гына.

Бүген майның урталары булганга, кояш ерак, ләкин туры һәм матур карый. Бөтен җир йөзе язның гүзәллеге белән чолгана, һәр җирдә тын гына, акрын гына бер шатлык сизелә.

Инешнең ике ягына тезелгән таллар, яшел яфракка күмелеп, акрын гына, сак кына тавышлыйлар. Аның бөтен килешенә җәелеп яткан киң яшел тугай китә. Бу киң вә дулкынлы үлән диңгезенең нәкъ уртасыннан назлы кыз йөреше кеби боргаланып-боргаланып аккан елга үзенең көмештәй ялтыраган төсе белән бөтен тирә-якның күркен әллә ничә кат арттырып җибәрә.

Әнә ерак таулар, урманнар, әнә матур гына дулкынланып күренә торган уҗым басуы, әнә безнең юкәдән ясалган тубаллар белән җиләк җыйган уйсулармы,— болар бар да бизәнгән, бар да хәтфәдәй үләннәр белән түшәлеп, сары, кызыл, ал чәчәкләр белән матурланганнар. Көннең эсселегеннән һәммәсенең өстендә әллә нәрсә елтырый, болар әлсерәгәнрәк тоелалар; бу чәчәкләр, бу таллар өстендә кечек һәм матур кошлар үзләренең диңгез артыннан алып килгән моңнарын, шатлыклы көйләрен, сандугач үзенең иге-чиге булмаган мәхәббәтен сайрый. Кайда гына карама, җан, күңел күтәрелә торган моңнар, матур күренешләр генә очрый.

Һәркем «яз» ди, һәркем аны эче-җаны белән сизә. Һәрнәрсә аның чиге булмаган матурлыгына, моңына баш ия, барлык җирен аның гүзәллеге чолгый да, йомшак кына, яшерен генә, тын гына булган шатлыкка, бәхеткә чума.

...Без шулар... шул матурлыклар уртасыннан, шул моңнар эченнән, табигатьнең өстеннән ярып барабыз... Әнә безнең алдыбызда — барачак юлыбызда, киң яшел ялан белән биек һәм урманлы тау уртасында, зур түгәрәк сихерле күл ялтырый... Ничаклы матурлык!

бөркү — тынчу
мурда — балык тоту өчен җайланма
тарткалаштык — бәхәсләштек
тирә-як күркен — тирә-як матурлыгын, гүзәллеген
тубал — җиләк җыю өчен үрелгән савыт
әлсерәгән — йончыган, хәлсезләнгән

Сораулар һәм биремнәр

1. Малайлар нинди уеннар уйныйлар? Сез нинди уеннар беләсез? Сөйләп күрсәтегез.
2. Салих ни өчен табигать кочагына ашкына?
3. Табигатьнең сихри матурлыгы сурәтләнгән урыннарны дөрес интонация белән укыгыз.
4. Бүлеккә исем куегыз.
5. «Туган ягым табигате» дигән сочинение язып килегез.

* * *

Авылдан өч чакрым ераклыкта булган бу зур күлгә миңа бала чактан ук күп йөрергә туры килә иде. Тирә-ягындагы күренешнең бик матур булучылыгы, үзенең уңайлыгы һәрвакыт мине тарта, балыкка, су керергә дип еш-еш чаптыра иде. Моның төн, көн батышы яклары киң вә тигез иген басуы булып, безнең нәкъ шул күлгә башы төшә торган җиребез бар. Шунда янып-көеп урак урган чакларда бу күлдә су коенып та бик рәхәтләнә идем.

Күлнең кыйбла, кояш чыгышы яклары бик биек, бик зур урманлы таулар белән чикләнгән булганга, үземне белә башлаганнан бирле моның калын, куе, карт агачлары, андагы акланнар арасында төрле җимешләр җыярга йөри вә шунлыктан болар иске бер таныш, якын кебек тоелалар иде. Күлнең тирә-ягында булган һәрнәрсә матур, һәрнәрсә күңелле; тик авылга караган башы гына бераз шомлырак иде.

Күлнең бу ягында озын, күп җире кеше дә керә алмаслык булган күллек һәм баткаклы бер камышлык бар. Халык моның хакында әллә нинди ят, куркыныч әкиятләр сөйли. Шуңа күрә бу камышлык мине бик шикләндерә. Аңа якын

килү түгел, хәтта исемен генә ишетү дә күңелгә бер каушау бирә башлый иде. Ләкин балык дәрте минем мондый куркуларымны җиңде.

Без белгән сулар эчендә моның тикле балыклысы булмаганга, күңел, һичбер куркуга карамыйча, моңа тартты. Менә килеп тә җиттек.

Бу күлнең кояш чыгышы ягында, зур урманлы тау астында, ташлары өскә аварга торган бик биек яр бар. Монда балыкның иң шәп каба икәнчелеге безгә күптән билгеле иде, иң башлап шунда каптырачак булдык.

Ярның астына тавыш-тынсыз гына кердек тә, төрле җиргә урынлашып, кармакларны хәзерли башладык. Һәммәбез тын, һәммәбез ашыга, кабалана иде. Үзебезчә балыкның күңеленә бик ошарга тиеш булган җимнәрне куйдык та:

— Кармак салдым, йөгереп кап, яр башында ялтырап ят! — дип, кармакларны суга ыргыттык.

Кармакның суга китүе белән, барлык тәнем кайнап, эчем әллә нинди бер кызу белән тулганын тойдым.

Монда иң башлап алуның артык бер кызыгы, мәртәбәсе бар. Шунлыктан һәркемнең иптәшләрдән алданрак әләктерәсе килә.

Кармакка балык килгәнне белдерү өчен куелган камышка күзләремне текәп, шатлыклы минутны көтәм, камышның һәрбер кузгалышы, селкенүе миңа зур өмет бирә... Килде бугай, кармакны шаярта бугай... тфү... тфү... төкеренә башлыйм.

А... әнә камышым селкенә! Чү, кузгала... Кузгала әнә, әнә торды. Ах... йөрәк суга... башым шаулый... Үзем белмим: җимне ашыймы, әллә берәр шаян балык мине алдый гынамы? Юк, чын булыр!

Мин шулай аптырап торганда, кармагым төпкә чумды. Тагы чыкты, инде тагы чумды. Ләкин бик нык, бик каты китте.

Эш бик өметле иде. Бу чаклы каты алып китүгә караганда, бик зур һәм нык капкан булуда бер дә шик юк иде.

Үземне үзем белмичә, чиктән тыш бер кызма белән кармакны яр башына аттым. Ни күрим? Җиме ашалган буш вә ялангач кармак килеп чыкты. Ах... валлаһи, нинди яман, нинди күңелсезлек! Бик зур балык көткәндә, буш кармак чыксынчы!

Бу миңа шундый авыр һәм яман булды. Мин тәнемдә янып торган бер утның сүнүен, эчемнең туңганын тою кебек бер халәткә килдем.

Дәртсез һәм калтырап, икенче җимне куйдым да яңадан салдым.

Кармак суга төшү белән, эчемдәге уңайсызлык тагы басылды. Мин, тагы әләктәгечә кызма белән камышыма күз тегәп, зур да, матур да булган балыклар көтә башладым.

Астан гына, алмыйлар микән дип, иптәшләргә күз салам, юклыгын белгәч, күңел азрак тынычлана иде.

...Ах... булмады.

Иптәшләрдән берсе, ялтыратып, яр башына атты. Нинди тагын! Кармакка бик сирәк каба торган бик зур, бик матур кызылканат балыкның ялтырап яр башына атылуы белән, һәммәбез кармакларны ташладык та шул бәхетле иптәшебез янына килдек.

Ул су кырыена үләнгә төшкән балыкның өстенә егылып тотарга маташа. Үзе бизгәк кеби калтырый, кабалана иде, аның балыгын күрү белән, барыбызның да эченә хәсрәт уты кабынып, шул балыкның үзебезгә эләкмәвенә эчтән көендек. Минем күңелемә: «Мин балык булсам, гелән миңа гына кабар идем!» дигән бер уй килде. Бу шундый турыларда минем башыма һәрвакыт килгәли иде.

Эчтән кызыксак та, тыштан белдермәдек, бернәрсә дә әйтә дә алмадык, тик эчке әрнүләребез белән:

— Ну, малай, Апрай! Башлап син алдың, кул артың авыр булса, бирербез кирәгеңне! — диешеп, яңадан кармакларыбызга килдек. Теге малай, яшь, өйрәнмәгән булганга, балыгын һаман урнаштырмаган, күзен ала алмый кызыгып, уйнатып тора иде.

Менә бервакыт «шалт-шолт» иткән бер тавыш ишетелде.

Карасак, малаебызның йөзе агарган, ике кулын тыгып, су читен бутап ята: ай, бичаракай, балыгын ычкындырган... Вәссәлам!

Гөнаһны яшерер хәл юк, тыштан: «Ну соң, зур иде, әй, беркөн Шаһи картның нәрәтә белән алган чуртаны чаклы бар иде!» —диешсәк тә, эчебездән шатландык.

Икенче балыкны мин алдым. Ләкин иң кечкенә һәм иң кирәксез бер яман бәрде иде.

Иптәшләр һәммәсе беравыздан:

— Карагыз әле, Салихка чәнчә бармактан да зур бер балык капкан! — дип көлештеләр.

Җитмәсә тагы, бер явызы:

— Ну, Салих, батыр икәнсең, ничек тартып чыгара алдың шундый зур балыкны! — дип мәсхәрә кылды.

Мин, эчемнән янсам да, тыштан сер бирмәдем:

— Э, алаймыни?.. Күзегез кызамыни?.. Сезгә ул да юк бит әле! — дидем.

кабалану — ашыгу
гөнаһ — *монда:* гаеп эш
нәрәтә — балык тоту җайланмасы
бәрде — балыкның бер төре
чәнчә бармак — аяк-кулның иң кечкенә, бишенче бармагы
күз кызу — кызыгу

Сораулар һәм биремнәр

1. Ни өчен күлнең матурлыгы иптәшләренә караганда Салихка ныграк тәэсир итә? Сезнең андый хисләр кичергәнегез бармы?
2. Салих күл турында исенә ниләр төшерә?
3. Балык каптырганда Салих нинди уй-хыялларга чума? Шул урынны табып укып күрсәтегез.
4. Беренче балыкны кем тота? Аның белән ни була?
5. Бүлекнең эчтәлеген өченче зат исеменнән сөйләгез.
6. Түбәндәге сүзләрнең синоним һәм антонимнарын табып, дәфтәрегезгә языгыз: *зур, матур, биек, калын, шомлы, ят, куркыныч.*

* * *

Башлап алучының кул арты яман булмады. Һәммәбез дә килгән бушка китмәде диярлек кадәрле балыклар тоттык, арада кармакка бик сирәк туры килә торган зур алабугалар, шүкәләр, шамбы, карабалык кебиләр дә бар иде.

Күлдән китми каптыруыбыз берничә сәгатьләр дәвам итте. Тоташтан кармак саклап утыруыбыз бераз ялыктыра да башлаган иде. Кармакларыбызны зур балыклар гына кабарлык итеп тирәнәйттек тә тау башына менеп киттек. Анда безнең өчен берничә төрле юаныч бар иде. Кош оялары, йомран өннәре карадык. Еланнар эзләдек, катканрак булса да, юалар, яңа гына чыга башлаган балтырган көпшәләре ашап, соңра уҗым ягына какыга чыктык.

Алып килгән икмәкләр бар иде, аны ашадык. Тирләүне басу өчен коенып алдык. Көн эссе, һава кызу иде. Йомшак вә

җылы суда бик рәхәт булып калды. Инде башка кызыклар беткән иде, тау буенда киң, юка ташлар җыйнадык та тулкынсыз күл өстеннән «сиңа ничә әпәй кирәк?» дип атыша башладык. Ләкин мин, моңа оста булмаганга, артык кызыгын тапмадым.

Шулай итеп, җәйнең озын көне безгә, бигрәк тә миңа, бер дә тоелмый, бәйрәм кеби күңелле үтеп китте.

Иптәшләрдә ялыкканлык сизелә башлады, малайлар, авыл ягына карангалап, җилкәләрен кашыйлар. Әллә нидән, бик үк кызык тапмаган Гали атлы бер иптәшебез:

— Кич тә булып килә, кайтырга кирәк инде, малайлар,— диде.

Күбебез моның сүзен куәтләдек.

Тик әллә нинди бер көч белән малайларны буйсындыра торган Тимеркәй белән Апрай гына каршы төштеләр. Алар һәрвакыт тискәреләнергә яраталар. Әле дә кечек башларыннан әллә нинди сүзләр чыгарып, телләренә салыштылар:

— Нәкъ кабар чак җиткәч кенә кайту була диме! Кичкә таба балык бик каба ул!.. Чөнки... фәлән... төгән...— дип, кире тордылар. Иртә кайтсалар, аларны эшкә кушачаклар, шуның өчен алар булган чаклы соңга калырга тырышалар икән. Без барыбыз да кайтуны теләсәк тә, җиңә алмадык, тагы каптыра башладык... Ләкин баягы дәрт беткән, күңел сүнгән иде. Кармакка күп карамыйча, җилкәләрне кашып яисә балык санап маташа идек.

Кояш баешы ягыннан кара куе болыт чыгуы безне тагы борчый башлады. Төрле яктан кайтуны кайгырта башладылар.

Болыт тизлек белән зурайды. Тагы ныграк калыная да, карала да төшеп, безгә якыная бара иде: җил чыгуы аңа тагы зур куәт булды.

Без барыбыз да балалар булып, мондый яшенле яңгырлардан куркып гадәтләнгәнгә, бер кулга кармакны, икенчесенә җепкә тезгән балыкларны тоттык та күл буйлап чаба башладык. Күлнең аргы башында булдыгымыздан, авылга кайту

өчен бер чакрым озынлыгындагы күл буе белән барып, теге куркыныч камышны үтү лазем иде.

Күк йөзендәге болыт катлавы һаман арта, һаман калыная, куе томанлы караңгылык кушыла бара, яшен, күк күкрәү баягыдан да яман рәвешкә керәләр, шулар бары җыелып, җаныңны бармак очына китерердәй була; өстеңә тау-таш ишелеп килә дә, шул минутта яшен, башыңа тиеп, бөтен гәүдәңне яндырып ташлар кеби тоела иде.

Шулар өстенә үзебезнең теге куркыныч камышка якынлашуыбыз безнең куркуны тагы мең кат арттырып җибәрә иде.

Җитмәсә тагы, бая гына: «Тоз түгелдерсең, эремәссең!» — дип батырайган тискәре малайларның беренчесе, бездән дә артык каушап, әллә нинди куркынычлар хакында тукый башлады:

— Тизрәк чабыйк, малайлар, тизрәк... ул-бу булганчы, менә бу камышлыкны чыгып калыйк. Минем абзый бу камышлык эчендә аждаһа күргән. Ул җил-давыл, болыт белән күтәрелә, имеш. Шуңар очрый күрмик!..— ди.

Аждаһа... аждаһа!.. Ух... нинди коточкыч нәрсә! Моның исемен генә ишетү белән, минем куркуым әллә ничә кат артып китә. Бу мин уйлый ала торган нәрсәләрнең иң усалы, иң явызы һәм иң коточкычы иде. Җеннән, албасты, су анасыннан, упкыннан бигрәк мин шуңардан курка идем. Бу хакта авылыбызның тәмле, килешле итеп әкият сөйләү белән даны чыккан Фәхринең сөйләгәннәре, иң элек ишетүем булганга, әле дә исемнән чыкмыйлар.

Тауларда йөри торган тузбашлы кечкенә еланнар бармы,— әнә шулар, йөз яшәсә, аждаһага әйләнәдер, ди. Шуның өчен аны күргән берен үтерә барырга кирәк, ди. Аның өчен бер дә гөнаһ булмый, ди. Әгәр инде аны үтермәсәләр, йөзгә җитә дә, ди, аждаһа була, ди.

Ул камышлы һәм кеше керә алмый торган күтәрлекләрдә була, ди. Аны минем бабам күргән: буе унбиш колач, калынлыгы ат чикле, ди. Шундый батыр, ди, сулышы-теше белән

зур үгезләрне ерактан суырып аладыр, ди. Ул шул камышта ята бирә, ди. Әгәр дә тирә-якка зыяны булмаса ята да ята, ди. Зыян итә башласа, маллар, адәмнәр, хайваннар алса, болыт килеп, җил-давыл белән күтәреп китә, ди.

Болар өстенә, бик бала чагымда әнинең итәгенә ятып, йокы аралаш тыңлаган мәсәлләр, хәзрәте Галинең авызыннан утлар чәчеп торган кырыгар башлы аждаһаларны кыруы хакында хикәяләр дә хисапсыз иде. Шуларның барысы җыелып, миңа шундый халәт ясаганнар иде, аждаһа дигән сүзне ишетү белән, күз алдына әллә нинди коточкыч бер сурәт килеп баса иде.

Теге иптәшнең «бу камышлыкта аждаһа... җил-давыл күтәрелә» кеби сүзләрен ишеткәч тә, шул коточыргыч сурәт тагын килеп, шулхәтле курыктым, гомеремдә һичбер вакыт ул чаклы курыкканымны белмим: башым гел яман сурәтләр белән генә тулып, хәзер каршыма ун башлы, табактай күзле, тау кеби зур аждаһа килеп чыгар да минуты белән мине йотар шикелле тоя башладым.

Менә артык яман җиренә якынлашабыз, ух... йөрәгем урыныннан чыга... Шул чакта гына минем алдымда бик көчле өермә кузгалды, һәм шул ук сәгатьтә күктән бик калын болыт шул җиргә сузылгандай булды, шул ук минутта колагыма «шши...» иткән бер тавыш ишетелеп, бүрәнәдәй бернәрсә, камышларны ярып, миңа таба килгән сыман тоелды.

Ни эшләгән, ни булганны белмим... Йөрәгем ярыла, җаным чыга...

Теге бүрәнә кебек нәрсәнең югары таба күтәрелгәндәй һәм шул ыжгыруда, нәкъ халык әйткәнчә, бар әйбер төрле якка тартылып, сугылып торгандай булды. Шуннан соң ни булганын ачык белмим, тик җан ачуым белән:

— Әни... эти... аждаһа бар, аждаһа ята! — дип кычкырып җибәрүемне, соңра күз алдым караңгыланып, башым җиргә тигәнен, дөньяның асты өскә килгәндәй әйләнүен аз гына хәтерлим...

Шул хәлдә байтак вакыт кичкән. Мин исем җыеп, кү-

земне ачу белән, иң элек әнине күрдем: аның күзләре яшьле һәм кызарган, йөзе көлдәй ак һәм тирән бер борчулы иде. Янында аннан башка тагын берничә кеше бар иде. Шулар эченнән урыс төсле бер адәм миңа әллә нәрсә эчертте дә, башларын селки-селки: «Хыялдан нинди бәлаләр туа бит», — диде.

Дөнья әүвәлгечә матур, таулар, кырлар, урманнар элеккечә яшел, сандугачлар һаман өзлексез сайрамакталар иде.

Мин дә озак ятмадым, аякка басып, тагын уйнарга чаптым.

каптыруыбыз — тотуыбыз
тоташтан — бертуктаусыз
ялыкканлык — арыганлык
тискәреләнергә — киреләнергә
юа — аш тәмләткеч тугай үсемлеге
балтырган көпшәсе — эре яфраклы үлән (борщевик) сабагы
лазем иде — кирәк иде
күтерлекләр — чытырманлыклар

Сораулар һәм биремнәр

1. Балык тотып арыгач, малайлар нишлиләр?
2. Тимеркәй белән Апрайның үз-үзләрен тотышын тасвирлагыз.
3. Салих аждаһа турында ниләр ишеткән?
4. *Хыялдан нинди бәлаләр туа бит* дигән җөмләне ничек аңлыйсыз?
5. Түбәндәге сүзтезмәләрнең мәгънәләрен аңлатыгыз: *кул арты, телләренә салыштылар, җаныңны бармак очына китерердәй була.*

* * *

Тормыш-көнкүрештәге катлаулы булмаган вакыйгаларны сөйләп бирүгә нигезләнгән кечкенә күләмле әсәр *хикәя* дип атала. Хикәядә, гадәттә, тормыштагы бер вакыйга сурәтләнә, кеше характерының, психологиясенең бер сыйфаты киң итеп ачыла.

«Яз башы» хикәясендә вакыйгалар беренче зат тарафыннан сөйләтелә. Салих исемле бер малай, кыш буе читтә укып,

туган авылына тәүге ялга кайткан. Аның күңеле иркенгә, табигать кочагына ашкына. Автор табигатьнең гаҗәеп гүзәллеген дә, дәһшәтен дә оста итеп сурәтли. Шул күренешләргә бәйле рәвештә геройларның уй-фикерләрен, хис-тойгыларын ачып сала.

«Минем яраткан китабым» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Сез нинди китаплар укырга яратасыз?
2. Соңгы вакытта нинди китап укыдыгыз? Аның авторы кем?
3. Ул китапның эчтәлеге нидән гыйбарәт?
4. Әсәрнең төп герое кем? Ул сезгә кайсы ягы белән ошады?
5. Әсәрдә күтәрелгән мәсьәләләргә сезнең мөнәсәбәтегез ничек? Автор позициясе белән килешәсезме?
6. Әлеге авторның иҗаты турында ниләр беләсез?

Дәрҗия Аппакова
(1898—1948)

Татар балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән прозаик һәм драматург Дәрҗия Сәйфулла кызы Аппакова 1898 елның 2 мартында Уфа губернасының Минзәлә өязе (хәзерге Татарстанның Түбән Кама районы) Байгол авылында ярлы крестьян гаиләсендә туа. Унөч яшендә Казанга килеп, укытучылар әзерли торган мәктәптә укый. Аны тәмамлагач, берничә ел Казанда һәм туган авылында балалар укыта. Бер үк вакытта театр студиясендә укый, соңыннан берникадәр вакыт сәхнәдә уйный, аннары яшьләр оешмасында эшли.

1928—1943 елларда Д. Аппакова Урта Азиядә яши һәм укытучылык, хатын-кызлар арасында мәгърифәт-агарту эшләре белән шөгыльләнә. 1943 елда яңадан Казанга кайтып, гомеренең соңгы көннәренә кадәр, профессиональ язучы буларак, иҗат эшчәнлеген дәвам итә. Язучының төрле милләт халыкларының үткәндәге һәм Октябрьдән соңгы тормыш күренешләрен яктырткан «Сәнәкчеләр», «Яшь ударниклар», «Мәмәт һәм Аман карт», «Кечкенә Бануның тарихы» исемле хикәя, повестьлары укучылар тарафыннан җылы кабул ителә. Балалар театры өчен иҗат ителгән «Дошман» дигән өч пәрдәлек пьеса да укучылар, тамашачылар күңеленә хуш килә. Дәрҗия Аппакованың «Кечкенә Бануның тарихы» повестен балалар аеруча яратып укыйлар. Бу әсәр тиз арада татар, рус, үзбәк һәм инглиз телләрендә дөнья күрә.

1943—1948 елларда Д. Аппакова балалар сәхнәсен төрле драма әсәрләре белән баетуга зур хезмәт куя. Шушы елларда аның «Тапкыр егет», «Шүрәле», «Бишек җыры», «Илдус» исемле пьесалары иҗат итела.

ЙОЛДЫЗКАЙ

Нәсимә аны юкка гына «Йолдызкаем» дип йөрми шул. Песинең йоннары чем-кара. Ә маңгаенда — нәкъ ике колак уртасында — ап-ак табы бар. Йолдыз кебек янып тора. Көндезләрен алар бергә-бергә чабышып уйныйлар. Кич булу белән песи Нәсимәнең юрган астына керә дә, мырр-мырр итеп, йомшак кына көйли башлый. Әйтерсең ул шулай ягымлы җыры белән дусын йоклата.

Җәйге көннәрнең берсе иде. Нәсимәнең әнисе, май язам дип, баздан сөт өсте алып чыкты. Аны гөбегә салды да, көянтә-чиләкләрен күтәреп, чишмәгә суга китте.

Ә песинең гөбе яныннан һич кенә дә китәсе килми бит. Койрыгын югары күтәргән, ә үзе Нәсимәдән күзен алмый.

— Мияу! Мияу! Каймак исен сизәм! Ми-яу! — дип сузуын гына белә.

— Әни кайтканын көтмисеңмени? Ярар алайса, әз генә алып бирим әле,—дип, кызчык, кашык табып, гөбедәге каймакка тыгылды.

Гөбе биегрәк шул. Нәсимәнең иягенә җитә...

Кыз үрелеп-үрелеп карады да, ала алмагач, гөбе янына бүкән тәгәрәтеп китерде. Бүкәнгә басты. Кашыгы белән гөбегә тыгылган иде, бүкән ауды да тәгәрәп китте. Нәсимә егылды, гөбене дә аударды.

Менә көтелмәгән бәла! Инде нишләргә? Нәсимә куркуыннан тезләре авыртканын да онытып җибәрде. Тиз генә гөбесен утыртты. Аннары идәндә җәелеп яткан каймакны, учлары белән җыеп, савытка тутыра башлады.

Ул тутыра, песи лач-лоч итеп ялый, рәхәтләнде песи каймакка!

Кинәт ишек ачылды. Әнисе кайтып керде.

— Ах әдәпсез бала! Харап иткәнсең икән!..

Нәсимә әнисенең болай тиз генә кайтуын көтмәгән иде. Каушавыннан:

— Мин түгел! Песи бит! — дип әйтүен сизми дә калды.

— Зуп-зур гөбене мәче аударамы соң?! — диде әнисе, ачуланып. Чыбык алды да: — Кит әле, каймакны пычратма син! — дип, песигә берне селтәде. Песи ачык ишектән атылып чыгып китте. Кызга бары тик кырын күзен генә салды ул. Нинди зур үпкәле караш иде бу! Нәсимәнең йөрәге сыкранып китте.

Кичкырын басудан әтиләре кайтты.

— Анасы, бүген безне май белән сыйларсың бит, ә?!

— Майны песи белән Нәсимәдән сорагыз. Гөбене аударганнар, йөзе каралар. Атна буе җыйган сөт өстен әрәм иткәннәр,— диде әнисе ачулы тавыш белән һәм почмакта утырган Нәсимәгә бармак янады: — Өйгә генә кайтсын мәчең, күрсәтермен әле мин аның күрмәгәнен!

Нәсимә: «Юк, юк, әнием! Гөбене ул аудармады!»—димәкче булган иде дә, батырлыгы җитеп бетмәде. Әтисе дә ачуланыр дип курыкты ул.

Ашап-эчкәч, Нәсимә урынына ятты. Тик ул йоклый алмады, бик озакка чаклы дустын көтте. Ак йолдызлы кара песи килмәде, юрган астына кермәде. Сөйкемле итеп мырр-мырын җырламады. Бүген аның песие кайда кунар икән инде?

Нәсимәнең күзләренә кайнар яшь тыгылды.

— Песием... Йолдызкаем!.. Алтыным!.. Инде моннан бүтән һич тә алай үпкәләтмәс идем. Әнә әнием дә мине яратмый инде,— дигән булды ул. Шулай да йокы килмәде. Нәсимә әкрен генә торды. Әнисе янына барды.

— Әни! Гөбене мин аударган идем. Ялгыш кына. Песине кыйнама, яме?!

— Ярар, ярар, бар ят, йокла инде,— диде әнисе йомшак тавыш белән.

Нәсимәнең кинәт өзелеп йоклыйсы килеп китте. Урынына барып юрганын гына ачкан иде... Ай! Кемнең күзләре шулай яна?.. Йолдызкаем! Синме бу? Кайттыңмы?

Песие, аңа иркәләнеп, мырылдап куйды.

гөбе — май яза торган агач савыт
күз алмау — текәлеп карап тору
бүкән — юан агачтан яки бүрәнәдән кисеп алынган оч, бүрәнә башы
бәла — бәхетсезлек
әрәм итү — нәрсәне дә булса кирәкмәгәнгә тоту, юкка сарыф итү

Сораулар һәм биремнәр

1. Ни өчен Нәсимә үзенең песиен «Йолдызкаем» дип йөртә?
2. Нәсимәнең әнисе нишләргә җыена?
3. Гөбе ничек авып китә?
4. Ни өчен Нәсимә үз гаебен песигә сылтый? Дөрес эшлиме? Нәсимә урынында булсагыз, сез нишләр идегез?
5. Текстны өлешләргә бүлегез. Һәр өлешкә исем куегыз.
6. *Маңгай, йолдыз, йомшак, һич, савыт, көндез, койрык* сүзләрен дөрес итеп укыгыз һәм рус теленә тәрҗемә итегез.

ШЫГЫРДАВЫКЛЫ БАШМАКЛАР

Гөлшатның сары башмаклары бар. Сап-сары, сары күбәләк канаты төсле башмаклар. Их, матурлар да! Үзләре тагы, аякка кию белән, җырлый башлыйлар: шыгыр-шыгыр, шыгыр-шыгыр. Әйтерсең олтаннарында тылсымлы кубыз бар.

Мондый башмакларны киеп, урам ташларын текелдәтеп тек-тек итеп басып йөрүең ни тора!

Бөтен балалар аның аягына карыйлар.

Балалар гынамы соң? Талда чутылдашып утырган чыпчык малайларына кадәр башларын кыйшайталар да елтыр күзләрен сары башмакларга төбиләр.

Бик-бик кадерле бүләк алар. Әтисе Гөлшатка Мәскәүдән җибәргән ул сары башмакларны. Ә аның әтисе — танкист. Гөлшат аларны беренче көнне үк Ләләгә киеп күрсәтте. Күрсәтмәскә! Ләлә Гөлшатның иң якын дусты ич. Күрше бүлмәдә генә тора. Алар икесе бергә бакчага баралар. Шулай бергәләшеп кайталар да. Кайткач курчак уйныйлар.

Ләләнең дә әтисе фронтта. Исән генә булсын. Әтисе кайткач. Ләләгә дә шыгырдавыклы башмаклар алып бирер әле.

Ә менә Гөлшатның әтисе кайтты да инде. Әтисе белән бергә бәйләм-бәйләм, кочак-кочак бәхет нурлары кайтты. Ул кайткач, өй эче бөтенләй яктырып киткән сыман булды. Әллә әтисенең күкрәгендәге йолдызлар шулай балкыттылар инде өйне, әллә кояш юмартланыбрак көлә башлады.

Гөлшатның башмаклары дисәң, алар тагын да күңеллерәк шыгырдыйлар. Менә бит ул ничек — әти кайткач!

Гөлшат, сөенеченнән нишләргә белмичә, Ләләләргә йөгереп керде.

— Әтием кайтты! Их, йолдызлары да йолдызлары! — дип кычкырып җибәрде ул.

Тик аңа эндәшүче булмады.

Ләләнең әнисе сандык өстендә елап утыра. Ләлә дә, әнисенә кушылып, үкси-үкси елый иде.

Ул, башын күтәреп, калтыравыклы тавыш белән:

— Хәзер инде минем сары башмакларым булмас,— диде.

— Әйе, кугәрченем, әтиеңнең батыр гәүдәсе сугыш кырларында калды. Кабере өстенә миләүшәләр үскәндер инде,— диде әнисе авыр сулап һәм, кызын кочаклап, тагын елый башлады.

Гөлшатның күкрәгенә таш кереп урнашкандай булды.

Шул вакытта ишек ачылып китте дә, Ләләнең өч иптәше килеп керде. Берсе зур курчак күтәргән. Икенчесе мәк чәчәге төсле кызыл туп тоткан.

Кызлар Ләлә янына килделәр.

— Бу тупны идәнгә бәрсәң, ул түшәмгә кадәр сикерә,— диде туп тоткан кыз һәм тубын елап утырган иптәшенә бирде.

— Бу курчагымның күзләре ачыла да, йомыла да белә. Ул мине бик ярата. Ал, Ләлә, курчагымны. Ул сине дә шулай яратыр әле,— диде икенчесе.

— Бу чәчәкләрне үзем сайлап алдым,— диде өченчесе. Хуш исле чәчәкләрен Ләләгә сузды.

Тагын ишек ачылды.

Бу юлы Гөлшатның әтисе керде. Керде дә Ләләне кулына күтәреп алды.

— Иһи! — диде ул, аның кулыннан тубын алып. Тупны идәнгә бер генә бәрде, туп түшәмгә кадәр сикерде.

— Ләлә кызым! Иртәгә мин сине курчак театрына алып барырмын. Гөлшат та барыр. Барырсың бит, Гөлшат?

Гөлшат бер сүз дә әйтмәде. Тиз генә чыгып китте дә, бүлмәсенә кереп, актарынырга тотынды ул.

— Кызым, син ни эзлисең анда? — дип сорады әнисе.

— Берни дә түгел,— диде Гөлшат. Ә үзе һаман эзләнә. Әйберләрнең берсен ала, берсен куя. Менә аның күзләре сары башмакларына төште. Кулына алды башмакларын. Әйләндерә-әйләндерә карады. Нинди чибәрләр бит! Менә ул аларны күкрәгенә кысты. Тагын бераз әйләндергәләп торды. Шуннан соң әнисе янына килде.

— Әнием! Ләләгә кызлар чәчәкләр алып килделәр. Аннары курчак та, аннары туп. Әй, нык сикерде дә! Мин дә башмакларымны бирәм, әнием, яме?

— Ярый, ярый, акыллым. Бик яхшы булыр, сөендер иптәшеңне. Бар, бүләгеңне кертеп бир,—диде әнисе.

Гөлшат кергәндә Ләләнең әнисе еламый иде инде. Ул, кызын юатып, нәрсәдер сөйләп утыра иде.

Гөлшат иптәше янына ук барырга кыймады. Бераздан тирән, бик тирән итеп сулап куйды да:

— Ләлә! Мә, башмакларымны киеп кара, аягыңа сыямы? — диде һәм Ләләгә аларны кияргә дә булышты.

Ләлә, аякларына иелеп карый-карый, ишекле-түрле йөри башлады.

— Сап-сары, сары күбәләк канаты төсле бит үзләре! — диде Гөлшат, дусты тирәсендә сикергәләп.— Дустым! Мин сиңа аларны бүләк итәм. Теләсәң ничек шыгырдатып йөр, яме!

Кинәт Гөлшатка бик җиңел, бик рәхәт булып китте.

башмак —чүәк, туфли
олтан — аяк киеменең аскы өлеше, табан
тылсымлы — могҗизалы, сихерле
төбәү — юнәлтү
шыгырдавыклы — шыгырдап тора торган

Сораулар һәм биремнәр

1. Хикәяне укыгыз һәм әчтәлеген сөйләгез.
2. Гөлшатка шыгырдавыклы башмакларны кем җибәргән? Хикәядән башмакларны тасвирлаган урынны табып укыгыз. Автор аларны ничек сурәтли?
3. Гөлшат шатлыгын кемнәр белән уртаклашырга тели?
4. Үзенә дә бик кадерле башмакларын Гөлшат дусты Ләләгә бүләк итә. Бу күренеш сезгә ничек тәэсир итте? Гөлшатны характерлаучы сыйфатларны әйтегез.
5. Сезнең сыйныфташларыгыз, иптәшләрегез белән мөгамәләгез ничек? *Чын дуслык, бер-береңә игътибарлы, ярдәмчел булу* дигән сүзләрне сез ничек аңлыйсыз?
6. Дуслык турында мәкальләрне укыгыз һәм аларга аңлатма бирегез.

   Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсын.
   Юлга чыксаң, дустың үзеңнән яхшы булсын.
   Дуслар эзләмәгән кеше үзенә дошман.

7. *Сөенеч, күңелле, юата* сүзләренә — синонимнар; *юмарт, дус, батыр* сүзләренә антонимнар табып әйтегез.

Гөлсем Сөләйманова
(1907—1968)

Гөлсем Сөләйманова 1907 елда Казанда ярлы гаиләдә алтынчы бала булып дөньяга килә. Казан бае Үтәгәневнең сабын заводында кассир булып эшләгән әтисе Нурмөхәммәт җырга-моңга гашыйк кеше була. Гармунда да бик матур, оста уйный. Алты яшендә үк Гөлсем әтисе уйнаган көйләрне бик тиз отып ала торган була. Мәктәптә укый башлагач, концертларда катнашып, матур җырлавы белән иптәшләренең һәм укытучыларның игътибарын җәлеп итә. Өч еллык укытучылар курсында, аннан соң Казан музыка техникумында укыганда, аның музыка белән кызыксынуы бермә-бер арта. Бу коллективта педагог, музыкант-мәгърифәтче, пианист һәм композитор Солтан Габәшинең эшләве җырга омтылучы кызга канат куя. Габәши җитәкчелегендәге укучылар хоры яшь республиканың мәдәни тормышында зур роль уйный, завод клубларында, мәктәпләрдә уңышлы чыгышлар ясый. Хор күренекле драма театры артистлары белән бергә музыкаль спектакльләр куюда катнаша. 1921 елның 21 декабрь кичендә уйналган «Бүз егет» спектакле Сара Садыйкова һәм Гөлсем Сөләймановаларның җырчы булып формалашуларына зур булышлык итә. Музыкасын Солтан Габәши язган бу спектакль тамашачылар тарафыннан бик җылы кабул ителә. Шушы вакытта республика җәмәгатьчелеге бу ике сәләтле кызга музыкаль белем бирү хәстәрен күрә. Сара — Мәскәү

консерваториясендә, ә Гөлсем Казан музыка техникумында укый башлыйлар.

Гөлсем уку елларында ук танылган җырчы буларак концертларда чыгыш ясый. Милли музыкада романс жанрына нигез салган композитор Солтан Габәши, «Кәккүк» романсын язгач, аның белән Гөлсемне таныштыра. Гөлсем Сөләйманова башкарган романс авторга һәм җырчыга дан китерә.

1927 елда Казанда радиотапшырулар комитеты оештырыла. Беренче көннән үк Г. Сөләйманова радиокомитетта җырчы булып эшли башлый.

«Иске карурман», «Әллүки», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү», «Салкын чишмә» кебек татар халкының борынгы көйләре Сөләйманова тарафыннан зур осталык белән башкарыла.

1930—1935 елларда С. Сәйдәшевнең музыкаль драмалары сәхнәгә куела, күренекле композиторлар Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Нәҗип Җиһановның иҗат юлы башлана. Шушы күтәрелеш чорында Г. Сөләйманова иҗатына киңрәк юл ачыла: ул композиторлар әсәрләрен беренче булып радио аша җырлый, аларны пропагандалауга күп көч куя.

Җырчы Г. Сөләймановаларның сугыш елларында радиодан чыгышлары ешая, ул төрле өлкәләргә концертлар белән чыга, хәрби частьларда чыгышлар ясый.

Менә шулай туган халкын эстетик яктан тәрбияләүгә, аның зәвыгын үстерүгә бөтен гомерен багышлаган Гөлсем Сөләйманова халыкның яраткан җырчысы булып танылa.

Сораулар һәм бирем

1. Гөлсемнең балачагы нинди шартларда үтә?
2. Җырчының иҗади үсешендә кемнәрнең ярдәме зур була?
3. Татар җыр сәнгатендә Гөлсем Сөләймановаларның роле турында сөйләгез.

Фатих Кәрим
(1909—1945)

Фатих Кәрим (Фатих Әхмәтвәли улы Кәримов) 1909 елның 9 гыйнварында Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында мулла гаиләсендә туа. Авыл мәктәбендә башлангыч белем ала, аннан соң ике ел Бәләбәй педагогия техникумының әзерлек төркемендә укый. Абыйсы шагыйрь Ярлы Кәрим булышлыгы белән Казанга килә һәм Н. К. Крупская исемендәге үсмерләр йортында тәрбияләнә. 1925—1929 елларда Казан Җир төзү техникумында укый.

Фатих Кәримнең әдәби иҗат эше белән җитди шөгыльләнә башлавы да студент елларына карый.

1928 елда «Яшь ленинчы» газетасы чыгарыла башлагач, унтугыз яшьлек Фатих аның җаваплы секретаре була. 1930—1931 елларда «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Атака» (хәзерге «Казан утлары») журналларында, 1937 елның маена кадәр китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты редакциясендә эшли. 1929—1937 еллар арасында аның ун китабы дөнья күрә.

Ф. Кәримнең таланты аеруча Бөек Ватан сугышы чорында ачыла.

Урынсызга рәнҗетелгән, 1937—1941 елларда төрмәдә утырган шагыйрь 1941 елның 1 декабрендә иреккә чыга һәм берничә атнадан фронтка китә. Сугышның соңгы айларына кадәр алгы сызыкта була, берничә тапкыр яралана, шәхси

батырлыклары өчен орден-медальләр белән бүләкләнә. Фронтның авыр шартларында да ул иҗат итә. Аның бу елларда язган шигырьләре, «Гөлсем», «Идел егете», «Кыңгыраулы яшел гармун», «Пионерка Гөлчәчәккә хат», «Тирән күл», «Үлем уены», «Партизан хатыны», «Өмет йолдызы» поэмалары, «Тимер һәм тимерче» балладасы сугыш чоры татар поэзиясендә күренекле урын тоталар.

Бөек Ватан сугышы елларында Ф. Кәрим «Шакир Шигаев» исемле драмасын, «Разведчик язмалары», «Язгы төндә» исемле повестьларын иҗат итә. Автор бу әсәрләрендә дә батыр сугышчыларның җанлы образын тудыра, төрле милләт кешеләреннән оешкан армиянең рухи һәм сугышчан бердәмлеген тасвирлый.

Фатих Кәрим туган иленә әйләнеп кайта алмый: 1945 елның 19 февралендә, бик җаваплы сугышчан задание үтәгәндә, батырларча һәлак була. Аның гәүдәсе Көнчыгыш Пруссиядәге Кёнигсберг шәһәре янында күмелә.

ГАРМУНЧЫ АЮ БЕЛӘН ҖЫРЧЫ МАЙМЫЛ

Җыелып утырыгыз,
Бер әкият укыгыз,
Кызык булса көләрсез,
Башкаларга сөйләрсез.

Моннан күп еллар элек,
Бик еракта, Таулыда
(Таулы дигән авылда)
Бер кеше гомер иткән,
Хәйдәр исемле икән.
Хәйдәрнең аты булган,
Колагы каты булган,
Сызгырсаң ишетмәгән,
Сыптырсаң килешмәгән,
Рәттән тугыз мәртәбә
Тибә булган тәртәгә.

Җәй үткән дә көз җиткән,
Кырда үләннәр кипкән.
Хәйдәр киткән урманга,
Утын кирәк булганга.
Иртән чыгып киткән ул,
Кичкә барып җиткән ул.
Баргач туарган атын,
Салдырмаган камытын.
Ат ачыгып кешнәгән,
Хәйдәр аңа дәшмәгән.
«Түзәр әле»,—дигән дә
Бәйләп куйган имәнгә.
Хәйдәр тәмәке тарткан,
Аннан йокларга яткан.

Бертын изелеп йоклагач,
Төн буе кискән агач.
Кискән күңеле булганчы,
Балта сабы сынганчы.
Кояш чыгып җиткәндә,
Хәйдәр атын җиккән дә,
Күчәр сынар димәгән,
Бар кискәнен төягән.
«Ат бит ул, тартыр ла»,— дип
Кузгалган кайтырга дип.

Ат, төн буе ач торгач,
Йөге дә авыр булгач,
Бер атлый да туктый, ди,
Хәйдәр аны тукмый, ди.
Хәйдәрнең кыйланганын,
Малкайны кыйнаганын
Ак каенда утырган
Саескан күреп торган.
Тузгачтын чыбыркысы,
Хәйдәр тешләрен кысып,

Сыек чыбык алырга дип,
Тагын атны ярырга дип,
Урман эченә кергән
Һәм коточкыч хәл күргән:
Икәү кочаклашканнар,
Ничектер, дуслашканнар
Маймыл белән Аю, ди.
Аю гармун уйный, ди,
Юл буйлап киләләр, ди,
Буылып көләләр, ди,
Маймыл бармак шартлатып,
Урманны яңгыратып:
— Их-ма! — ди икән,
Кычкырып җырлый икән: —
Дошман аяк чала алмас,
Кичәрбез судан, уттан,
Дусыбыз Аю бар чакта,
Безгә диңгез тубыктан.
— Әйттерәләр бит! — дип, Керпе
Төлкегә эндәшәдер...
— Безнең болай дус булуга
Бүре дә көнләшәдер...
— Их-ма! — ди икән,
Кычкырып җырлый икән.

Хәйдәрнең төсе киткән,
Теле кабыктай кипкән,
Калтыраган тезләре,
Шардай булган күзләре,
Карамаган атына,
Качкан куак артына.
Озын койрык Саескан
Каен төбенә поскан,
Курыккан, имеш, үзе дә,
Яшь аккан, ди, күзеннән.

(Аккан яшьнең тирәнлеге
Булган, имеш, тезеннән.)
Маймылның егетлеге:
Булмаса да күзлеге,
Саесканны тиз күргән
Һәм Аюга белдергән.
— Ни кайгысы бар моның? —
Дип, Аю үз гармунын,
Чын гармунчылар сыман,
Култыгына кыстырган.
Саесканга килгәннәр:
— Ник елыйсың? — дигәннәр.

Торса да безнең илдә,
Әллә нинди бер телдә
Саескан сөйләп киткән,
Маймыл тәрҗемә иткән.
Аюның исе киткән.
Саескан, яшен сөртеп,
Киткән Хәйдәрне тетеп:
— Рәхимсез ул, таш күңел,
Башкалар алай түгел,
Киләләр утынга дип,
Шундый ук бер атлылар,
Килгәч йоклап ятмыйлар,
Ашаталар туйганчы,
Атның күңеле булганчы.
Чама белән төйиләр,
Какмый-сукмый йөриләр.
Маймыл йодрыгын төйгән:
— Ай ул Хәйдәрне! — дигән.
Аю, аңлагач хәлне,
Тузып киткән бермәлне,
Үрә торган йоннары.

Ачуыннан җиңнәрен
Сызганырга уйлаган,
Тик күлмәге булмаган.

Барса куак артына,
Анда Хәйдәр утыра.
— Сүс чыбыркың тузганчы
Синме ул ат кыйнаучы,
Төн буе ач тотучы?
Мин сине шуның өчен...—
Дип, Аю күтәргән кул,
Ләкин шулчакны Маймыл
Аюны тотып кала,
Читкә чакырып ала,
Учын куеп, тын гына,
Пышылдый колагына:
— Ни булса шул булган,— ди,—
Калдырыйк бер юлга,— ди.

Аю бертын уйлый да,
Тирән итеп сулый да,
Уйнаклатып киң кашын:
— Риза! — дип селки башын.
Гармуннарын алалар,
Ат янына баралар,
Төрле план коралар,
Торгызмакчы булалар.
Бигрәк Аю тырыша,
Торгызырга булыша.
Иңенә гармун аскан,
Үзе тәртәгә баскан.
Тарта атның койрыгын —
Үти Маймыл боерыгын.
Саескан ара-тирә:
— Әйдә, һап! — дип көч бирә.

Шулай бик нык тырышкач,
Саесхан да булышкач,
Тирлиләр, кызалар, ди,
Атны торгызалар, ди.

Ат ашаган, ял иткән...
Хәйдәр кузгалып киткән,
Саубуллашкан чагында,
(Дөнья хәле тагын да!)
Аю белән Маймылга
Бер үтенече булган:
— Алда бер текә тау бар.
Куркыныч андый таулар,
Атым тыела алмас,
Арбамда утын калмас,
Барысы коелып бетәр,
Хезмәтем бушка китәр.
Зинһар төшерешегез,
Бәясен килешербез,—
Дип, Хәйдәр әйтеп салган.
Тегеләр уйга калган.
«Нишлик икән?» —дигәннәр,
Ахыр чиктә күнгәннәр.
Ярты юлны үткәч тә,
Текә тауга җиткәч тә,
Маймыл, Аю — икесе
Арканның очын кисеп
Арт күчәргә бәйлиләр:
— Рәтен таптык бит! — диләр.
Урап тоталар баудан,
Ат төшә башлый таудан.
Аю, бер кулын болгап:
— Нык тотын,— ди Маймылга.
Икәүләп сөйрәләләр,
Дөберди бүрәнәләр.

Хәйдәр арба өстендә,
Тик курку бар төсендә.
Ул-бу булмасын өчен,
Аю сала бар көчен,
Маңгаеннан тир ага,
Йөрәге дөп-дөп кага.
Авыр була Аюга,
Чөнки гаеп Маймылда:
Ул шунда ук үз эшен,
Гадәтенчә, оныткан —
Бауны буш кына тоткан.
Күчәрнең мыгырдавын,
Май сорап шыгырдавын
Бик кызык эш дип белеп,
Бара, ди, кет-кет көлеп.

Маймыл көлеп барганда,
Тауны яртылаганда,
Көтелмәгән эш чыккан,
Аюның йөрәге купкан:
(Ничек аңларга моны?)
Төшеп калган гармуны.
Белдермәгән Маймылга,
Бауны җибәргән кулдан,
Киткән гармун артыннан.

Арба кинәт тартылган,
Көлеп барган Маймылның
Бау кисеп кергән кулын.
Арба һаман тартыла,
Маймыл карый артына,
Караса, исе китә,
Калтырый — хәле бетә.
— Аю мине утырткан,
Хәйлә белән котырткан...

Маймыл оныта tауны,
Кулдан җибәрә бауны,
Әй йөгерә кычкырып,
Арба китә ычкынып!

Ычкынып китә дә ул,
Чокырга җитә дә ул,
Юллар аерылган чатта
Кинәт борылган чакта,
Каралып торган ярга
Барып бәрелә арба.
Аю тауның башында.
Бу хәлне күреп шуннан,
Ул куркудан шашына,
Кулын бәрә башына.
Маймыл килеп тә җитми,
Аю сорамый-нитми,
Чалт берне яңагына,
Екканчы аягыннан.

Маймыл торган, ди, җирдән.
Бик тиз акылга килгән...
Барып атны тотканнар,
Арбаны утыртканнар.
Хәйдәре дә табылган —
Аның башы ярылган.
Алъяпкычын сүткәннәр,
Аккан канны сөрткәннәр.

Хәйдәр атка утырган,
Үрәчәгә тотынган,
Рәхмәт әйткән илле кат,
Алдында — җигелгән ат.
— На! — дип, атын кузгаткан.
Урман шаулап озаткан:

— Онытма, дустым, шуны:
Бөтен эштә бул зирәк,
Атның таза, тук булуы
Тау төшкәндә дә кирәк!
Аю белән Маймылның
Хәзер кайда булуын
Теләсәгез белергә,
Барып-килеп йөрергә,
Исән-сау, тереләр, ди,
Урманда йөриләр, ди.
Аю һич тә туймый, ди,
Көн-төн гармун уйный, ди.
Маймыл, бармак шартлатып,
Урманны яңгыратып:
— Их-ма! — ди икән,
Кычкырып җырлый икән.

1936

сыптыру — чыбыркы, чыбык белән сугу
колагы каты булу — ишетмәү
тәртә — атны җигеп тарту өчен арбага тоташтырылган колга
камыт — ат муенына кидерелә торган җигү әйбере
күчәр — агач яки металлдан ясалып, башларына тәгәрмәч кидерелә торган үзәк
сыек чыбык — сыгылмалы чыбык
аяк чалу — *монда:* комачаулау
тетү — *монда:* ачулану
үрәчә — арба һәм чананың киңлеген арттырып тора торган иң тышкы агач
зирәк — зиһенле, акыллы

Сораулар һәм биремнәр

1. Хәйдәрнең атын характерлагыз.
2. Хәйдәрнең атына мөнәсәбәте аның нинди кеше булуын күрсәтә?
3. Хәйдәр урманда кемнәрне очрата?
4. Саескан Маймылга Хәйдәр турында нәрсәләр сөйли? Ул аны ни өчен ачулана?

5. Җәнлекләр атны ничек торгызалар?
6. Ни өчен таудан төшкәндә арба ычкынып китә? Сәбәпләрен әйтегез.
7. Киңәйтелгән план төзеп, әкиятнең эчтәлеген сөйләгез.

ҮЛЕМ УЕНЫ

Сугышта үлем
Каршыңа килә,
Йоклап йөрсәң,
Кычкырып көлә.

Кайчак бу үлем
Батырларны да
Бугазлап ташлый
Сугыш кырында.

Менә Сөләйман
Снайпер иде,
Исеме һәркайда
Макталып йөрде.

Орден алды ул
Төз аткан өчен,
Өч йөз фашистны
Озаткан өчен.

Беркөн Сөләйман...
Үлде үзе дә...
Үлсә дә үзе,
Торды сүзендә.

Торды сүзендә,
Ул сынатмады,
Бер пулясын да
Бушка атмады.

Сугышта була
Батыр үлеме,
Дулкынландыра
Сизгер күңелне.

Авыр булды бик
Ул үлгән кичне,
Йөрәкне кысты
Үч алу көче.

Менә кабере,
Кабердә — тынлык,
Кабер өстендә —
Кадерле мылтык.

Кадерле мылтык
Гөлгә күмелгән.
Сөләйман аны
Кочаклап үлгән.

Бу яңа кабер —
Каен астында.
Каен янына
Майор басты да

Сөйләде янып,
Йөрәкне өзде,
Хәтта үзенең
Яшьләнде күзе.

Сулаудан тынды
Бар сугышчылар;
Хыяллар гына
Ерак очтылар;

Очтылар ерак,
Уктай омтылып,
Үчле ачуның
Яшене булып.

Бу үч яшене
Бервакыт сүнмәс,
Аның көченә
Бер фашист түзмәс!

Кабер кырында
Майор тезләнде,
Коңгырт күзләре
Кемне эзләде?

«Кил, Әхтәм,— диде,—
Кабер янына!»
Башлар борылды
Әхтәм ягына.

Мондый вакытта
Уйчан буласың...
Уйчан бер малай,
Зурларча басып,

Килде тын гына:
Пилотка кигән,
Шинель итәге
Җиргә үк тигән;

Билендә каеш,
Бик кысып буган,
Патрон сумкасын
Алга ук куйган;

Юка иренле,
Ак һәм вак теше,
Күзе очкынлы...
Зирәккә охшый!

Гомумән, малай
Кечкенә буйлы,
Бу — Әхтәм инде—
Партизан улы.

Әтисе аның,
Белмим, кайларда,
Хат-хәбәре юк
Соңгы айларда.

Йөридер җимереп
Немецлар юлын,
Эче пошканда
Уйлыйдыр улын.

Кем белсен, бәлки,
Көрәш юлында
Сөләйман кебек
Үлгәндер ул да.

Юк, юк... ул исән,
Ул кылыч кайрый,
Киң урманнарда
Җыры яңгырый.

Улы да аның
Безнең сафларга
Килеп кушылды
Илне сакларга.

Тора ул басып
Майор каршында,
Бәйсез хыяллар
Кайный башында.

Ул — Сөләйманның
Якын иптәше,
Снайперларның
Яшькә иң яше.

Тезләнгән җирдән
Майор кузгалды,
Гөлләр эченнән
Мылтыкны алды.

Яшь снайперны
Майор кочаклап,
Бирде мылтыкны:
— Мә, энем, сакла!

Синең кулыңда
Ул эшсез булмас,
Сиңа күренгән
Фриц котылмас!

Әхтәм кулында —
Кадерле мылтык;
Кабер өстендә —
Дәһшәтле тынлык.

* * *

Озакка бармый
Тынлык сугышта,—
Җай гына эзли
Аяусыз дошман.

Шулай да бу төн
Тын үтте бүген,
Яшенсез булды
Дошманнар күге.

Җыр ишетелде,
Белмим, кайдандыр;
Таң аткач, хәтта
Кошлар сайрады.

Тын сулый таңда
Зәңгәрсу урман,
Ләкин һәр кеше
Мылтыгын корган.

Күк күкерәсә
Бер җирдә хәзер,
Ядрә яңгыры
Яварга әзер.

Шушы тын таңда
Әхтәм күренде,
Котелок тотып,
Ашка йөгерде.

Сипкелле повар
Зур чүмеч тоткан,
Ак түбәтәен
Кырын утырткан.

Повар елмаеп
Честь бирде аңа:
«Казаным иске,
Чүмечем яңа;

Апаң үстергән
Кишер, кәбестә,
Итләре аста,
Өресе өстә.

Чөгендереннән
Тешләр камаша;
Борычы да бар,
Сакланып аша.

Сакланып аша,
Бомба төшмәсен,
Котелогыңның
Төбен тишмәсен!»

Повар такмаклап
Куе аш салды,
Тагын честь биреп
Озатып калды.

Тар сукмаклардан,
Чокырлар буйлап,
Кайтты снайпер
Нәрсәдер уйлап.

Кешенең уен
Белүе кыен...
Кеше уенда —
Шул ук киң дөнья.

Кеше сугышта
Суга да төшә,
Сугышта кеше
Утка да пешә.

Кеше сугышта
Ниләр уйламый,
Сугышта кеше
Үлә — еламый.

Сугышта куба
Иң яман ачу,
Мөмкин түгел һич
Аңардан качу.

Сугышта туа
Тиңе юк дуслык,
Дуссыз күңелдә —
Чиге юк бушлык.

Кайнар күз яше
Сугышта кибә,
Сугышта йөрәк
Ашкынып тибә.

Сугышта кеше
Сикереп уяна,
Эче пошканда
Җырлап юана.

Җырда кайгы бар,
Җырда сагыш бар,
Җырларда шаулый
Таллар, камышлар...

Дөнья байлыгы
Җырларга тула,
Анда юк әйбер
Җырларда була.

Җыр ул аерылмый,—
Һәрчак янында,
Башыңнан сыйпый
Үлгән чагында.

Тын гына җырлап
Таңгы тынлыкта,
Аш алып кайтты
Әхтәм окопка.

Яшел котелок —
Окоп читендә,
Снайпер Әхтәм —
Окоп эчендә.

Чак-чак күренә
Әхтәмнең башы,
Әхтәм кулында
Алюмин кашык.

Котелогыннан
Бу күтәрелә,
Борычлы ашның
Исе бәрелә.

Ашыйсы килгән,
Әхтәм ашыгып
Бу тәмле ашка
Сузды кашыгын.

Сузуы булды,
Шартлады мылтык,
Сүнгән ут кебек,
Югалды тынлык.

Елан тел — ядрә
Үтте сызгырып,
Әхтәм колагын
Уттай кыздырып.

Әхтәм сискәнеп
Яшерде башын,
Аяк астына
Түгелде ашы.

Яшел котелок
Үтә тишелгән,
Һәм ядрә аны
Бәреп төшергән.

Яшен яшьнәде
Немец күгендә,
Утыра Әхтәм
Окоп төбендә.

Окоп төбендә
Посып утыра,
Тикмәгә түгел,
Бер хәйлә кора.

Хәйлә кешене
Ат итеп җигә,
Сугышта хәйлә
Танкны җиңә.

Әхтәм ашыгып
Шинелен салды,
Аяк астыннан
Бер таяк алды.

Пилоткасын да
Салды башыннан,
Тагын бер тапкыр
Котырсын дошман.

Карачкы ясап,
Шул ук урынга
Бастырып куйды —
Алдап торырга.

Тора карачкы
Окоп янында,
Яшел котелок,
Аның алдында.

Карачкы гүя
Аннан аш ашый,
Кайчакта хәтта
Селкенә башы.

Ә үзе Әхтәм
Икенче якта,
Куак астына
Сузылып яткан.

Кадерле мылтык,
Ул да тырыша,
Гүя җаны бар,
Кулга елыша.

Тын алмый Әхтәм,
Немецны көтә,
Канны кытыклап,
Секундлар үтә.

Менә башлана
Үлем уены:
Фашист окоптан
Суза муенын.

Оптик приборда
Әхтәмнең күзе;
Ул, иренен тешләп,
Мылтыгын төзи.

Төзи фашистка
Бик тыныч кына;
Фриц та төзи,
Тик — карачкыга.

Күңел тын булса,
Ышаныч арта,
Әхтәм курогын
Тын гына тарта.

Ычкына ядрә,
Сызгыра шашып,
Актарып ташлый
Фашистның башын.

Әхтәм янында
Күгелҗем төтен;
Әхтәм ни уйлый,
Әйтүе читен.

Траншейда ята
Немец гәүдәсе,
Үлемнән тора
Фашист тәүбәсе.

Тишек котелок,—
Аның ашы юк;
Фашист гәүдәсе,—
Аның башы юк.

Нигә Әхтәмнең
Йомыла күзе?
Керфек астында —
Елмаю эзе;

Иркә елмаю
Балкый бу чакны,
Гүя Сөләйман
Аны кочаклый.

Офыктан кояш
Нурларын сибә,
Нурлар Әхтәмнең
Күзләрен үбә.

Кайгы булганда
Ник моңаймаска;
Шатлыгың булгач
Ник елмаймаска!

Ник елмаймасын,
Ул бит яшь әле,
Ул бу дөньяда
Бик аз яшәде.

Аның атларга
Атланасы бар;
Ерак юллардан
Хат аласы бар.

Озак яшәр ул,
Яшәр, макталыр,
Кош кебек очып
Килер хатлары.

1942

бугазлау — үтерү
коңгырт карасу — көрән төс
өре — итле аш өстенә чыккан май
яман — начар, юньсез, мәкерле, рәтсез
сагыш — берәр нәрсәне яки кешене нык сагынудан, юксынудан туган күңел төшенкелеге, моңаю
уктай — бик тиз, бик җитез
аяусыз — рәхимсез, шәфкатьсез
эч пошу — күңел төшенкелеге
сискәнү — кинәт булган борчылу (курку һ. б.) тойгысыннан кискен калтыранып кую
карачкы — кеше рәвешендә ясалган фигура
гүя — әйтерсең лә; кебек
елышу — кемгә яки нәрсәгә таба булса да әкрен-әкрен хәрәкәт итү, якынаю
күгелҗем — күксел
тәүбә — теге яки бу эшне моңарчы эшләгәненә үкенеп, яңадан кабатламаска бирелгән сүз, ант
юану — берәр кайгы-хәсрәттән арынгандай булу, тынычлану
бу — пар

Сораулар һәм биремнәр

1. Бөек Ватан сугышы турында сез нәрсәләр беләсез?
2. Әсәрдә сугыш вакыйгалары, күренешләре ничек тасвирлана?
3. Снайпер Сөләйманга характеристика бирегез.
4. Җыр нәрсә ул? Кеше тормышында музыкаль әсәрнең роле нинди? Әсәр текстыннан җырга бәйле строфаларны табып, аларны яңадан укыгыз, музыка, моң турында фикер алышыгыз.
5. Снайпер Әхтәмнең сугышчан батырлыгы, осталыгы турында сөйләгез.
6. Бөек Ватан сугышында катнашкан яшь батыр образын тудырган нинди китаплар укыганыгыз һәм фильмнар караганыгыз бар?

Батырлык турында мәкальләр

- Батыр яуда беленер.
- Батырлыкта матурлык.
- Данлы егет ил өчен үләр.
- Ефәк билбау — бил күрке, батыр егет — ил күрке.
- Батыр даны — ил телендә, куркак уе — гел үлемдә.

ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП

Әдәп төбе — матур гадәт

Хат ул — нәрсә дә булса хәбәр итеп, хәл-әхвәлеңне, үз фикерләреңне, хисләреңне белдереп кемгә дә булса язылa торган язу. Гадәттә аны конвертка салып почта аша җибәрәләр.

Хат рәсми яки шәхси булырга мөмкин. Рәсми хат кабул ителгән билгеле бер форма буенча нинди дә булса оешма (уку йорты, колхоз, совхоз һ. б.) исеменнән языла.

Шәхси хатны ничек язарга соң? Бу мәсьәләдә һәр очракка ярый торган ниндидер үрнәк бирү кыен. Шәхси хатлар кешеләрнең шәхси эшләрен, үзара мөнәсәбәтләрен чагылдыра.

Билгеле, бик якын кешегезгә аның белән гадәттә ничек сөйләшсәгез, шундый формада язарга була. Таныш булмаган кешегә, һичшиксез, тыйнак итеп язарга тиешсез.

Тагын бер киңәш: һәр хат эндәш сүз белән башлана, шуңа күрә текст эчендә кабат-кабат эндәшүнең кирәге юк.

Шуны да истә тотыгыз: сезне белмәүче кешегә хат җибәргәндә, имзагызны ачык, төгәл итеп куегыз.

Әгәр берәр нәрсәне язарга онытсагыз, имзадан соң P.S. хәрефләрен куеп (латинча post scriptum — *язылганнардан соң* дигәнне аңлата), фикерегезне өстәп языгыз.

Хатка тиз җавап бирергә кирәк. Эшең никадәр генә күп булса да, кыска гына хат язып салырлык берничә минут вакыт табып була. Хатка җавап бирмәү, бердән, әдәпсезлек булса, икенчедән, сезгә хат язучының да моңа борчылуы мөмкин бит әле.

Түбәндә хат язу үрнәге китерелә. Үрнәк буенча, үзегез дә иптәшегезгә (дәү әниегезгә, апагызга һ. б.) хат язып карагыз.

Кадерле абыем Рәшит!

Язган хатың өчен зур рәхмәт. Әти-әни, дәү әти һәм дәү әни, энең Фәрит һәм мин синең әйбәт хезмәт итүеңә, кәефең яхшы булуга бик сөендек.

Әти һәм әни элеккечә заводта эшлиләр. Дәү әти һәм дәү әни, белгәнеңчә, ялда. Фәрит белән мин мәктәптә укыйбыз. Икенче чирекне икебез дә «4» һәм «5» билгеләренә генә тәмамладык. Дәрестән соң Фәрит — яшь техниклар, ә мин тегү һәм чигү түгәрәгенә йөрибез, өйдә әти-әнигә булышабыз, кибеттән ашамлыклар алып кайтабыз.

Рәшит абый! Без барыбыз да хезмәтеңнең авыр, җаваплы булуын беләбез, сиңа зур уңышлар телибез. Хезмәтеңне уңышлы тәмамлап, безнең янга исән-сау кайтуыңны көтеп калабыз.

Барлык туганнардан, күршеләрдән, дусларыңнан сиңа күп сәлам.

Сине сагынып, гаиләбез исеменнән сеңлең Фәридә.

8 март 2004 ел.

Абдулла Алиш
(1908—1944)

Абдулла Алиш — нигездә балалар язучысы. Ул балаларны ярата, алар белән аралаша, алар белән сөйләшә, аларның телен, теләкләрен, дөньяга үзенчәлекле карашларын яхшы белә иде...

Абдулла Әхмәт

Абдулла Алиш (Габдуллаҗан Габделбари улы Алишев) 1908 елның 15 сентябрендә элекке Казан губернасының Спас өязе (хәзерге Татарстан Республикасы Спас районы) Көек авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. Алты-җиде яшьләрендә әтисеннән укырга-язарга өйрәнә, аннан соң авылдагы башлангыч мәктәптә, 1917—1919 елларда Ямбакты мәдрәсәсендә белем ала, 1919—1921 елларда Бураково авылында ачылган мәктәптә укуын дәвам итә, аннары Спас педагогия техникумы каршындагы җидееллык рус мәктәбен тәмамлый. Мәктәп елларында А. Алиш, фәннәрне яхшы үзләштерү белән бергә, драма һәм әдәбият түгәрәкләре, концертлар оештыру, стена газеталары, кульъязма журналлар чыгару кебек эшләрдә башлап йөри, үзе дә шигырьләр, хикәяләр яза.

1927 елның җәендә Казанга килеп, Казан Җир төзү техникумында укый башлый. Биредә укыганда ул әдәбият белән аеруча кызыксына: әдәбият түгәрәкләренә йөри, техникумда кульъязма рәвешендә чыгып килгән «Кызыл төзүче» исемле газета һәм «Яңа белгеч» журналы редколлегиясенең әгъзасы

була, яшьләр тормышына багышлап язылган хәбәрләре белән республика матбугатында катнаша.

А. Алишны балаларның яраткан язучысы иткән жанр— әкиятләр. Әдипнең «Капкорсак патша» исемле беренче әкияте «Пионер каләме» журналында басылып чыга. Яшь укучылар аны бик җылы кабул итәләр. 1935—1940 елларда А. Алиш егермедән артык әкият яза. Бу әкиятләр җыйнак, уку өчен кызыклы, сурәтләү чараларына бай, образлы тел белән язылганнар.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк А. Алиш сугышка китә, солдат-радист сыйфатында Орлов өлкәсендә барган каты сугышларда катнаша. 1941 елның 12 октябрендә, Десна елгасы буенда чолганышта калып, әсир төшә. Берлин янындагы төрмәдә А. Алиш Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре белән очраша, алар белән бергә яшерен оешмада эшли. 1943 елның августында фашистларга каршы көрәшүче бу оешманың эше ачыла, һәм оешмада торучыларны фашист суды үлем җәзасына хөкем итә.

Абдулла Алишның исеме аның әсәрләре белән бергә яши. Аның «Нечкәбил», «Чуар тавык», «Аны һәркем ярата», «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар» һ. б. әкиятләрен балалар бик яратып укыйлар.

СЕРТОТМАС ҮРДӘК

Борын заманда башы бүрекле, аягы төкле бер үрдәк булган. Ул үзе сайрый белмәсә дә, күргән бер кошына, хайванына, ерткычына озак-озак итеп яңа хәбәрләр сөйләргә бик ярата икән. Тегеләр аның сүзләрен тыңлый-тыңлый арып бетәләр, я бөтенләй тыңламый ташлап китәләр икән. «Ишеттеңме бер яңа хәбәр? Сиңа гына сер итеп сөйлим», — дип башлап китә торган булган ул сүзен.

Бердәнбер көнне йорт хуҗасы үзенең этен иярткән, корыч балтасын биленә кыстырган да урманга киткән. Йортындагы

һәрбер кош-кортына: «Өйдә юклыгымны берәүгә дә белдермәс булыгыз!» — дигән.

«Нигә белдермәскә кушты икән?» — дип, үрдәк йөдәп чыккан, ләкин ни өчен икәнен һич төшенә алмаган.

Кош-кортлар хуҗаларыннан башка бер кич кунганнар, берни булмаган. «Икенче көнне дә кайтмас бу»,— дип, алар хуҗаны чакырып кайтырга берәрсен җибәрергә булганнар. «Син очасың да, син йөзәсең дә, син йөгерәсең дә, син бар!»— дигәннәр алар үрдәккә. «Ләкин берүк нишләп йөрүеңне берәүгә дә белдертәсе булма!» —дигәннәр. Үрдәк күнгән: «Ярар, сезнең хакыгыз өчен генә барсам барырмын инде»,— дигән.

Иртә торгач та үрдәк уйлап-нитеп тормаган, тамагын туйдырган да юлга чыккан. Башта ул канатларын кагып очкан, оча-оча бер елгага барып төшкән. Ишкәкләре-тәпиләре үзендә булганга, аптырамаган, йөзеп тә киткән. Елга буйлап озак йөзгәч, корыга чыгып тәпи-тәпи дә йөгергән...

Бара-бара куе бер урманга барып җиткән. Төрле тәмле җиләкләр, симез бөҗәкләр ашый-ашый, урманга кереп тә киткән.

Үрдәк күбәләк куып йөргәндә, аның каршысына бер керпе килеп чыккан һәм аңа сүз дә кушкан:

— Кая барасың болай? — дигән.

Үрдәккә инде шул гына кирәк тә икән. Юл буе берәү дә очрамаганга, берәү белән дә җәелеп сөйләшергә туры килмәгәнгә аның бик эче пошкан булган, иптәшләренең әйткәннәрен дә оныткан, сүз артыннан сүзне тезәргә тотынган:

— Урманда утын кисүче хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез дә аңа ияреп киткән иде. Хәзер йорт-җирне саклаучы берәү дә юк. Аларны чакырып кайтырга иптәшләрем мине җибәрделәр,— дигән.

— Синең өең еракмы соң? — дигән керпе.— Анда симез тычканнар, усал еланнар юкмы? — дип сораган. Аның үз хәле хәл, бик нык ашыйсы килә икән.— Менә шушы сукмак безнең өйгә туп-туры алып бара, бер кешегә дә әйтмә, кара! — дигән үрдәк. Өйләрендә еланнарның бөтенләй юклыгын,

тычканнарга көн бирмәүче мәченең шуклыгын да сөйләп биргән.

Алар дус булышып аерылышканда, энәле кием кигән булса да, керпе бик файдалы киңәш биргән:

— Мин инде андый усалларның берсе дә түгел, синең серләреңне белсәм дә, каян килүеңне күрсәм дә, сиңа зарарлы эш эшләмәм. Шулай да син саграк бул. Очраган берәүгә серләреңне сөйләмә. Сереңэчеңдә торса, йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр,— дигән.

Керпенең бу акыллы киңәшенә үрдәк һич колак салмаган, ашыга-ашыга урман эченәрәк атлаган.

Бара-бара үрдәккә озын колаклы бер куян очраган, һәм ул да аңардан сораган:

— Әй бүрекле үрдәк, күзге төсле матур, кыр төсле зур күл булганда, ни эшләп урманда буталып йөрисең?

— Хуҗабыз белән этебез урманга утын кисәргә киткәннәр иде, өебез ялгыз калды,— дигән үрдәк, керпегә сөйләгәнне моңа да сөйләп биргән. Куян эченнән генә: «Алай булгач, хуҗаның алмагачларын кимерергә барырга бик җайлы вакыт икән»,— дигән. Үрдәктән өйләренең кайдалыгын сорашкан, теге, юләр, моңа да серен ачкан.

— Хуҗаңны күргәнем юк,— дигән дә куян куаклык эченә кереп югалган.

Үрдәк тагын алга киткән. Бара-бара бер аланга барып җиткән. Анда бер зур соры аю мышный-мышный йоклап ята икән. Үрдәк аны да уяткан. Керпе белән куянга сөйләгән сүзне аңа да сөйләп биргән. Сүз ахырында аюдан сораган:

— Эт ияркән, кулына балта тоткан кешене күрмәдеңме?

Аю:

— Күрмәдем,— дип җавап биргән. Үрдәкнең кайгысын уртаклашкандай булып кыланган: «Урман эченәрәк керсәң, һичшиксез, табарсың»,— дип, юл өйрәтеп җибәргән. Ә үзе эченнән генә: «Хуҗаның умартасын ватып, бал ашап кайтырга бик җайлы вакыт икән»,— дип, ашыга-ашыга китеп тә барган.

Үрдәк һаман хуҗасын эзләвен дәвам иткән. Аның саен урманның эченәрәк керә барган. Бара торгач, аның каршына бүре килеп чыккан һәм аңа сүз кушкан:

— Әй бүрекле баш, шушындый куе урманда япа-ялгызың гына курыкмыйча батырланып ничек йөрисең? — дигән. Теге дә үзенең ник йөрүен сөйләп биргән. Хуҗаның өйдә юклыгын, этнең дә аның белән бергә ияреп китүен бүрегә дә әйткән. Усал бүре тешләрен шакылдаткан, үз-үзенә: «Боларның сарыкларын барып ашап кайтырга бик җайлы чак икән»,— дигән, ә үрдәккә: «Андый кешене күргәнем юк!» — дип, куаклар арасына кереп югалган.

Үрдәк һаман туктамаган. Хуҗасын эзләүне дәвам иткән. Күргән бер коштан, төрле ерткычтан, хәтта нәни бөҗәклардән дә бу турыда сорашып бара икән.

Бара-бара аның каршысына көлтәдәй койрыклы бер төлке килеп чыккан. Теге дә ахмак бит, моңа да сүз кушкан:

— Багалмакай, матур апакай, минем хуҗамны күрмәдеңме? — дигән.— Янында эте, кулында балтасы бар иде,— дип өстәгән. Хуҗасыз һәм этсез өйдәге хайваннарның тынычсызлануларын, алардан башка куркуларын да сөйләп биргән.

— Чибәрләрнең чибәре, гәүһәрләрнең гәүһәре, күрдем мин аны! — дигән төлке.— Янында кәкре койрыклы эте дә, билендә корыч балтасы да бар иде,— дип өстәгән. Үрдәкне үзе белән ияртеп киткән. Алар бик озак барганнар һәм куак белән капланган елга буена килеп туктаганнар. Шунда төлкенең оясы буенда балалары уйнап йөриләр икән.

Алар:

— Әни, безгә азык алып кайттыңмы? — дип, аның тирәюнен сырып алганнар, ә ул, авызын ерган килеш, үрдәккә күрсәткән...

— Менә, бәбкәләрем, сезгә тәмле үрдәк ите,— дигән һәм шул минут үрдәкне буып, балаларына бүлеп тә биргән. «Үрдәк ите бигрәк тәмле була икән!» — дип, алар, авызларын ялый-ялый, аны ашап та ташлаганнар, ләкин туймаганнар, аналарыннан тагын да сораганнар.

— Хәзер, бәбкәләрем, авылга барам, берьюлы берничә үрдәк алып кайтам,— дигән төлке. Балаларын калдырып, авылга киткән.

Бер сертотмас үрдәк аркасында бу хуҗалык тәмам туздырылган булыр иде, ләкин хуҗа уяу кеше булган, дошманнарына каршы һәр җирдә киртә куйган. Куян рәшәткә арасыннан үтә алмаган, кире борылган. Аю бәрәңге базына төшкән, бүрегә дә сарыклар эләкмәгән, хуҗаның абзарына ул бөтенләй керә алмаган. Төлке, хәйләкәр булса да, сыза алмый калган, үрдәк ите ашыйм дигәндә генә, капкынга эләккән, ә хуҗа кайткач инде аның кирәген биргән... «Тагын берничәне тоткач, толып тектерермен»,— дигән һәм тиресен киптерергә амбарга элгән.

Хайваннар эшнең нидәлеген хуҗага сөйләп биргәннәр. Сертотмасны шундый зур эшкә кушуларына алар да бик нык үкенгәннәр.

төк — йон
йөдәп чыгу — аптырап бетү, гаҗәпләнү
күнү — риза булу, килешү
колак салу — тыңлау
алан — урман эчендәге агачсыз, ачыграк урын
умарта — бал кортларын асрау өчен эшләнгән оя
хуҗалык — *монда:* йорт

Сораулар һәм биремнәр

1. Әкиятне укыгыз һәм, киңәйтелгән план төзеп, эчтәлеген сөйләгез.
2. Бу әкияттә нинди хайваннар катнаша? Һәркайсының характерлы сыйфатларын ачыклагыз.
3. Сертотмас үрдәк ни өчен бәлагә дучар була?
4. Үрдәк сер тотмаса да, аучы хуҗалыгына зыян килми. Ни өчен дип уйлыйсыз?
5. Йорт хайваннары яки ерткыч хайваннар турында тагын нинди әкиятләр укыганыгыз бар?
6. Түбәндә китерелгән табышмак һәм мәкальләрне укыгыз. Үзегез дә мисаллар уйлагыз.

Башы бүрекле, аягы төкле.
Оча да, йөзә дә, йөгерә дә. Нәрсә ул? *(Үрдәк.)*

Бер йомгакта мең энә,
Сиңа тими, син тимә. *(Керпе.)*

Җәен соры, кышын ак,
Аңа шулай яхшырак. *(Куян.)*

Җәен урманда патша,
Кышын кардан да аста. *(Аю.)*

Кош түгел, оча,
Ябалактан курка,
Чикләвекне ярата,
Сызгырса, урманны яңгырата. *(Тиен.)*

Үлән ашый, май ташый. *(Сыер.)*

Сакалы бар, акылы юк. *(Кәҗә.)*

Бәләкәй генә буйлы,
Әйләндереп кигән тунлы. *(Сарык.)*

Тимерче дә түгел,
Балта остасы да түгел,
Үзе авылда беренче эшче. *(Ат.)*

Сереңэчеңдә торса,
Йортың тыныч булыр,
Җимерелмәслек нык булыр.

Аерылганны аю ашар,
Бүленгәнне бүре ашар.

Йорт хайваннары турында сөйләшү өчен сораулар

1. Йорт хайваннарын санап чыгыгыз. Кайсылары сезгә аеруча ошый? Ни өчен?
2. Аларның тышкы кыяфәтен, табигатен тасвирлагыз.
3. Йорт хайваннарыннан ат, сыер турында сөйләгез.
4. Этне сез ни өчен аеруча яратасыз? Эт — кешенең дусты, дип әйтәбез. Моны дәлилләгез (исбатлагыз).
5. Сезнең этегез яки мәчегез бармы? Булса, сез аларны ничек тәрбиялисез, нәрсәләргә өйрәтәсез?

ЧУАР ТАВЫК

I

Безнең Җамал әбинең бер чуар тавыгы бар. Бер авылда да юк бу тавыкка пар. Чуар тавыкны тавык димәсәң, Җамал әбинең хәтере калыр, бу сүзне улы Гата да күңеленә авыр алыр. Күгәрченнән кечкенә, сыерчыктан зур — чуар тавык әнә шундый ул.

Чуар тавык ул күпне күргән, ике-өч еллык гомерендә берничә оя чебеш тә үстергән. Ул да, Җамал әби төсле, үзенең якыннарына: «Әкренләп картаям инде»,— дигән, аның төсле үк итеп, башына бүрек тә кигән.

Ләкин Җамал әби җимне бик әз бирә. Чуар тавык кайда туры килсә шунда тибенә, атнага бер-ике йомырка сала, күп вакыт кыртлап кына кала.

«Салгандыр»,— дип, оясын капшыйлар, ләкин йомыркасын тапмыйлар.

II

«Ай күрде, кояш алды» дигәндәй, көннәрнең берендә чуар тавык каядыр югалды. Эзләмәгән урынны калдырмадылар, бөтен дөньяны актардылар, һичкайдан да таба алмадылар.

Эзләп-эзләп тә тапмагач, ашарга да кайтмагач, Җамал әбинең инде өмете тәмам өзелгән иде, чуар тавыкны үлгәндер дигән иде. Ләкин бер дә көтмәгәндә, кайтыр дип һич өмет итмәгәндә, чуар тавык кайдандыр үзе килеп чыкты.

Амбар алдында җим чүпләгән башка тавыклар арасында кыртлап йөрүче чуар тавык күренде. Җамал әби белән Гата аны күрделәр дә: «Чуар тавык утыра башлаган икән»,— диделәр. Гата тавыкны күзәтергә булды, шуның өчен ул бер почмакка посып торды.

Җим ашап туйгач, берничә тамчы су да эчеп куйгач, чуар тавык борынын бер-ике тапкыр җиргә ышкыды. Канатларын кагып, тузаннарын койды.

«Утыра торган йомыркаларым суынмасыннар, чәберчек булмасыннар»,— дип, оясына ашыкты чуар тавык.

Гата да йоклап тормады, поскан җиреннән чыкты да тавык артыннан атлады. Кетәклек башында, өрлек астында, салам куышында иде чуар тавыкның оясы. Оясына менеп җиткәч кенә, йомыркаларны җылытыйм дигәч кенә артка чигенде чуар тавык. Бөтен көченә чырлый башлады һәм, күп тә үтмичә, оясындагы дошманга ташланды. Һөҗүмгә түзә алмыйча, оядан нидер атылып чыкты, хәтта Гата да курыкты, арткарак чигенде, озак уйлап тормады, әнисенә йөгерде.

III

Әнисе белән икәүләп килделәр. Югары менделәр. «Кара син аны, качкын тавык!» — диделәр, азрак тиргәделәр.

Чукуына исе китмәде, куркынмады, артка чигенмәде. Җамал әби чуар тавыкның канат астыннан тотып, югары күтәреп карады. Чуар тавык чырлады, тыпырчынып әбинең кулын чукыды. Гата да тик тормады, тавык астындагы йомыркаларны санады.

Җамал әбигә берьюлы ике шатлык туды: ярты дистә йомырка да булды, чуар тавык та табылды.

Гата йомыркаларга үрелде, берсен кулына алды һәм хәйранга калды, йомырка, ничектер, бик җиңел күренде, нык лабрак караса, коры кабык кына лабаса. Әйе, өч йомырканың коры кабыгы гына калган, эчен нәрсәдер бик чиста итеп суырып алган.

Кем эше икәнне шунда ук сизенделәр, качып баручы соры песине күрделәр. «Бу — синең эш!» — диделәр. Шулай итеп, мәченең юлы уңмады, Җамал әби белән Гата очрады. Шуңа күрә ул койма тишегеннән аргы якка сикерде, башлаган эшен шулай бетерде: мыек буялмады, тамагы туймады, берни булмады.

Җамал әби чуар тавыкны кыртлавыннан биздерергә тотынды. Чуар тавыкның кайнар түшен суга тидерде. Тагын бер әмәл тапты, тавыкны сулы кычыткан белән чапты. Ләкин чуар тавык кыртлавыннан бизмәде. Һаман-һаман утырырга оя эзләде.

IV

Төрле юллар белән дә кыртлавыннан бизмәгәч, һаман утырырга йомырка эзләгәч, чуар тавыкны утыртырга булдылар.

Җамал әби йомырка сайларга утырды. Аның бу эшен Гата күрде:

— Ул йомыркаларны куырып ашарбыз, менә дигән әрләрен табарбыз. Күрше колхозның фермасына барырмын, нәселле тавыкларныкын алырмын,— диде.

Һәм шулай да итте. Җыенып фермага китте.

Ферма эче күркә хәтле зур-зур тавыклар белән тулган: апаклар, кып-кызыллар — кыткылдый-кыткылдый йомырка салалар.

Ферма мөдире Миргалим абзый Гатаны көлеп каршы алды, исәнлеген сорашкач, ферманы күрсәтә башлады:

— Менә бусы безнең тавыклар, алар шушы чиста тигәнәләрдән ашыйлар, үләнлеккә чыгып йөриләр, ояларына кереп йомырка салалар.

Миргалим абзый комод төсле бер әйбер янына туктады, үзе Гатага сорау бирә башлады:

— Сезнең чуар тавык ничә чебеш чыгара?

— Күп булса егермене,— ди Гата.

— Ә безнең тавык, туганкай Гата, берьюлы биш мең чебеш чыгара ала. Сездә чебешләрне җәй көне генә күреп була, ә безнең ферма кыш көне дә чебешләр белән тула. Безнең тавык менә нинди уңган, асрасаң, шундый тавык асра син, туган.

Бу сүзләрне тыңлаган Гата шакката:

— Ул нинди тавык, күрсәтегез зинһар табып,— дип ялынырга тотына.

Ә Миргалим абзый, мыек астыннан елмаеп, Гатага тавыкны күрсәтеп тора:

— Менә бу нәрсә комод түгел — инкубатор. Электр белән эшли торган чебеш анасы. Шушы тартмасына йомырка саласы. Электр лампалары тартма эчендәге һаваны җылыта, йомыркаларны һава җылытып тора.

— Ә йомыркалар ничек пешмиләр? Чебешләр ничек үлеп бетмиләр?— ди Гата.

— Бу машинаны уйлап табучы кеше бик башлы булган, ул да синең кебек төрлечә уйлаган. Артык кызуга китсә, бу лампочка үзеннән-үзе сүнә. Чебешләр чыккач, аларны башка җиргә күчерәбез, менә шулай итеп күп чебеш үстерәбез,— ди Миргалим абзый.

— Мин, Миргалим абзый, сиңа зур йомыш белән килдем, әнигә: «Без дә нәселле тавыклар асрыйк!» — дидем, ярдәм сорап сиңа килдем, Миргалим абзый кире какмас, дидем.

— Үрнәк күрсәтерлек эшкә тотынгансың, тырышырмын, кулымнан килгәнчә булышырмын,— ди Миргалим абзый.

Ферманы карап бетергәч, Гата җырлый-җырлый өенә кайта. Шатлыгыннан авызы ерыла, туктаусыз елмаеп тора. Кепкасындагы йомыркаларны әнисенә бирә, ферма хәлләрен сөйләп аны да сөендерә. «Ялгыш алып кайткансың, улым, кире илт, бар, каз йомыркалары ич болар!» — ди Җамал әби. Гатага кызык, ул һаман көлә-көлә әнисенә сөйли: «Нәселле тавык йомыркасы шул ул!» — ди.

Җамал әби кычытканын да ташлады, чуар тавыкны суга да манчымый башлады, ящикка салам түшәп оя ясап бирде, йомыркаларны йомшакка тезеп куйды, чуар тавыкны сөендерде.

V

Икенче көнне Гата, сазга бата-бата, куып йөрде бака. Бакалар Гатадан хәйләкәррәк булдылар, ул килгәнне ишетүгә, берәм-берәм суга чумдылар. Шуңа күрә аларның берсен дә тота алмады, авызын ачып тик карап калды. Камышлыкка кача-кача, Гатаны үртәгән шикелле, кычкырды бака: «Ба-ка-ка-ка... Ба-ка-ка-ка».

Йөри торгач саз буйлап, төрле-төрле уй уйлап, Гатага йомыркалар очрады.

Саз эчендә кыяклы түмгәк өстенә чыбык-чабыклар, йонмамыклар өеп үрдәкләр оя ясаганнар. Шунда ана үрдәк

йомырка салган. Бала чыгармакчы булган. «Нәни генә бәбкәләр үстерербез, җәйне рәхәтләнеп үткәрербез»,— дип уйлаганнар иде үрдәкләр.

Гата бу йомыркалар өчен бик сөенде, үз-үзенә: «Боларны алып кайтыйм мин»,— диде. Биш йомырканы да эшләпәсенә салды, маяга берәрсе калсын да димәде.

Гатаның уйлары бик озак сугыштылар: «Син табигать сөюче, файдалы кошларның тормышлары өчен көюче, аларга булышлык итүче, иркенлек бирүче, ни эшлисең син?»— диделәр. Гата бу уйларны тыңламады, үзенекен итте, үрдәкләрне кызганмады, йомыркаларның барысын да алып китте.

Үрдәкләр тирги-тирги баш очында очып әйләнделәр, җитмәсә башка кошлар да бәйләнделәр. Акчарлак: «Кызганмадың, барын да алдың»,— диде. Тәкәрлек: «Син бик начар егет»,— диде. Ә Гатаның берсенә дә исе китмәде:

Акчарлак, акчарлак,
Акчаң булса, миңа бир,
Тәкәрлек, тәкәрлек,
Тәңкәң булса, миңа бир,—

дип җырлый-җырлый өенә кайтып китте.

кыртлау — тавыкның өзек-өзек авазлар чыгаруы
кетәклек — йорт кошлары асрау өчен махсус урын
күк — кебек, төсле
чәберчек — кош басып утырганда бала чыкмыйча бозылган йомырка
әмәл — җай, чара
чекерәю — гаҗәпләнү, куркудан һ. б. күзләр кысылу
тигәнә — бербөтен агачтан чокып ясалган озынча улак, тагарак

Сораулар

1. Чуар тавык сезгә ошадымы? Ни өчен?
2. Чуар тавык башына нинди игелекле уйлар килә?
3. Ферма мөдире Миргалим абзый Гатаны нәрсә белән сөендерә?
4. Хикәя текстыннан электр белән эшли торган чебешләр анасы — инкубатор хакында ниләр белдегез?
5. Үрдәк, акчарлак, тәкәрлекләр Гатаны ни өчен тиргиләр? Гата бу очракта нинди ярамаган эш эшли?

VI

Әллә ни булган төсле, Гата ишектән йөгереп керде дә эшләпәдәге йомыркаларны тизрәк әнисенә бирде:

— Менә, әни, нәрсәләр таптым, бер кызык эшләр өчен алып та кайттым,— диде.

Җамал әби башта аптырап калды. Соңыннан гына аңлап алды. Әй орышырга тотынды Гатаны:

— Хәзер үк кире илт, күземә күренмә, моннан соң бер кошның да йомыркасына үрелмә!

Гата аптырамады, җавапсыз калмады:

— Мин дә бит аларны уйнарга дип алмадым, берсен дә ватмадым, яхшы сакладым, бер тәҗрибә эшләргә уйладым,— диде.

Гата теләгенә бик тиз ирешмәде, Җамал әби тиз генә бирешмәде. Аңа бик озак ялынырга туры килде, Җамал әби бик авырлык белән генә күнде.

Чуар тавыктан бәбкә чыгартырга булдылар. Шул теләк белән үрдәк йомыркаларын да тавык оясына куйдылар.

VII

Өч атна дигәндә, йомыркалар борынладылар, берәм-берәм чебешләр чыга башладылар. Өч-дүрт көн үткәч, бәбкәләр дә чыктылар. Җамал әби чыккан берсен җылы бүреккә җыя барды. Чебешләр уникс булды, бәбкәләр белән унбишкә тулды. Бу чебешләр һич тә элеккегеләр кебек түгелләр, бик терeләр. Аларга караганда күп өлеш зурлар, мондыйларны кем хурлар!

Ике көн үткәч, чебешләр һәм бәбкәләр бары да чыгып беткәч, Җамал әби күптәнге уен эшкә ашырды. Чебешләр һәм бәбкәләрне чуар тавыкның үзенә тапшырды.

Гата да чебешләрне Җамал әби төсле үк сөйде. Аларның язмышы өчен көйде. Күп вакыт аның көне чебешләр янында үтте, ул аларны саклады, усал дошманнардан яклады, я су эчертте, я ярма сипте.

Ишегалдын бер итеп кыртлый чуар тавык, үзе чебешләре тирәли йөри чабып. «Пи-пи-пи, әни, бир ипи»,— диләр чебешләр. Әниләре чакыргач, йөгерешеп килделәр, җим эзләделәр, нәни тәпиләре белән тибенделәр, ямь-яшел чирәмлеккә сибелделәр.

Кинәт ала каргамы, кара каргамы күренде. Әйтерсең ул берәр чебешне эләктерергә үрелде. Чуар тавык моны бик тиз сизенде, бик әче тавыш белән кыртлап җибәрде. Минут эчендә әйтерсең ут эчендә калдылар чебешләр. Кайсы кая качып беттеләр. Кайсылары әниләре канаты астына кереп киттеләр.

Ләкин карга тиз югалды, чөнки чуар тавык та сизенеп калды, җитмәсә, Гата да кузгалды. Тиз генә кулына таш алды, һавага җибәрде, ташы әз генә каргага тимәде.

Беләсезме, ул карга түгел икән, ул булган тилгән, күрәсең, чебеш ите ашыйсы килгән, ах үләт тигән!

Әнә ничек кызарып байый кояш...

Яктылык сүнә, әзәя, караңгылык үзенең канатын җәя...

Чебешләре дә чәрелдиләр: «Йоклыйсыбыз килә, әни, йоклыйбыз!»— диләр. Чуар тавыкның канат астына тулалар, күзләрен йомалар, татлы йокыга чумалар.

VIII

Төн уртасы җиткәч, барлык шау-шу тынып беткәч, кошкорт йокыга киткәч, Җамал әбигә тагы эш чыкты.

Йоклый иде ул тәмле төш күреп, төшендә көмеш кебек чәчләрен бер сүтеп, бер үреп, нәкъ шул вакыт нидер чырлады, бу тавыш төнге тынлыкта тагын да куркынычрак булып яңгырады.

Галошын да эләктермәде, өстенә дә кимәде, Җамал әби ишегалдына атлады.

Ни күзе белән күрсен, ни җаны белән түзсен, чуар тавыкның чебешләре тузгыган. «Тукта әле, тукта, чебешләр нигә болай аз калган?» — ди Җамал әби.

Ундүрткә кадәр санады,
Барысын да барлады.
Ә унбишенчесе кая?
Югалган бит, бичара!

Йокысы йокы булмады, күзе йомылмады, йокы күрмәде, һаман чебеш урлаучы дошманны тиргәде: «Минем чебешемә тигән өчен муены астына килсен!»

Ләкин дошманның кем икәнен тиз сизделәр. Гата да усал, кайдандыр капкын алып кайтты, аңа ит кисәге куйды, ә үзе тыныч кына йокларга ятты. Чуар тавыкны да ишегалдында калдырмадылар, җыйнак кына оя ясадылар, чебеш һәм бәбкәләре белән шунда яба башладылар.

Иртәгесен Гата чыгып капкынын караса шакката, капкында авызын ачкан көзән ята...

IX

Чебешләр дә, бәбкәләр дә үсә башладылар, ишегалдында йөрүне генә ташладылар. Чуар тавык аларны урамга да алып чыгарга күнде, ләкин бу эшенә соңыннан бик үкенде, чөнки ул эш аңа зур кайгы китерде.

Яңгыр арты иде. Көн бик матур иде. Чебешләр капка астыннан урамга сибелделәр. Черкелдәп-черкелдәп җим эзләп тибенделәр.

Чуар тавык үзенең балаларына карап куанды. Аларның киләчәкләрен, зур үсәчәкләрен уйлап юанды.

Әнә анда көмеш сулы күл ялтырап ята. «Ашап туючыларны сыйлыйм, татлы сулы мин»,— дигән төсле, бу күл безнең танышларны үзенә чакыра. Чебешләр йөгереп киләләр дә суны тамчылап кына эчә биреләр.

Әнә бәбкәләр дә килеп җиттеләр. Алар инде тамчылап кына эчеп тормадылар, шуптырдый-шуптырдый, күл эченә кереп киттеләр. «Ничек боларның йөрәкләре житте!» — дип, яр кырыендагы чебешләрнең исләре китте. Бәбкәләр үзләре генә булса, бер хәл иде, ә әниләре — чуар тавыкны хур иттеләр. Ул да балаларыннан калышмаска теләде, күлгә якын

килде, ләкин кермәде, бер-ике тамчы су чәчрәве чуар тавыкны куркытырга җитте.

Бәбкәләр бер-берсенә: «Без дә яшәгәнбез, ләкин шушындый рәхәт барын белмәгәнбез!» — диештеләр. Куышып уйнадылар, уйнап-уйнап туймадылар. Чуар тавыкның: «Кайтабыз, каласыз, кузгалабыз, югаласыз»,— дип кыткылдавы да һич файда бирмәде. Бәбкәләр күлдә калдылар, әниләре чакырган саен эчкә керә бардылар.

Чуар тавык, чебешләрен генә ияртеп, аһ-ваһ итеп кайтып керде. Җамал әбигә: «Тыңламадылар, калдылар, котырдылар!» — дип сөйләп тә бирде. Үзенчә кыртлап күрсәтте, ә әби аңламады, кыртлауны тыңламады. «Көш тә көш!» — дип куып йөдәтте.

Бәбкәләрне күл буеннан Гата алып кайтты... Ул бу эшкә артык әһәмият бирмәде, аларны чебешләр белән бергә үк япты.

Шул көннән башлап бәбкәләр чуар тавыкны ана итмәделәр. Өчәүдән-өчәү күлгә йөри башладылар, чуар тавыкның канат астын һәм чебеш туганнарын мәңгегә ташладылар.

X

Көз якынлаша, бай көз. Сез шуны сизәмсез? Ашлык төягән арбалар шыгырдый, бертуктамый яңгыр шыбырдый. Ә кояш исенә төшсә генә бер карый, анысы да күңелгә ярый.

Чебешләр инде тавыктай зур булдылар, әниләреннән аерылдылар. Хәзер аның белән бергә дә йөрмиләр, канат астына да кермиләр. Колгага менеп кунаклыйлар да рәхәтләнеп йоклыйлар. Әтәч чебешләр таңны каршы алалар, шапылдатып канат кагалар, киерелеп-киерелеп кычкыралар, үзләренчә күңел ачкан булалар.

Бәбкәләр тәмам үрдәк булдылар, элеккечә һаман судан туймыйлар. Көне-төне күл буенда йөриләр, өйгә кайтып та кермиләр.

Их син, чуар тавык, бичара, балаларың белән үлчәшеп кара! Арагызда аерма бар күп кенә, алар янында син үзең хәзер чебеш күк кенә!

XI

Уңыш бәйрәмендә бик шәпләп сыйланырга, үрдәкләр суярга, шулпалы бәлешләр салырга уйлаганнар иде...

Матур уйларының, уңыш туйларының бу өлеше күңелсез булып бетте, эшләре бераз чуалып китте.

Мондый усал ниятне үрдәкләр ишеттеләр, җыелып киңәш иттеләр, котылу юлын эзләргә керештеләр.

Кайсы әйтә: «Суга чумарга кирәк»,— ди, кайсы: «Болында кунарга кирәк»,— ди.

Берсе әйтә: «Урманга качыйк»,— ди, икенчесе: «Ничек тә котылып калыйк»,— ди. «Очыйк!» — дип берсе дә әйтмәде, шуңа төшенергә башлары җитмәде.

Бары да үзенчә тырышкан була. Котылырга план корышкан була.

Йолдызлар чекерәеп карап торганда, күл өсте ай нуры белән тулганда, үрдәкләр шулай уйга чумганда, күктән бик җитез итеп канат җилпегән тавыш ишетелде. Кыр үрдәкләре очтылар: «Җылы якка әйдәгез, монда калсагыз туңып үләрсез!» — дип кычкырып уздылар.

Муеннарын сузып, башларын кыңгыр салып, күлдәге үрдәкләр бу тавышны тыңладылар.

Бу тавыш күңелләрен уятты, «Безгә дә очарга кирәк!» дигән теләкне кузгатты. Канатларын җилпеп күлдән күтәрелделәр, очып баручы кыр үрдәкләренә иярделәр.

Җамал әбинең морҗалары турында өч мәртәбә әйләнделәр: «Безне кабат күрмәссез, хушыгыз инде!» — диделәр.

көзән — сусарлар семьялыгыннан кыйммәтле мехлы кечкенә җәнлек
тилгән — карчыгалар семьялыгыннан ерткыч кош
юану — тынычлану, онытылу, мавыгып киту
җилпү — канатны кагу (кошлар турында)

жим — азык
үләт — күпләп үлү (эпидемия)
барлау — барлыгын дөресләп тикшерү
бичара — мескен, кызганыч
капкын — ау җайланмасы
куану — шатлану

Сораулар һәм биремнәр

1. Җамал әби улы Гатаны ни өчен орыша?
2. Чуар тавык йомыркаларны җылытып ничә чебеш һәм бәбкә чыгарган?
3. Чуар тавык чебеш һәм бәбкәләрен тилгән явыздан ничек коткара?
4. Җамал әби белән Гатага көзән нинди яңа борчулар тудыра?
5. Су буена төшкәч, чуар тавык белән чебешләр нинди хәлгә калалар?
6. Кыр үрдәкләренең: «Безне кабат күрмәссез, хушыгыз инде!» — дип очып китүләре сездә нинди уйлар тудырды?
7. Йорт хайваннарын, кош-кортларны ашатырга, тәрбияләргә яратасызмы?

Фатих Хөсни
(1908—1996)

Фатих Хөсни (Фатих Хөснетдин улы Хөснетдинов) 1908 елның 3 февралендә элекке Казан губернасы Лаеш өязе (хәзерге Татарстанның Теләче районы) Олы Мәтәскә авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туган. Башлангыч белемне авыл мәдрәсәсендә ала. 1924 елда Казанга килә һәм Мулланур Вахитов исемендәге күргәзмә-тәҗрибә мәктәбенә укырга керә. Шунда укыганда каләм тибрәтә башлый. «Безнең юл» (хәзерге «Казан утлары») журналының 1927 елгы 4—5 нче саннарында унтугыз яшьлек егетнең «Дөнья матур миңа» исемле беренче шигыре басылып чыга.

1929—1933 елларда Фатих Хөсни Казан дәүләт финанс-экономика институтында укый. Аны тәмамлагач, Татарстан Финанс министрлыгында эшли. 1935 елдан Ф. Хөсни «Кызыл Татарстан», «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газеталары, «Совет әдәбияты» («Казан утлары») һәм «Чаян» журналлары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, 1955—1957 елларда Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре вазифаларын башкара.

Бөек Ватан сугышы чорында әдип, барлык язучылар кебек үк, каләм көчен фашизмга каршы көрәшкә юнәлтә. Ватан сугышы темасы, халкыбызның фронттагы һәм тылдагы батырлыклары аның шул еллардагы күп кенә әсәрләрендә чагыла. Алар арасында «Йөзек кашы» (1942) повесте аеруча

игътибарга лаеклы. Бу әсәр рус, үзбәк, казах телләрендә дә дөнья күрде.

Бөек Ватан сугышыннан соң язылган зур күләмле әсәрләре — «Авыл өстендә йолдызлар», «Минем тәрәзәләрем», «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» повестьлары, «Җәяүле кеше сукмагы», «Утызынчы ел» романнары аны зур осталыкка ия язучы итеп таныталар.

Ф. Хөсни — «Урманда», «Еллар һәм юллар», «Бертуган Таһировлар» драмалары авторы да. Ул язучы хезмәте, каләмдәшләре иҗаты турында да күп яза.

Фатих Хөснигә «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» дигән повесте һәм хикәяләре өчен 1972 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Ә 1993 елда ул Татарстанның халык язучысы дигән мактаулы исемгә лаек булды.

МАЛАЙ БЕЛӘН СОЛДАТ

...Бусы менә Наилләр өе. Аны узып бераз барасы да — күпер. Күперне узып бераз баргач — каланча. Аның башында зур җиз чаң, аннары тагын тире толып кигән Галәви абзый басып тора. Шунда ук тыкрык, тыкрыктан бераз баргач — ындыр. Аннары басу капкасы, аннары тимер юл, аннары калай түбәле кызыл станция. Станциянең аргы ягында — кар басып киткән кыр. Куян белән тулган урман. Урманның аръягында — кайдадыр шунда якында гына — Наилнең этисе... Ә үзе, шул эти, кайтмый да кайтмый. Әнисе әйтә Наилгә, сораган саен әйтә: әнә шул якка, урман артына таба китте безнең этиебез, кайтса, шул яктан ук әйләнеп тә кайтырга тиеш, ди. Элегрәк Наилгә сугыш үзе дә шунда, урман артында гына булгандыр кебек тоела иде, үсә-үсә ул инде белә башлады: юк, сугыш урман артында гына булмаган, сугыш каладан да ары, Теләчедән дә ары, кайдадыр еракта-еракта булган, аны хәзер тагын да ераккарак куганнар, ә Наилнең этисе алай еракта түгел, әнә анда — урман артында гына.

Шулай уйлау рәхәт, шулай уйлау күңелгә тынычлык бирә, әни дә шулай уйлый, кем белә, бәлкем, каланча башындагы Галәви абзый да шулай уйлый торгандыр!

Наил хәзер бала-чага түгел, ул инде укырга өченче класска йөри, өйдә әнисенә булыша, абзар-кура арасында терлек-туар карый, бүтәнен әйтеп тә торасы юк, ул быел, кулына балтапычкы тотып, үзенә чаңгы да ясады. Шулай да этисе турында ул элек ничек уйлаган булса, хәзер дә шулай уйлый: эти урман артында мәңгелеккә калырга тиеш түгел, эти кайчан да булса бер кайтырга тиеш. Сугыш булган да беткән, башка малайларның этиләре инде әллә кайчан кайтканнар, тик менә Наилнең генә этисе кайтмый да кайтмый.

Кышкы каникул вакыты иде. Беркөнне Наил, үзе ясаган чаңгыга басып, япа-ялгыз чыгып китте. Күперне узды, каланча чатына җитте, тыкрыкка борылды, басу капкасы янында аз гына тукталып торды, аны да үтте, басуга чыгып китте. Ә үзе япа-ялгыз, җитмәсә тагын көн кичкә авышып бара, нык кына буранлап та тора иде.

Станция юлында аңа аркасына рюкзак аскан, кулына кечерәк кенә чемодан тоткан җәяүле бер солдат очрады. Икесе дә туктап калдылар.

— Бу — алда күренә торган авыл — Мүкле Күл авылымы? — дип сорады солдат, малайны башыннан аягынача күздән үткәреп.

— Мүкле Күл түгел, безнең авыл,— дип җавап кайтарды Наил, солдатның соравын аңлашып җитмичә. Ул, зурларча хәрәкәт ясап, бүреген артка чөя теште, маңгаен сыпырып куйды. «Менә мин шул авыл егете булам инде!» дигән кебек итеп, солдатка кыю гына бер карап алды. Икесе дә көлемсерәп куйдылар. Малайның болай чекерәеп карап торуы солдатка ничектер сәер тоела иде, шул ук вакытта Наилгә дә кызык: шундый зур солдат абый, кыр уртасында аны туктатып, аннан авылны сорашып тора.

Бераз сүзсез торганнан соң, солдат янә сорап куйды:

— Ә син болай кичләтеп кая барасың?

«Әтине эзләп...» — дип, чак кына ычкындырып ташлама-ды малай, ничектер уңайсыз булып китте аңа. Шунда ук ул чаңгысын авыл ягына борып, солдатка ияреп кайтырга булды.

каланча — тирә-юньне күзәтү өчен тар һәм биек итеп эшләнгән баскычлы корылма
чаң — зур кыңгырау
ындыр — урылган ашлыкны саклау, киптерү, сугу, җилгәрү өчен махсус җайланган урын, корылма
абзар-кура — йорт тирәсендәге каралты
сәер — гадәти булмаган, гаҗәп

Сораулар һәм бирем

1. Наил яши торган авылны ничек күз алдына китерәсез? Тексттан файдаланып, тасвирлап күрсәтегез.
2. Наил әтисен сагына. Сез моны нинди мисаллар белән аңлатырсыз?
3. Наил кая барырга чыга? Аңа юлда кем очрый? Наил аның белән ничек сөйләшә?

* * *

Юлда алар әллә ни сөйләшеп тормыйча, икесе дә бик зур кеше булып, тамак кыргалый-кыргалый гына кайттылар. Шулай да солдат сорашкалады. Янәсе, Наилгә чаңгыны кем ясап биргән? Наил мәктәптә укыймы? Укулары ничек бара? Наил киләчәктә кем булырга уйлый? Җитмәсә тагын, тел ачылгач, Наилнең чаңгысын да яманлап ташлады, чаңгыны, имеш, юкагачтан ясамыйлар. Сөйләшмәделәр дисәк тә, байтак кына сөйләшкәннәр икән алар. Кыскасы, Наилләр авылына кайтып җиткәндә, алар тәмам дуслашып өлгергәннәр иде.

Каланча чатында борылмыйча, солдат үз юлы белән китә башлагач, Наил кинәт аптырап калды:

— Безгә бит бу якка... син безгә кайтмыйсыңмыни? — дип сорап куйды ул, бераз аптырабрак. Аның тавышы бер үк вакытта гаҗәпсену һәм аптырау белән тулган иде. Солдатка ул

шундый бер тилмерү белән карап алды, теге борылмас җиреннән борылды.

— Кайтыйк, алайса...— дип, шаярткандай итеп кенә әйтеп куйды ул авыз эченнән генә. Әмма уйланып калган хәлдә кабатлады: — Караңгы да төшеп килә, буранлап та тора...

...Ул кичне Наил, шатлыгыннан нишләргә белмичә, гел солдат тирәсендә бөтерелде: аның йолдызлы бүреген киеп карады, аның бил каешын салдырып, каешны үзе буып йөрде, солдат аның белән шашка уйнаган булды. Тышта буран котыра, буран тәрәзә пыяласына кар китереп сылый, әллә нидә бер күрше Әхми абзыйларның эте өреп куя, ә өй эче җылы, рәхәт, җиделе лампа яна. Наилнең каршысында зур гәүдәле, таза иңбашлы, салынкы кашлы, гел көлемсерәп торучы сөйкемле абый утыра. Бик күңелле булып китте Наилгә һәм ул, шул рәхәтлектән әкрен генә оеп, мендәргә кәкрәеп төшкәнен үзе дә сизми калды.

Ләкин иртәгесен солдат абый юк иде инде. Наил йокысыннан торганчы, солдат абый җыенып чыгып киткән. Йолдызлы бүрек тә юк, бил каешы да юк, шашка төймәләре кайсы кайда сибелеп яталар, кыскасы, өй эче нәкъ элеккечә бушап, ятимләнеп калган иде. Наил күңелсезләнеп тәрәзәгә килде, күзләре белән солдат абыйны эзләп табарга теләгәндәй, каланча тыкрыгы ягына таба карап торды. Ләкин солдат абый бер җирдә дә күренми иде. Ул да түгел, ишекне зур итеп ачып, әнисе яңа чаңгы күтәреп керде.

— Менә сиңа... солдат абыең ясап калдырды,— диде ул, чаңгыны Наилгә биреп. Шулай диде дә, бүтән бер сүз дә әйтмичә, ашыгып кече якка кереп китте. Күреп калды Наил, әнисенең нишләптер иңбашы дерелдәп куйды, кинәт яулык почмагы белән күзләренә тотынды — әллә елый инде?

Менә моны, ичмасам, чаңгы дияргә дә була — үзе киң, үзе озын, үзенең әле олылар чаңгысы кебек башы да кәкрәеп тора. Ә әни, юләр, елый.

Солдат аның малаена нинди шәп чаңгы ясап калдырган, ә ул елый...

Сораулар

1. Солдатның үзләренә кайтуына Наил бик шатлана. Ни өчен дип уйлыйсыз?
2. Солдат абыйсы Наилгә нинди бүләк калдыра?
3. Наилнең әнисе ни өчен елый?

«Ялкын» журналы турында сөйләшү өчен сораулар

1. «Ялкын» журналы тарихыннан сез нәрсәләр беләсез?

2. «Ялкын» журналы, анда басылган әсәрләр белән даими танышып барасызмы?

3. Татар язучыларының анда басылган нинди әсәрләрен укыганыгыз бар?

4. «Ялкын» журналы битләре аша сез сәнгать осталарыннан кемнәр белән таныштыгыз? Аларга багышланган нинди рәсемнәр, язмалар буенча фикер алыштыгыз?

5. Чит илләрдәге яшьтәшләрегезнең уй-хыяллары, омтылышлары «Ялкын» журналында ничек яктыртыла?

6. «Ялкын»да басылган нинди әкиятләр укыдыгыз?

7. «Ялкын»ның кайсы сәхифәсе сезгә аеруча ошый? Ни өчен?

СӨЙЛӘНМӘГӘН ХИКӘЯ

Бу хәл минем балалык дустым Биктимер башыннан узган бер хәл булганга һәм ул тарихны кешегә сөйләргә Биктимер ризалык бирмәгәнгә, хәзергә чаклы мин моны беркемгә дә сөйләми йөрдем. Дөрес, аны сөйләргә теләп телем кычыткан минутлар аз булмадылар, ләкин ничә әйтсәң дә бер сүз, без Биктимер белән бик дус идек шул. Хәзер инде Биктимер үсте, чабатачы Әхми малае сипкелле Биктимердән хәзер ул инженер Биктимергә әйләнде. Әллә кайчан булып узган бер тарихны кешеләргә сөйләп бирүем өчен ул миңа шәт үпкәләмәстер. Тагын шул чаклысы да бар, Биктимер минем

җилбәзәк булуымны, лыгырдарга яратуымны бик яхшы белә. Шуларны искә алып, ул мине гафу итсен, сөйлим дә бирәм.

...Моннан байтак еллар элек, революциягә чаклы ук, Биктимернең әтисе Әхми абзый, ул вакыттагы алама гадәт буенча, «Чабатачы Әхми» яисә «Төккунмас Әхми» дип йөртелә торган чакта, көннәрнең берсендә, Биктимернең әнисе Маһруй җиңги коймак пешерергә уйлый. Тукта әле, безнең авыз да коймак ашап карасын бер, дип үзеннән-үзе сөйләнеп ала ул һәм, шулай итеп, коймагына баш ясап куя. Коймак бик яхшы булып әчи, кабара, бер сүз белән әйткәндә, «менә авызга керәм... менә керәм» дип чымырдап тора башлый. Шуннан соң ул, әлеге безнең Маһруй җиңги, коймакны пешерү нияте белән мич ягып җибәрә. Мич яккач таба кирәк, коймакны бит учта пешереп булмый. Ә аларның исә мич астында күгәреп беткән ярык бер табалары гына бар.

— Ай алла! Тагын кешегә барырга кирәк,— дип, тирән генә көрсенеп куя Маһруй җиңги. Ләкин нәрсә генә булмасын, башлаган эшеннән кире кайтырга һич кенә дә уйламый.

Мич башында кыштыр-кыштыр килеп чабата киндерәсен ялгап маташа торган кечкенә Биктимергә кычкыра:

— Бар, Биктимер, хәзер үк чат Җамалиларга йөгер, әни таба сораган иде, табагызны биреп торыгыз әле, диген.

Яшереп булмый, Биктимернең сүз тыңлый торган гадәте кече-кечкенәдән бар иде. Андый шатлыклы көнне, әйтик, коймак пешерелә торган көнне, аның ул гадәте бигрәк тә көчәеп киткән, күрәсең. Анасы әйтү белән Биктимер, чабата киндерәләрен дә бәйләп тормыйча, мич башыннан атылып төшә дә иске бишмәте белән иске бүреген тиз генә эләктереп чыга башлый. Ләкин ул чыгып өлгерми, Маһруй җиңги, аны туктатып, тагы бер кат бик ныклап тукый:

— Аягың тигән җиргә тисен, тимәгән җиргә тимәсен, югыйсә камырым ташый, хәзер үк кайт. Ишеттеңме?

— Ишеттем,— ди Биктимер.

Тагын бер кат «Ишеттеңме?» дип сорый Мәһруй җиңги, тагын бер кат «Ишеттем» дип җавап кайтара Биктимер.

— Ишетсәң шул, бер җирдә дә тукталып торма, йөгереп бар да йөгереп кайт,— дип, өченче кат Биктимернең исенә төшерә анасы. Биктимер тәмам чыгып киткәч, капка төбенә килеп җиткәч, Мәһруй җиңги аны тагын туктата:

— Болай гына булмас син ачык авыздан. Син, Биктимер, барганда да, кайтканда да авыз эчеңнән «Әнинең камыры кабара, әнинең камыры кабара» дип кабатлап бар. Ишеттеңме?

— Ишеттем,— ди Биктимер һәм шул минуттан башлап «Әнинең камыры кабара»ны кабатларга да тотына. Чат Җамалиларга барып җиткәнче кабатлап бара. Чат Җамалиларның ишек төпләрендә дә гел кабатлап тора. Хәер, аңа чат Җамалиларда озак торырга туры килми. Табалары буш булганлыктан, тегеләр зур гына бер табаны Биктимергә тоттырып җибәрәләр. Кайтырга чыга Биктимер. Үзе йөгерә, үзе һаман «Әнинең камыры кабара»ны авыз эченнән кабатлап кайта. Күрәсез, бөтенесе ал да гөл булып, коймак дигәнең авызга үзе шуып керергә тора.

Шулай итеп, безнең Биктимеребез авыз эченнән әлеге дә баягы «...кабара»ны кабатлап, ә куллары белән зур табаны кочаклап кайтып килгәндә, бәхеткәме, бәхетсезлеккәме каршы, аның юлы Чишмә тавына килеп чыга, ә тауда су сибеп катырган көзгедәй шугалак була. Шугалакта бала-чагалар шау-гөр килеп чана шуып уйныйлар. Бу чаналы малайлар Биктимернең иптәшләре булмасалар да, аларның кычкыра-кычкыра чана шуулары Биктимерне кызыктыру өчен җитә кала. «Эх... минем дә чанам булса...» дип, эчке яну белән уйлап куя Биктимер. Ләкин аңа карап Биктимернең чанасы булмый. Ә чанасы булмауга карап, Биктимер шулай ук җиңелергә һич тә уйламый. Балаларча кызыгу белән кызыгып, озаклап карап тора ул. Бу минутта аның зур соры күзләре гаҗәеп ут белән тула. Бу минутта аның кечкенә йөрәге күкрәген бәреп тышка чыгарга теләгәндәй тыпырчына. Ләкин, аның күзләре матур дип, аңа берәү дә үз чанасын китереп тоттырмый. Чаналы малайларга сер бирәсе килмәгән Биктимер, аны-моны уйлап тормастан, кулындагы табасын куя да, шуңа утырып, боз шугалак буенча тау астына шуып төшеп китә. Тел белән сөйләп, каләм белән язып бетерә алмаслык бәхет эчендә күмелеп кала Биктимер. Тагын менә, тагын төшә, тагын менә, тагын төшә. Бөтен нәрсәне, шул җөмләдән ашауны да, шул җөмләдән «Әнинең камыры кабара»ны да онытып, шуып уйный башлый ул. Биктимернең табасы, чаналардан уздырып, үзенә бер тавыш белән зыңгылдап шуа. Бу нәрсә башка малайларның күзләрен яндыра. Малайлар, чаналарын ташлап, Биктимергә кызыгып карап тора башлыйлар. Моны күргәч, Биктимер, шатлыгыннан канатланып, җырлый-җырлый берүзе генә шуарга тотына... А... моны тыныч кына сөйләп тә булмый, моның рәхәте ничек булгандыр дисез сез!

Бер сүз белән әйткәндә, Биктимернең куллары канатларга әйләнәләр. Чабатачы Әхми малае сипкелле Биктимер, әкиятләрдә сөйләнә торган канатлы кешегә әверелеп, иртәдән кичкә чаклы бәхет томаны эчендә очып йөри. Бервакытны, әйтик, канатлары киредән кулга әйләнгәч, әйтик, бәхет томаны бераз тарала төшкәч һәм Биктимер инде оча торган малай түгел, ә иске бүрекле Биктимер булып калгач, ул, айнып, күзләрен ачып җибәрә. Бу вакытта инде, кояш баеп, күктә беренче йолдызлар күренә башлаган була. Биктимер, әнисен күз алдына китереп, «әни... кабара...» дигән сүзләрне өзек-өзек кабатлап куя. Ә бераздан соң инде, бозланып каткан итекләрен шыгырдатып, табасын кочаклаган көйгә, әкрен генә атлап өйгә кайтып керә.

Биктимер ишектә күренү белән, әнкәсе Мәһруй җиңги:

— Сине, эт куучыны, кай җиреңнән кыйный башлыйм икән мин! — дип, сырлы бәләк күтәреп, аның өстенә килә. Тик Мәһруй җиңги өлгерми кала. Биктимернең әтисе Әхми абзый килә дә Мәһруй җиңгинең кулыннан сырлы бәләкне

тартып ала. Ала да үзе Маһруй җиңгинең күзләренә туры итеп бераз карап тора, аннары әйтә:

— Тукта, кечкенә генә малайны нужа да, син дә кыйнасаң, ул аннары кая китә!

Моннан соң ул Биктимерне үзенә табарак тартып китерә дә чишендерә, бүреген чөйгә, бишмәтен мич кырына элеп куя. Боларның барысыннан да соң, шулай ук туры һәм шелтәле итеп, Биктимернең күзләренә карап тора.

— Ә сиңа анаң сүзен тыңларга кирәк, малай актыгы,— дип, авыр гына әйтеп куя соңыннан.

Биктимернең миңа сөйләвенә караганда, башкача ул һичбер вакытта да анасының сүзен аяк астына салып таптамаган.

Ә инде кайбер кешеләрне коймак мәсьәләсе кызыксындыра икән, рәхим итсеннәр, Биктимернең анасы Маһруй җиңги хәзер коймакны әледән-әле пешерә. Маһруй җиңгине яманлар хәлем юк, кунакчыллыгы бар, рәхәтләндереп сыйлап җибәрер үзләрен.

Шулай да, Биктимер дустым, балачагыбызның кызыклы һәм ачы бер истәлеген болай ярлы итеп сөйләвем өчен, син мине ачуланма инде.

җилбәзәк — җиңел холыклы, һәрнәрсәгә дә җиңел, өстән генә карый торган кеше
лыгырдау — белер-белмәс берәр нәрсә турында сөйләү, әйтү
төккунмас — тормышы рәтләнмәгән
көрсенү — нинди дә булса хисне, кайгыны белдереп озын һәм тирән итеп сулыш алу
чабата — чолгау яки оекбаш белән кию өчен юкәдән (кайвакыт каештан) үрелгән аяк киеме
киндерә — юкәдән ишелгән нечкә бау
бишмәт — мамык белән сырып тегелгән кыешкы өс киеме
ачык авыз — җебегән, булдыксыз, игътибарсыз
тыпырчыну — аякларны бер урында тыпырдатып тору
көй — нинди дә булса бер җай, бер уңай, бер тәртип
бәләк — гадәттә бераз кәкрерәк яссы агач тукмак (кер чайкаганда тукмаклау һәм кипкәч йомшарту өчен кулланыла)

Сораулар һәм бирем

1. Инженер Биктимернең балачагына бәйле вакыйга сездә нинди тәэсир калдырды?
2. Бу гаиләнең тормыш хәле, гаилә әгъзалары арасындагы мөнәсәбәтләр хикәядә ничек тасвирлана?
3. Әнисенең үтенечен вакытында үти алмаган Биктимергә карашыгыз нинди?
4. Маһруй җиңги, Әхми абзыйлар кайсы сыйфатлары белән сезгә аеруча ошады?
5. Биктимернең, табага утырып, таудан шуу күренешенең рәсемен ясагыз.

Нәби Дәүли
(1910—1989)

Нәби Дәүли (Нәбиулла Хәсән улы Дәүләтшин) 1910 елның 1 июнендә Татарстанның Әлки районы Мәүләшә (Иске Камка) авылында ярлы крестьян гаиләсендә туган. Нәбиуллага сабый чактан ук тормышның бөтен ачысын татырга туры килә: дүрт яшендә әтисе һәм, озак та тормый, әнисе үлә.

1921 елда унбер яшьлек Нәбиулла, Царицын (хәзерге Волгоград) шәһәренә килеп, балалар йортына эләгә. Шунда җидееллык мәктәпне тәмамлый. Бераздан ул Донбасска китә һәм, Донецк шәһәрендәге металл эшкәртү заводында тимерчелек һөнәренә өйрәнеп, цехта эшли башлый. Шул ук вакытта ФЗӨ мәктәбендә белем ала, әдәбият белән кызыксына, үзе яза башлый. Бу елларда Донбасста татар телендә чыга торган «Пролетар» газетасында шигырьләр, очерклар бастыра. Соңга таба үзе дә шушы газета редакциясенә әдәби хезмәткәр булып эшкә керә һәм армиягә алынганчы шунда эшли.

Н. Дәүли 1935 елда Казанга килә һәм Бөек Ватан сугышы башланганга кадәр «Яшь сталинчы» (хәзерге «Татарстан яшьләре») газетасы редакциясендә әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире булып эшли. Бу елларда Н. Дәүли әдәбиятка ныклап аяк баса, шагыйрь буларак формалаша. 1937—1941 елларда аның дүрт шигырь җыентыгы басылып чыга («Бәхет», «Ал чәчәк», «Уйлар», «Кырык шигырь»). Шагыйрь яшь кешенең

туган илгә һәм тормышка мәхәббәтен, күтәренке рухын һәм иҗади хезмәт шатлыгын гәүдәләндерергә омтыла.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк Н. Дәүли фронтка китә. Ләкин авыр сугышларның берсендә, чолганышта калып, әсирлеккә төшә. 1942 елның яз башында аны, бүтән әсирләр белән бергә, Германиягә озаталар. Әдип төрле лагерьларда газап чигә. 1945 елның апрелендә ул берничә иптәше белән лагерьдан кача һәм үзебезнекеләргә кушыла.

Фронттан кайткач, Казан шәһәренең төрле рәсем остаханәләрендә рәссам-бизәүче вазифасын башкара.

Шагыйрьне тормышыбызның бик күп күренешләре иҗатка рухландырган, күп нәрсәләр борчыган. Ул хезмәт, батырлык, туган ил, яшьлек, мәхәббәт турында җырлый. Нәби Дәүли иҗаты нинди, ул нәрсә турында яза, дигән сорау куйсалар:

— Нәби Дәүли иҗаты — Ватан һәм аңа лаеклы булу турында,— дип әйтергә мөмкин булыр иде.

Бу темалар аның лирик шигырьләрендә, баллада, поэмаларында («Берлинда окоп», «Авыл дәфтәре») һәм проза әсәрләрендә чагылыш таба.

Автобиографик материалга нигезләнеп язылган, әсирләрнең авыр сынауларда да Ватанга тугрылыклы, көчле рухлы булып калулары турындагы «Яшәү белән үлем арасында» һәм «Җимерелгән бастион» әсәрләре укучылар арасында аеруча танылыла.

Алар рус, кыргыз телләрендә дә дөнья күрделәр.

Татар дәүләт Курчак театрында аның «Җырлап узган җәй» пьесасы нигезендә куелган спектакль зур уңыш казанды.

БӘХЕТ КАЙДА БУЛА?

Кояшлы яз көнендә	Бәхет ул кайда була?
Яшел каен төбендә	Шул турыда син уйла.
Сөйләшәләр ике дус —	Кояш чыккан яктамы?
Галимҗан белән Илдус.	Кояш баткан яктамы?

Шунда, ял итим диеп,
Туктаган бер карт килеп.

Ике дусны күргән ул,
Менә нәрсә дигән ул:
Бакчада бар агачлар,
Чиязләр, алмагачлар.
Сайрыйлар кошлар таңда,
Тирбәлеп яшел талда,
Сайрыйлар кошлар әйтеп,
Бар диеп монда бәхет.
Әйдәгез, барып карыйк,
Бәхетне казып алыйк.
Риза булды ике дус —
Галимҗан белән Илдус.
Көрәк, тырма алдылар,
Шул бакчага бардылар.
Казыдылар бик озак,
Күрәсең, бәхет ерак.

Җир өсте калды йомшап,
Алмагач моңа бик шат.
Алмагач башын игән,
Нигә соң болай икән?

Чөнки авыр алмалар,
Баллы чыклар тамалар.
Чөнки инде көз булган,
Алмалар пешеп тулган.
Аллы-гөлле төсләре,
Нинди тәмле исләре!

Шунда күрде ике дус —
Галимҗан белән Илдус —
Чал бабай уңыш җыя,
Алмадан таулар өя.
Ак сакалын сыйпый ул,
Ике дусны сыйлый ул:
— Ашагыз,— ди,— балалар,
Без үстергән алмалар.
Эзләп йөрмә бәхетне
Җиде ят ерак илдә.
Ул яши безнең өйдә,
Без торган азат җирдә.
Шунда белде ике дус —
Галимҗан белән Илдус,
Бабай бик дөрес әйтә:
Бәхет була хезмәттә.

таңда — иртән
тирбәлү — чайкалу
чык — су тамчысы (роса)
чал — ак чәчле

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз һәм түбәндәге сораулар буенча эчтәлеген сөйләгез.
   Галимҗан белән Илдус нәрсә турында сөйләшәләр?
   Ял итәргә туктаган бабай, бу сөйләшүне ишетеп, аларга нинди киңәш биргән?

   Малайлар бабайның киңәшен ничек үтиләр?
   Көз көне Галимҗан белән Илдус бакчада кемне күрәләр? Ул нишли?
2. Бабай бәхет турында нәрсә ди? Шул сүзләрне текстан табып укып күрсәтегез.
3. Бәхетне сез ничек аңлыйсыз? Үзегезнең иң бәхетле көнегез турында сөйләгез.
4. *Кояш чыккан як, кояш баткан як, җиде ят* сүзтезмәләренең мәгънәләрен ачыклагыз.

Бәхет һәм хезмәт турында мәкальләр

- Бәхет — пыяла: сакламасаң уала.
- Бәхет теләктә түгел, беләктә һәм йөрәктә.
- Бәхет тәрәзәдән карый, кайгы ишектән керә.
- Бәхет үзе килми, ияреп тә йөрми — аны эзләп табалар.
- Бәхет җирдән чыкмас, тирдән чыгар.

- Ирнең асылы эштә танылыр.
- Бүренең көче — тешендә, кешенең көче — эшендә.
- Эше барның көче бар.
- Эшләп ашасаң, ипиеңнән дә күмәч тәме килә.
- Эш батыры — ил батыры.
- Тырышкан табар, ташка кадак кагар.
- Һөнәре бар үргә йөзәр.

«Кешене хезмәт бизи» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Халыкта «Кешене хезмәт бизи» дигән әйтем йөри. Сез аны ничек аңлыйсыз?

2. Акыл хезмәте һәм физик хезмәт бер-берсеннән ничек аерыла? Мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз.

3. Сезгә нинди һөнәрләр аеруча ошый? Ни өчен?

4. Сезнең әти-әниегез, туганнарыгыз кайда, кем булып эшлиләр?

5. Сез киләчәктә кем булырга телисез?

КАР НИНДИ ҖЫЛЫ...

Җәй узды. Уку елы башланды.

Илгиз белән Гариф мәктәп капкасы янында очраштылар да, бер-берсен бик озак күрмәгән ирләр кебек, кочаклашып күрештеләр. Бу ике дус мәктәптә әле өченче ел гына укыйлар иде.

Гариф, җәй буе авылда торып, тазарып киткән, тагы да үскән шикеллерәк.

Ә менә Илгизгә нәрсә булды икән? Ул бит туп кебек түмтүгәрәк иде. Нигә ул болай ябыккан? Йөзеннән елмаюы да сыпырылган. Дәрес вакытында Илгизне күреп укытучының исе китте, йөрәге сызлап куйды. «Нәрсә булды икән бу аю баласына?» — дип уйланды ул.

Дәрестән соң укытучы Илгизне үз янына чакырып алды. Баштанаяк күзәтеп чыкты. Ә Илгиз, кеше күзенә бер дә курыкмыйча карый торган Илгиз, бу юлы башын иеп, күзләрен озын керфекләре арасына яшереп куйды. Ул нәрсәдәндер ояла иде.

— Йә, йә, кара әле миңа,— диде укытучы, Илгизнең башыннан сыйпап.—Нәрсә булды сиңа? Нигә болай ябыктың, әллә авырыйсыңмы?

— Юк, апа, авырмыйм,— диде Илгиз.

— Әллә өегездә берәр кайгы бармы?

Илгиз эндәшмәде. Башын күтәреп укытучы апасына карады. Аның керфек очларына вак-вак кына энҗе бөртекләре тезелгән иде.

Укытучы баланы артык борчырга теләмәде. Ләкин аның тәҗрибәле күзләре бала йөзендә сагыш моңын ачык күрделәр. Кайгы бит ул шундый, кеше йөзенә бертөрлерәк тамга сала. Яшьме, картмы дип тормый — моңландыра, саргайта. Илгизнең дә кайгысы бар иде. Тик ул әле аны «кайгы» дип әйтә генә белми торгандыр.

Өйгә кайтып барышлый Гариф дусыннан сорады:

— Укытучы апа сине нигә чакырды? — диде.

Илгиз бераз сүзсез барды. Аннан соң бик уңайсызланып кына:

— Кайгы нинди була? — дип, үзе дә Гарифка сорау бирде.

— Кайгы? — дип гаҗәпләнде Гариф.

— Әйе.

Чыннан да, кайгы нинди була икән? Аның төсе бармы, исе бармы? Әллә ул күзгә күренмни торган нәрсәме? Менә кызык сорау. Гариф бераз уйга калып барды. Башка вакытта ул, аны-моны уйлап тормастан, җәт кенә җавап биреп ташлый торган иде. Ә бу юлы ул сорауга тиз генә җавап таба алмады.

— Укытучы апа сорады, өегездә берәр кайгы бармы әллә, диде. Ә мин нәрсә әйтергә дә белмәдем,— дип, тагын сүзгә кереште Илгиз.

— Кайгы,— диде Гариф,— беләсеңме, малай, нәрсә ул?

— Нәрсә?..

Гариф тагын тынып калды. Бераз баргач кинәт кенә:

— Белдем, малай, белдем,— дип кычкырып җибәрде.

— Йә, әйт, нәрсә?

Гариф ни өчендер башта колак артын кашып алды. Бүреген күтәреп куйды. Аннан соң сөйләп китте:

— Кайгы ул, малай, беләсеңме нәрсә? Кайгы ул — әти үлгәч була. Минем әти үлгәч, әни, безнең зур кайгыбыз бар, диде. Хәзер син дә, мин дә ятим калдык, диде. Кайгы менә шул инде...

Илгиз дусының каршына чыгып туктады да:

— Әти үлгәч бик авыр буламы? — диде.

— Әни бик авыр дип әйтә, миңа да күңелсез...

Кинәт кенә Гарифның йөзенә дә моң сугылды. Шул минутта урамда баручы кешеләр арасында аның үз әтисе дә узып киткән кебек тоелды. Их, Гарифны әтисе ничек ярата иде! Алар ял көннәрендә бакчаларга чыгып йөриләр, шаярлар, куышып уйныйлар иде. Җәй көннәрендә Аккош күленә, урманнарга, йә Идел буена балык тотарга китәләр иде.

Ә хәзер Гариф ятим бала. Аның әтисе сугыштан яраланып кайтты. Ул һаман, иңбашым авырта, дип зарлана торган

булды. Ә бервакытны ул бөтенләй авырып китте. Аны больницага салдылар. Үпкәсенә кереп калган кечкенә генә тимер ярчыкны операция ясап алырга кирәк иде. Аны йоклаттылар. Һәм ул шул йокыдан кабат уянмады. Йөрәге чыдамагандыр инде...

Бу моннан өч ел элек булган иде. Ләкин әти юклыгы һаман сизелә. Өйдә нindидер бушлык бар сыман. Ничек кенә мичкә яксаң да — өй һаман салкын кебек, нинди генә бәйрәм булмасын — өйдә күңелсез...

Ике дус икесе дә уйга калып бардылар.

— Безнең өйдә дә кайгы бар,— диде Илгиз.

— Нинди кайгы? Синең әтиең исән ич...

— Минем әти китә.

— Китә?

— Китә.

— Кая китә?

— Белмим,— диде Илгиз,— миңа бик күңелсез булыр инде...

— Нигә аны әниең җибәрә соң? — диде Гариф.— Син аңа әйт, әтием, китмә, дип әйт, җыла, муенына асылын, мин сине беркая да җибәрмим, син минем әтием, диген...

— Әти белән әни һәркөнне талашалар. Әни җылый, мин бүлмәгә керсәм, әти, бар әле моннан чыгып тор дип, мине куа. Аннан соң мин дә җылыйм. Әти, мин китәм, китәм дип, әнигә җикеренә.

— Ни өчен икән?..

— Белмим...

Алар урам чатына килеп җиттеләр. Инде ике дуска менә шул чатта аерылышырга кирәк иде.

— Әйдә безгә,— диде Гариф Илгизгә.— Бүген безгә кунак киләсе, әни мәмиләр пешерә калды. Дәресләрне дә бергәләп әзерләрбез. Күршеләргә телевизор карарга керербез, әйдәме?

Илгиз икеләнде. Аның өйгә дә кайтасы килә. Ә өйдә күңелсез. Һаман тавыш, һаман ызгыш. Аның инде күптән вакытында ашаганы юк. Төнлә йоклаганда да күрше бүлмәдә әтисе кычкырганга куркынып уянып китә. Урамда гына түгел, аларның үз өйләрендә дә салкын кыш иде кебек.

Илгиз, инде нишләргә, өйгә кайтыргамы, әллә аларга барыргамы, дип уйланып торганда, Гариф аны кулыннан тотып тартты:

— Йә, киттек инде,— диде,— курыкма, минем әнием бик-бик яхшы...

Илгиз теләр-теләмәс кенә дусы артыннан атлады. Аның әле Гарифларда бервакытта да булганы юк. Гариф та Илгизләрнең йортын белми иде. Башта алар бер-берсенә кунакка йөрергә әле бик кечкенәләр иде. Берсе җәй көне авылга китә, берсе пионер лагеренда ял итә торган иде. Быел Илгиз дусын үзе беренче булып кунакка чакырырга җыенган иде. Ә ул әнә ничек булып чыкты.

Алар килеп җиттеләр, өйгә керделәр. Гарифның әнисе өстәлгә табын әзерләп йөри иде, кулларына тәлинкәләр тоткан килеш каршылады.

— Кайттыгызмы, улым, менә шәп, менә шәп,— дип, балаларга карап елмайды. Ул бүген өстенә чәчәкле ефәк күлмәген кигән, чәчен бөдрәләтеп җибәргән, шуңа күрә тагын да яшьрәк, тагын да матуррак булып киткән кебек.

Гариф әнисенә карап сокланды. Әтисе исән чагында гына, бәйрәм көннәрендә генә ул шулай киенә торган иде. Ә бүген бит бәйрәм дә түгел. Ә өстәлдә, өстәлдә нәрсә генә юк. Гариф иң элек көмеш муенлы бик зур шешәне күреп алды. Тәлинкәләр төрле-төрле ашамлыклар белән тулган иде. Шунда ук зәңгәр вазага чәчәкләр дә куелган.

Илгиз әле ишек төбендә басып тора иде. Гарифның әнкәсе аны күрде дә:

— Әйдүк, улым, әйдүк, тартынма,— дип, Илгизне түргә чакырды.— Исемең ничек соң?

— Илгиз,— диде малай.

— Ул минем классташым, әни,— дип, Гариф, дусы янына килеп, аңа пальтосын салырга булышты.

— Дустыңны бигрәк кадерлисең инде,— дип, Гарифның әнкәсе йөзен балкытып көлде.

Ике дус өстәл янына килде. Гарифның әнкәсе аларны кара-каршы утыртып, алларына кабарып пешкән өчпочмаклар куйды, үзе дә алар янына утырып калды. Балалар ашый башладылар. Әни кеше аларга карап ниндидер бер җылы ләззәткә бирелде... Ул бер үз улына, бер Илгизгә карады. Алар икесе дә бертуганнар кебек иде.

— Кара әле, улым,— диде ул Илгизгә,— әллә бик тырышып укыйсыңмы, әллә авырыйсыңмы? Бигрәк ябыккансың ич...

Илгиз өчен Гариф җавап бирде:

— Аларның өйләрендә кайгы бар, әни! — диде.

— Кайгы? Нинди кайгы?

Бала авызыннан әйтелгән бу сүзләр гадәттәге «кайгы» дигән сүздән дә кайгылырак булып ишетелде.

сыпырылу — югалу
җәт—җәһәт, тиз генә
ярчык — нәрсәдән дә булса ватылып, кыйпылып төшкән кисәк
ләззәт — рәхәтлек
тамга — шартлы билге
моң — кайгы, хәсрәт, борчу

Сораулар һәм бирем

1. Илгиз белән Гарифның үзара мөнәсәбәтләре турында сөйләгез.
2. Гарифның Илгизгә игътибарлы, ярдәмчеллеген нинди мисалларда күрәсез?
3. Сугыш яраларыннан вафат булган әтисен Гариф ничек искә ала?

— Нинди кайгы соң ул? Миңа да белергә мөмкиндер бит, балакайларым?

— Аның әтисе китә! — диде Гариф.

— Кая китә?

Гариф Илгизгә карады. Бу сорауга җавапны инде ул бирергә тиеш иде.

— Белмим, апа,— диде Илгиз.

Көтелмәгәндә генә башланып киткән шушы сүз ана йөрәген дер селкетеп куйды. Ана баланы шулкадәр сыздырган кайгының серен белергә теләде.

— Әниең нәрсә әйтә соң? — диде ул Илгизгә.

— Әни җылый...

Анага шул сүз җитә калды. Барысы да, барысы да аңлашылды. Ул Илгизне кызганып башыннан сыйпады. Ләкин нәрсә әйтергә дә белмәде. Ана кешегә бик авыр булып калды. Хатын-кыз буларак, мондый кайгының нәрсә икәнен белә иде ул. Ят ана Илгизнең күмердәй кара күзләренә текәлде. Ә ул төпсез тирән күзләрдә йөзеп китсәң — йөзеп китәрлек, очып китсәң — очып китәрлек бер зур дөнья бар иде шикелле. Ул күзләрдә кара төндә җемелдәгән йолдызлар да, таң алдында чәчәкләргә кунып калган чык тамчылары да ялтырый сыман, аларда кояшның бер чаткысы да янып тора кебек. Кеше шул күзләргә карап үзенең җирдә яшәвенә мең-мең кабат шатлана түгелме? Әйе, бала күзләре шундый алар. Ә кемдер менә шул күзләрне яратмаган. Дөньяда тик аңа гына бирелгән бәхеттән баш тарткан. Кем икән ул?

— Синең әтиеңнең исеме ничек соң?

— Саматов Харис.

Гарифның әнкәсе кинәт сискәнеп куйды. Аның йөрәгенең кайсыдыр җиренә энә белән чәнечтеләр кебек. Тәне чемердәп салкынайган төсле булды. Ул ни өчендер бүлмә буйлап күзләрен йөртеп чыкты. Әле хәзер генә ялтырап, балкып торган бүлмә кинәт кенә караңгыланып калды.

Аның үз улы әтисез калды. Ана ятим баласының күңелен табар өчен күпме кыенлыклар кичермәде, күпме борчылулар уздырмады. Йокысыз төннәр, сагышлы көннәр аның күз яшьләрен аз агыздылармы? Ләкин бала тук булды, өс-башы бөтен булды. Әмма ятимлек хәсрәтен бала күңеленнән берничек тә алып ташлый алмады. Бала һәр көнне, һәр кичне әтисен сагынды. Ә менә Илгиз нишләр? Ул да бит ятим каласы бала икән. Әтисе була торып! Бу бит тагы да ачырак кайгы...

Моннан бер ел элек Газизә, пароходта ялдан кайтканда, Саматов Харис дигән бер яшь ир белән очрашкан иде. Харис ул чакта командировкадан кайтып килә иде. Пароход озак барды. Танышырга да, сөйләшергә дә вакыт җитәрлек булды.

Газизә тормышының яңа нигезен корырга, башкалар кебек үк күзле-башлы хатын булырга өметләнде. Улы Гарифны ата култыгына кертмәкче иде бит. Аның моңа хакы юкмыни? Ләкин бер сәгать вакыт эчендә барысы да җимерелеп төште. Тукта, барысы да җимерелдеме? Бәлки, киресенчә, җимерелергә тиеш тормышның җимерелми калуыдыр бу... Әгәр Газизә үзе Илгизнең әнкәсе урынында булса, нишләр иде икән? Әгәр Гарифны әтисе ташлап китсә — нишләр иде мескен ана?

...Инде төн иде. Тышта йомшак кына кар ява. Тынып калган урам буйлап ике кеше атлый: берсе дәү, берсе нәни генә. Илгиз белән аның әтисе үз өйләренә кайтып баралар иде.

Илгиз әтисе янында туп шикелле тәгәри. Бер алга йөгереп чыга, бер юри артта кала да йөгереп җитеп әтисенең чабуына ябыша, шаркылдап көлә-көлә учларына ап-ак карны ала.

— Әти, кар нинди җылы,— дип сөйләнә.

Юк, кар салкын иде. Ләкин баланың кечкенә генә йөрәгендә зур шатлык җылысы бар иде бу кышкы кичтә.

1968

Сораулар

1. Илгизнең кайгысы дустының әнисенә ничек тәэсир итә?
2. Сез Татарстан радиосыннан әти-әниләрегез белән бергә татарча «Пар канатлар» тапшыруын тыңлыйсызмы? Мәскәүдән «Жди меня» тапшыруын карыйсызмы? Бу тапшырулар сезгә ошыймы? Сез алардан нинди гыйбрәтләр аласыз?

Нури Арсланов
(1912—1991)

Нури Газиз улы Арсланов 1912 елның 19 сентябрендә Казахстанның Петропавел (Кызылъяр) шәһәрендә эшче гаиләсендә туа. 1928 елда Күкчәтау шәһәрендә җидееллык татар мәктәбен тәмамлый. 1928—1931 елларда Казан сәнгать техникумының рәсем бүлегендә укый. Техникумны тәмамлагач, Кукмарада, аннан соң Урта Азиядә рәсем-сызым укытучысы һәм Ерак Көнчыгыш шәһәрләрендә рәссам-бизәүче булып эшли. Әмма булачак шагыйрьне Казан тарта. Ул, Казанга кайтып, «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») һәм «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газеталары редакциясендә рәссам хезмәтен башкара. 1934—1936 елларда армиядә хезмәт итә. 1941 елның август аеннан 1946 елның июленә кадәр — яңадан армия сафларында. Бөек Ватан сугышыннан соң Н. Арсланов «Совет Татарстаны» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасы редакциясендә — рәссам, 1964—1972 елларда «Казан утлары» журналында поэзия бүлеге мөдире булып эшли. 1972 елдан тулаем язучылык хезмәтенә күчә.

Нури Арсланов әдәбиятка сугыш чорында «Мәхәббәт» һәм «Рус кызы» исемле поэмалары белән килеп керә. Сугыш тәэсирләреннән туган һәм сугышчыларның патриотик хисләрен, фронттагы батырлыкларын данлаган бу поэмалар үз вакытында әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан җылы кабул ителә.

Бу чорда шагыйрьнең иҗади осталыгы үсә, камилләшә бара. Илленче елларда иҗат ителгән «Ай Хян белән Ли», «Корея геле», «Давыл кызы», «Яшьлек чишмәсе», «Көзге», «Тапкыр игенче» кебек төрле халыкларның авыз иҗаты әсәрләренә нигезләнеп язылган поэма-легендалар һәм поэма-әкиятләре, «Девон фонтаннары», «Якты юл», «Язгы яңгыр алдыннан» исемле шигырь җыентыклары, балалар өчен язылган «Ауда», «Сыерчык», «Карамаймалай әкияте» исемле китаплар укучыларын тиз тапты.

Н. Арслановның күп кенә шигырьләре композиторлар тарафыннан көйгә салынган. «Республикам минем» (Н. Җиһанов), «Казан кызы», «Баулылар», «Нәсимә» (З. Хәбибуллин), «Үрдәкләрем-дүдәкләрем» (И. Хисамов), «Гәрәбә» (Р. Гобәйдуллин), «Уники батыр турында баллада» (Р. Яхин), «Зоя» (Җ. Фәйзи), «Көймәдә» (М. Имашев), «Бәбиләр» (А. Монасыйпов) кебек җырларны халык яратып кабул итте.

Н. Арсланов тәрҗемә өлкәсендә дә күп эшли. Пушкин, Лермонтов, Байрон, Гёте, Шелли, Беранже, Хәйям, Хафиз, Абай, Гамзатов һ. б. бик күпләрнең поэтик әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Иделемилем» (1982) исемле шигырьләр һәм поэмалар китабы өчен Нури Арсланов 1985 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

КАЗАН

И Казан, дәртле Казан,
моңлы Казан, нурлы Казан!

Г. Тукай

Дәртле Казан,
Таныш урамнарның
Ташларына басып йөргәндә,
Хыялларым сәяхәткә китә
Еракларга, узган көннәргә.

Гүя менә нәкъ мин баскан җирдә,
Ат уйнатып шушы ярларда,
Минем бабам басып торгандыр күк,
Өмет баглап килер таңнарга.
Бишбалтаның куе урманнары,
Кабан буендагы камышлар,
Аулардагы ирлек-егетлекләр,
Сабантуйлар, көрәш, ярышлар...
Борынгының зәңгәр томанында
Берәм-берәм үтә уемнан;
Хәзер менә Казан басып тора
Иксез-чиксез диңгез буенда...
Кайда гына бармыйм, кайда йөрмим —
Мин Казанны өзелеп сагынам;
Үзем китсәм, йөрәгем кала кебек
Аерылалмый Идел ярыннан.
Шуннан киттем ике сугышка да,
Тормыш юлын шуннан башладым;
Шуңаргадыр, монда тумасам да,
Казан җире, Казан ташлары —
Туган йортым бусагасы миңа,
Идел ярын туган яр итәм;
Казан, Казан! Сине миннән артык
Яратучы, белмим, бар микән?!

1958

өмет баглау — өметләнү, ышану
аулар — җәнлек, кош аулау

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз.
2. Шагыйрьнең Казанга мәхәббәте кайсы юлларда аеруча нык чагыла? Укып күрсәтегез.
3. Казан шәһәре тарихыннан сез нәрсәләр беләсез? *Бишбалта* һәм *Кабан* атамаларының мәгънәсен аңлатыгыз.

12 к 4/109

4. *Казан җире, Казан ташлары —*
Туган йортым бусагасы миңа дигән юлларга игътибар итегез. Шагыйрь, Казанда тумаса да, ни өчен болай язган дип уйлыйсыз?
5. Казанда нинди югары уку йортлары, музей, театрлар бар?
6. «Казан — Татарстан Республикасының башкаласы» дигән темага сочинение языгыз.

«Безнең якның тарихы» дигән темага сөйләшү өчен сораулар

1. Безнең борынгы бабаларыбыз кемнәр, алар кайларда яшәгәннәр?

2. Борынгы Болгар дәүләте турында сез нәрсәләр беләсез?

3. Болгар дәүләтенең нинди шәһәрләре булган? Алар турында нәрсәләр сөйли аласыз?

4. Борынгы бабаларыбыздан калган нинди гореф-гадәтләр һәм бәйрәмнәрне беләсез?

5. Казан ханлыгы турында сезнең нәрсәләр ишеткәнегез, укыганыгыз бар?

6. Сөембикә кем булган? Татар халкы аны ни өчен тирән хөрмәт белән искә ала?

7. Сез яши торган төбәктә борынгы бабаларыбыз тарихы турында сөйләүче нинди истәлекле урыннар, һәйкәлләр бар?

ГАСЫРЛАР ТИРӘНЛЕГЕННӘН

Нәрсә ул тарих? Ул туган илебезнең, халкыбызның борынгы һәм күптән түгел узган тормышын өйрәнә. Борынгы бабаларыбыз без яшәгән Идел һәм Кама буйларын әлек-әлектән үз итеп, яратып гомер кичергәннәр. Меңнәрчә еллар узган. Бер буын кешеләре икенчесен алыштырган. Һәр буын үзеннән соң, шәһәрләр, авыллар төзеп, зур эшләр эшләп калдырган. Аларның эшләрен яңа буыннар дәвам иткән. Әмма тарих алай гына бармаган. Коточкыч сугышлар, авыл-шәһәрләрнең көл-күмергә әйләнүен, күпләгән кешеләрнең корбан булуын да тарих белә.

Бу яктан аеруча безнең халкыбыз тарихы гыйбрәтле. Борынгы бабаларыбыз әлек-әлектән дәүләткә, шәһәрләргә, дингә-иманга, рухи мәдәнияткә ия булган. Дошман аларның дәүләтләрен, шәһәр-авылларын, халкын кырган. Әмма халкыбызның таланты, тырышлыгы белән дәүләт, шәһәрләр яңадан калыккан. Тормыш тагын алга киткән. Гасырлар узган. Тагын ил өстенә афәт килгән. Әлеккесеннән дә явызрак, мәкерлерәк дошман борынгы илебезне яулап алган. Шулай да халкыбыз бетмәгән. Иле-көне бетсә дә, халык булып калган.

Тарихны өйрәнмичә, үткәнне белмичә, хәзерге тормышны аңлап, яңаны төзеп булмый. Чөнки бүгенге тормыш — меңнәрчә елларның җимеше, нәтиҗәсе ул. Тарих — хәтер ул. Ул азатлык өчен көрәштә башларын җуйган фидаи җаннарны онытмаска өйрәтә. Тарихыбызда булган ялгышларны кабатламаска, бердәм булырга сабак бирә. Сатлык җаннарга карата нәфрәт уята. Тарихын оныткан халык юкка чыга. Кешеләр манкортка әйләнә. Кем соң алар манкортлар?

Кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның бер әсәрендә шундый гыйбрәтле хикәят сөйләнә. ...Борын-борын заманда чүлле, далалы эссе якларда бер урыннан икенче урынга күчеп йөреп мал асрау белән көн күрүче күчмә кабиләләр яшәгән. Алар арасында башка кабиләләрнең малларын, көтүлекләрен тартып алучы, кешеләрен кол итеп алып китүче кабилә дә булган. Колларына төшкән әсирләргә алар ифрат дәрәҗәдә рәхимсез булганнар. Әсирләрне коточкыч язмыш көткән. Колларның башына, чәчләрен кыркып, яңа суйган дөя тиресен кидереп куйганнар. Эссе кояш астында куырылып, тарайганнан-тарая барган тире әсирнең чәчсез башын тимер кыршау сыман кыса, тарттыра барган. Коллар, авыртуга түзә алмыйча, җан ачысы белән кычкырганнар. Тавышлары ишетелмәсен өчен, аларны ерак чүлгә, эссе кояш астына илтеп баганаларга бәйләп куйганнар. Тире башлык тагын да куырылып катып башка батып кергән, башны изгән. Бу коточкыч авыр җәзалаудан әсирләр үзләренең тарихларын, телләрен,

хәтта исемнәрен дә онытканнар, хәтерләрен җуйганнар. Алар ата-аналарын, әби-бабаларын, ыруларын, туган илләрен онытканнар. Алар белән теләсә нәрсә эшләп булган. Манкорт мәхлук телсез хайваннан әллә ни аерылмаган. Ашау турында гына уйлаган. Эт кебек, үзенең хуҗасын гына таныган, ни кушса, шуны гына эшләгән.

Борынгы заманнарда яшәгән кешеләрнең тормышын без ничек белә алабыз соң? Кызганычка каршы, тарихи китапларның бик азы гына безгә кадәр килеп җиткән. Алар дәһшәтле елларда утта яндырылган. Дошман шулай итеп тулы бер халыкның хәтерен җуйдырырга тырышкан. Әмма халык тарихы эзсез югалмаган. Һәр ел саен, сулар агып, җирләр кипкәч үк, археологлар борынгы шәһәр урыннарына ашыгалар. Алар өчен җир — бик зур калын китап. Китап битләрен ачкандай, археологлар борынгы шәһәр хәрабәләрен табалар, андагы табылдыкларга карап, шул заман кешеләре хакында фикер йөртәләр. Җәйге каникул вакытларында аларга мәктәп балалары да ярдәмгә килә.

Халкыбызның авыз иҗатында да, аеруча риваять, бәет һәм тарихи җырларда, булып узган вакыйгалар тасвирланган. Халык бу әсәрләрне еллар буе телдән телгә сөйләп, үзеннән дә өстәп, буыннан буынга тапшырган.

Кадерле дуслар, мөгаен, сез яшәгән йортта, күршегездә сугыш һәм хезмәт ветераннары яшидер. Алар дәһшәтле сугыш һәм авыр хезмәт ачысын-авырлыгын да, җиңү шатлыгын да үз язмышларында татыганнар. Аларны үзегезнең тарих түгәрәкләренә чакырыгыз. Алар сөйләгәннәрне төгәл итеп язып калырга тырышыгыз. Язмаларыгызны музейларга тапшырыгыз.

Элек халкыбызда шундый бер әйбәт гадәт булган. Яшьтән үк һәр бала үз нәсел-ыруының кимендә соңгы җиде буынын белергә тиеш булган. Җиде бабаның исеме догаларда искә алынган. Бабаларыбызда нәсел шәҗәрәләре телдә генә түгел, язма рәвештә дә гамәлдә булган. Бармагыгызны бөгә-бөгә, нәсел-бабаларыгызны барлап карагыз әле, ничә буынга

җиттегез? 2—3 тән узмадыгыз, шулай бит? Әмма үзегезне нәсел-нәсәбен белмәгән бер надан итеп хис итәргә ашыкмагыз: әти-әниләрегездән, әби-бабаларыгыздан сораштырыгыз. Гаилә альбомына куйсагыз, шәҗәрә сезнең балаларыгызга да кучәр. Сыйныфыгызда, мәктәбегездә ярыш оештырыгыз: кем күбрәк буын бабаларын һәм аларның тормышын белә икән? Әйдәгез, халкыбыз, илебез тарихын өйрәнүне шуннан башлыйк әле. Борынгы тарихка сәяхәттә хәерле юл сезгә!

Гамирҗан Дәүләтшин

дин-иман — диннең төп нигезләренә ышану
афәт — бәла-каза, зур бәхетсезлек
фидаи — фидакарь
куырылу — кибеп тартылу
кыршау — бөҗра
мәхлук — җан иясе, *монда:* кимсетебрәк әйтү
хәрабә — җимерек корылма
риваять — буыннан буынга сөйләнеп килгән хикәя, тарих
нәсел-ыру — бер ата-бабадан таралган токым
шәҗәрә — нәсел-ыруны күрсәткән схема, нәсел агачы

НИНДИ УЛ ТАТАРСТАН?

Әгәр дә Татарстан буйлап сәяхәткә чыгарга уйласагыз, алдан ук әйтеп куярга мөмкин: вакытыгыз бик күңелле үтәчәк.

Татарстанның теләсә кайсы ягында карасаң күреп туймастай, йөрсәң йөреп арымастай урыннар аз түгел. Аның табигате бик төрле-төрле. Бездә калын урманнар да, тигез далалар да бар. Урманнарында учар мөгезле пошилар, бурсыклар, дала сыман кырларында төлкеләр, борындыклар, бүреләр дә очрата аласың. Безнең республиканы зур елгалар да бик ямьләндерә. Әмма кечкенә инешләр дә, тау асларыннан чылтырап аккан салкын чишмәләр дә үз урыннарында бик матур.

Безнең якларның климаты да бик ягымлы һәм уртача гына. Кышлары чамасыз салкын түгел, җәйләрен хәтта чиллә вакытында да түзмәслек эссе булмый. Габдулла Тукай үзенең туып үскән Казан арты, Кырлай яклары турында бик яратып, үз итеп әнә нинди җылы сүзләр язып калдырган:

Анда бик салкын вә эссе түгел, урта һава:
Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява.

Кайбер үзгәрешләр өстәгәндә, шушы сүзләр гомумән бөтен Татарстан иленә дә туры килер иде.

Шулай да һәр якның, һәр шәһәрнең, хәтта һәр авылның үз күрке, үз яме бар. Әтнә, Арча, Балтач, Саба яклары үзенең тын гына аккан кечкенә инешләре, тәбәнәк кенә калкулыклары белән, анда-санда яшелләнеп утырган дымсу урманнары, яшел болыннары, салкын чишмәләре белән матур... Шуларның барысы өстенә бу як халыклары Тукайның якташы булулары белән дә горурланалар.

Инде кара туфраклы далага тартым тигез кырлар күрәсегез, Оренбург ягыннан искән коры дала һавасын сулыйсыгыз килә икән,— Каманың аргы ягы нәкъ әнә шундый. Республиканың игенне иң күп үстерә торган кара туфраклы иркен басулары, киң болыннары әнә шунда инде. Ул якның Алабуга тирәсендәге матур нарат урманнары, Ык, Зәй, Чирмешән шикелле зур елгалары, иксез-чиксез җир асты байлыклары: кара алтын, күмер, газ, тагын әллә ниләр бар. Чистай, Бөгелмә, Чаллы, Минзәлә шикелле шактый ук күптән яши торган шәһәрләр дә шул якта.

Әйе, һәр як үзенчә матур, үзенчә күркәм. Әмма кайсы як кына булмасын, ул, барыннан да элек, шул матурлыкны, байлыкны бар итүче хезмәт кешеләре белән, үзенең ягын чын күңелдән яратучан тыйнак холыклы, киң күңелле юмарт халкы белән матур...

Бездәге агым сулар арасында иң зурлары һәм мәшһүрләре — дүртәү. Татарстан җиреннән әлеге чал Идел белән аның бертуган сеңлесе — мул сулы Кама (борынгы исеме — Чулман), көләч ак йөзле Агыйдел һәм, кырысрак чырайлы булса да, үз матурлыгы белән күңелгә якын Вятка (Нократ) елгалары агып уза... Бик күп халыкларны үз тирәсенә җыйган бөек Идел татар халкының тормышына да тирән эзләр салган... Ул халыкларга эш биргән, икмәк биргән, барыр юлларын кыскарткан. Алай гына да түгел, чал Идел зур вакыйгалардан читтә калмаган, халыклар тормышына зур өлеш кертеп, кайгылы чакларында тынычландырып, караңгы көннәрен яктыртып, көнкүрешен ямьләндереп торган. Шунлыктан Иделне һәр халык үз итә, аңа багышлап үз телендә җырлар җырлый...

Гомәр Бәширов

учар мөгезле — җәелеп, тармакланып үскән мөгезле
бурсык — ерткыч җәнлек
борындык — җирдә өн казып яшәүче, тиенгә охшаган кечерәк җәнлек
поши — боланнар семьялыгыннан эре хайван
чиллә — җәйге эссе вакыт

Сораулар һәм биремнәр

1. Татарстанның табигате турында сөйләгез.
2. Республикада нинди зур елгалар бар?
3. Татарстанда нинди зур шәһәрләр бар?
4. Кама, Вятка елгалары элек ничек аталган?
5. Татарстандагы шәһәрләрнең, елгаларның исемен (үзегез белгәннәрен) дәфтәрегезгә языгыз.
6. Татарстан нинди файдалы казылмаларга бай?
7. Республиканың гербы, флагы турында ниләр беләсез?

Сажидә Сөләйманова
(1926—1980)

Сажидә Гаделша кызы Сөләйманова 1926 елның 3 октябрендә Башкортстанда, хәзерге район үзәге Яңавылда туа. 1944 елда Тәтешле урта мәктәбен тәмамлагач, авылда укытучы булып эшли. 1946—1950 елларда Уфада Башкорт педагогия институтының тарих факультетында югары белем алганнан соң, мәктәпләрдә тарих фәнен укыта. 1955 елда Әлмәт шәһәренә күчеп килә. 1973 елга кадәр ул Әлмәт нефть техникумында тарих укытучысы һәм шәһәр радиоүзәгендә редактор булып эшли. 1973 елның августыннан С. Сөләйманова, профессиональ язучылык хезмәтенә күчеп, әдәби иҗат белән генә шөгыльләнә.

С. Сөләйманова — лирик шагыйрә. Аның шигырьләрендә яшьлекләре сугыш чоры һәм сугыштан соңгы авыр елларга туры килгән бөтен бер буынның — авылда туып үскән кыз һәм егетләрнең — олы да, катлаулы да язмышы мәгънәле шигъри юллар, тәэсирле сүзләр һәм яңа сурәт-образлар аша тасвирлана. Шагыйрә иҗатында зур урын тоткан мәхәббәт лирикасы да хис-тойгыларның тирәнлеге, ихласлыгы һәм халык җырларына хас интонацияләре белән күңелне җәлеп итә. Сажидә Сөләйманова тормышның, яшәешнең әхлакый-фәлсәфи мәсьәләләрен күтәргән «Җир-су», «Фал китабы», «Мәңгелек ут», «Ак чәчәкле болын», «Сузган ике кулым» кебек поэмалар һәм «Саубуллашу вальсы», «Гүзәлия җыры»

(М. Имашев музыкасы), «Күңелем язлар көтә» (К. Хөснуллин музыкасы) кебек популяр җырлар авторы буларак та билгеле. Ул шулай ук проза әсәрләре дә язды («Гөлбадран» повесте, хикәяләр).

Үзе исән чагында С. Сөләйманованың Мәскәүдә һәм Казанда русча өч җыентыгы басылып чыкты. Аерым шигырьләре украин, үзбәк, азәрбайҗан һәм башка телләргә дә тәрҗемә ителде.

КАЙНЫЙ, ШАУЛЫЙ КАЗАН УРАМНАРЫ

Кайный, шаулый Казан урамнары,
Карлар оча, җилләр тилемсә.
Матурлыгын кичнең казанлылар
Күрми дәме әллә югыйсә?—

Кабалана алар, ашыгалар,—
Троллейбуска чират, кинога.
Өйсез җилләр белән җитәкләшеп,
Буран диңгезендә мин агам...

Яр өстендә, тауда ак манара.
Кремль сәгатендә ун тула.
Богауларын өзгән Муса, гүя
Болай гына ярда утыра...

Халыкларның күңелен яулап алган,
Үзенекен биреп алмашка.
Бөекләрнең даны ташка күчә,
Җаны иңә җиргә, тормышка.

Каплар өчен җирне ач бураннан,
Кыя-Муса кинәт калкына,
Кайный Казан, ялкыннары ялмый,—
Ташларыннан ялкын саркыла.

1973

манара — мәчет түбәсенә яки янына эшләнгән биек корылма (башня)
богау — тоткыннарның кул-аякларына кидерү өчен тимер богаулар
яулап алу — көрәшеп, җиңеп үзеңнеке итү
иңә — батып керә, сеңә
ялмый — ялый

Сорау һәм биремнәр

1. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз.
2. Казан урамнары, Казан Кремле, Муса Җәлил һәйкәле шигырьдә ничек тасвирлана?
3. *Бөекләрнең даны ташка куча,*
Җаны иңә җиргә, тормышка дигән шигъри юлларның мәгънәсен аңлатыгыз.

«Үзем турында үзем» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Син кайда туып үстең?
2. Синең әти-әниең кемнәр? Гаиләгездә тагын кемнәр бар?
3. Син кайсы мәктәптә укыйсың? Мәктәпне яратасыңмы?
4. Ял вакытыңны ничек үткәрәсең?
5. Синең яраткан шөгылең бармы?
6. Нинди эчтәлектәге китаплар укырга яратасың?
7. Нинди спорт төре белән шөгыльләнәсең?
8. Җәйге каникулда кайда ял итәсең? Үткән җәйге ялың нәрсә белән истәлекле булды?



Шәүкәт Галиев

(1928 елда туган)

Шәүкәт Галиев (Шәүкәт Галиулла улы Һидиятуллин) 1928 елның 20 ноябрендә Татарстанның Апас районы Олы Бакырчы авылында туа.

Үсмер һәм яшьлек еллары Бөек Ватан сугышына туры килгәнлектән, шул чорның авырлыгын үз җилкәсендә татыган шагыйрьләрнең берсе ул.

Шагыйрьнең алтмышынчы-җитмешенче елларда дөнья күргән «Сиңа әйтер сүзем бар», «Сөенечләрем, көенечләрем», «Уйларым-серләрем», «Фикердәшкә», «Чынлык», «Тамчылар тамар чаклар» кебек җыентыклары аны югары зәвыклы, сизгер рухлы лирик шагыйрь итеп танытты.

Шәүкәт Галиев — сатира һәм юмор остасы. Ул бу өлкәдә иҗатының башлангыч елларыннан башлап бүгенге көнгәчә актив эшләп килә. Шагыйрь «Шәвәли», «Кызык», «Гаҗәп хәлләр, мәзәк хәлләр», «Тәмле йорт», «Котбетдин мәргән» исемле шигырь җыентыклары өчен — Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә, ә 1980 елда рус телендә чыккан «Заяц на зарядке» китабы өчен, татар балалар язучыларыннан беренче буларак, Халыкара бүләк — Г.-Х. Андерсен исемендәге Почетлы дипломга лаек булды.

Ш. Галиев — балаларның яраткан шагыйре. 1962 елда аның балалар өчен махсус язылган шигырьләре тупланган

«Камырша» исемле җыентыгы басылып чыккан иде. Шуннан соңгы елларда авторның яшь дусларына багышлап язган егермеләп китабы дөнья күрде.

Шәүкәт Галиев балалар әдәбиятында бөек Тукай традицияләрен дәвам итә. Ул балалар күңеленә рәссам булып керә, алар белән яши, табигатьне тоярга, яратырга өйрәтә. Шагыйрь тудырган шигъри дөнья —искиткеч кызыклы, маҗаралы дөнья. Аның Камырша, Шәвәли кебек геройлары, укучыларның шаян дусларына әйләнеп, илебезнең төрле почмакларында сәяхәт итәләр.

«Шәүкәт Галиев — балаларның киңәшчесе, дусты. Ул аларны хезмәт сөяргә, гадел, тырыш, кыю булырга өйрәтә. Табигать бизәкләре, кеше күңеленең матурлыгы белән бергә күңелгә туган тел аһәңе сеңеп кала. Телнең тапкырлыгы, матурлыгы, байлыгы бу телдә сөйләшкән халыкка ихтирам уята»,— дип язган иде шагыйрә Саҗидә Сөләйманова Шәүкәт Галиев иҗаты хакында.

1995 елда Ш. Галиевкә Татарстанның халык шагыйре дигән мактаулы исем бирелде.

АЛТЫН КУЛЛАР

Искиткеч кул
Бар, ди, имеш:
Ул орынса —
Үсә җимеш,
Ул кагылса —
Чүл терелә,
Чәчәкләргә
Җир төрелә.
Тау, ташларны
Тотса әгәр,
Күз алдында
Калка шәһәр.

Яңа таулар
Өя икән,
Күккә йолдыз
Чөя икән!
Юк ул кулдан
Килмәгән эш,
Юк ул куллар
Белмәгән эш.
Бар дөньяда
Куллар — коллар.
Ә бу куллар —
Азат куллар.

Бәхет иле
Төзи алар,
Дөньябызны
Бизи алар!
Иң азактан
Әйтим шунсын:

Ул кулларда
Юк сер, тылсым...
Алтын түгел,
Гади куллар —
Синдә дә бар
Андый куллар!

1961

кол — колбиләүчелек җәмгыятендә изелүче сыйныф вәкиле
сер — әлегә ачылмаган, кешегә белдерергә ярамаган, яшерен мәгълүмат

Сораулар һәм биремнәр

1. Шигырьне сәнгатьле итеп укыгыз.
2. «Алтын куллы кеше» дип нинди кешегә әйтәләр? Ни өчен?
3. *Бар дөньяда*
   Куллар — коллар
   дигән юлларны сез ничек аңлыйсыз?
4. «Азат куллы кешеләр» кемнәр алар?
5. Түбәндәге мәкальләрне укыгыз һәм аларны шигырьнең эчтәлегеннән чыгып аңлатыгыз.

   Агачны яфрак бизәсә, кешене хезмәт бизи.
   Осталык — иң зур байлык.
   Өйрәнмичә хезмәт юк, хезмәт итми хөрмәт юк.
   Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.

ХӘЗИНӘ

Хәзинәләрне
Борын-борыннан
Эзләп бакканнар
Төрле урыннан.

Мөгаен, син дә
Уйга каласың,
Хәзинә диеп
Хыялланасың.

Ята кебектер
Таулар артында.
Ә үзе сиңа
Бик тә якында.
Төшә аласың
Бик тиз эзенә —
Китапханәдә
Ул бай хәзинә.

1968

хәзинә — байлык
эзләп багу — эзләп карау
эзенә төшү — билгеле бер нәрсәнең урынын ачыклау, табу

Сораулар һәм бирем

1. Шигырь нинди байлык турында?
2. Шагыйрь китапханәне ни өчен «хәзинә» дип атый?
3. Сез китапханәгә язылдыгызмы? Нинди китаплар алып укыдыгыз?
4. Китап турында сез нәрсәләр беләсез?
5. Шигырьне яттан сөйләргә өйрәнегез.

Китап турында мәкальләр

- Китап — белем чишмәсе.
- Китап — бер нәселнең икенче нәселгә калдырган мирасы.
- Китап — тормыш көзгесе.
- Китап укысаң — белемең артыр, укымасаң — белгәнең дә онытылыр.
- Китапсыз өй — тәрәзәсез бүлмә.
- Алтын җирдән табыла, акыл — китаптан.

ТЕЛЛӘР БЕЛҮЧЕ КАЛӘМ

Үзем дә сизми калам —
Татарча яза каләм.
Русчасын да ким белми —
Хәзер русча кем белми!
Артекта исем китте,
Чит телдә сырлап үтте:
Француз алгач кулына —
Французча яза каләм!
Немец алгач кулына —
Немецча яза каләм!

Инглизчә дә йөгерә,
Испанча да өлгерә,
Вьетнамча, гарәпчә —
Әллә ничә тел белә!
Язды каләм истәлек,
Бер үк булды эчтәлек:
«Тынычлык» диеп язды
Һәм «дуслык» диеп язды!
...Татарча язган каләм,
Русча да язган каләм,
Шулай бик тиз көйләнеп,
Дөньяларны әйләнеп,
Кайтты телләр өйрәнеп!

1980

каләм — карандаш, ручка
көйләнү — тәртипкә салыну, җайлану

Сораулар һәм бирем

1. Телләр белү ни өчен кирәк?
2. *Хәзер русча кем белми!* дигән юлларны сез ничек аңлыйсыз?
3. Артек турында нәрсәләр ишеткәнегез бар? Ул кайда?
4. Ни өчен шагыйрь каләмне «телләр белүче» дип атый?
5. Шигырьне ятлагыз.

МАГНИТОФОН ОНЫТМЫЙ...

Ун яшь тулгач Хәнифкә
Бик күп булган теләкләр.
Иң соңыннан бабасы
Магнитофон сөйләткән.
Күңелләре нечкәреп,
Тыңлап тора әнисе —
Өч яшь тулган көнендә
Шигырь укый Хәнифе!

Тыңлый Хәниф үзе дә,
Тик аңламый берни дә...
Ишетсә дә көн саен,
Бу телне ул белми лә!
    Үзе ни сөйләгәнне
    Үзе төшенми торгач,
    Аптыраган улына
    Әтисе була тылмач...
Күрсәң иде малайның
Ничек гаҗәпләнгәнен:
— Кара әле, яшь чакта
Мин татарча белгәнмен?!
    «И туган тел...» — ди Хәниф
    Магнитофон аркылы.
    Бар белгәнен онытмый —
    Магнитофон акыллы!

1975

күңел нечкәрү — дулкынлану, тәэсирләнү
тылмач — тәрҗемәче
төшенү — аңлау

Сораулар

1. Хәнифкә бабасы нәрсә «бүләк иткән»?
2. Хәниф кайчандыр үзе сөйләгән шигырьне аңламый. Ни өчен? Шагыйрь моның белән нәрсә әйтергә тели?
3. Хәнифнең туган телен онытып баруына кем гаепле дип уйлыйсыз?
4. Татар телен ни өчен туган телебез, ана теле дип әйтәбез?

САУМЫСЫЗ, АРЫШЛАРЫМ!

Исәнме, арыш кырларым,
Саумысыз, арышларым,
Сез минем сабый чагымнан
Иң якын танышларым.

Еракларда, чит җирләрдә
Нихәтле торып та мин,
Исләремнән чыгармадым,
Сагындым, онытмадым.
    Агайлар килсә авылдан,
    Сүзне гел сезгә бордым,—
    «Игеннәр ничек быел?» — дип,
    Хәлегезне белеп тордым.
Сезнең өчен сусадым мин,
Яңгырлар яумаса да;
Сызландым, өзелгән башак
Тузанда аунаса да.
    Сөенәм, бүген сезнең мин
    Шаулап үскәнне күреп;
    Башыгыздан сыйпыймчы бер,
    Юлымнан читкә кереп.
Ятсынмагансыз лабаса,
Куенга үреләсез;
Сез миңа, ничә кайтсам да,
Яшәреп күренәсез.
    Исәнме, иркен кырларым,
    Саумысыз, арышларым;
    Бөтенләйгә булсын иде
    Бу кайтып барышларым!

1959

сусау — эчәсе килү
сызлану — тән сызлап яки берәр әгъза авыртып газаплану

Сораулар

1. Шагыйрь ни өчен арышларга мөрәҗәгать итә?
2. Автор *Сызландым, өзелгән башак*
   Тузанда аунаса да
   дигән шигъри юллары белән нинди фикер әйтергә тели?
3. Сез арыш икмәген яратасызмы? Икмәк турында нинди мәкаль һәм әйтемнәр ишеткәнегез бар?
4. «Ипи кадерен белү» дигәнне ничек аңлыйсыз?

Рабит Батулла

(1938 елда туган)

Рабит Батулла (Роберт Мөслих улы Батуллин) 1938 елның 26 мартында Татарстанның Зәй районы Түбән Олоҗы авылында укытучы гаиләсендә туа. 1955 елда Биш авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, бер ел Кадер авылында җидееллык мәктәптә балалар укыта. 1956—1961 елларда Мәскәүдә М. С. Щепкин исемендәге театр училищесында укый, аны тәмамлагач, ике ел Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актёр булып эшли, бер үк вакытта режиссёрлык эше белән дә шөгыльләнә.

Рабит Батулла әдәбиятның төрле жанрларында иҗат итә. Балалар өчен язган повесть һәм хикәяләре, мавыктыргыч әкиятләре белән ул әдәбиятта үзенең ныклы урыны барлыгын раслады. Аның «Исемем минем Дүрткүз», «Серле сандык», «Чебен гөмбәсе», «Алып батыр маҗаралары», «Куян баласы Нуяк», «Үлемсез егет», «Тычкан баласы Чикыл», «Йолдызлар һаман исән», «Гөлчәһрә», «Ташсуар патша», «Каратай» кебек повесть-әкиятләре әкият жанрында эзләнүләренең уңышлы мисалы булып торалар.

Иҗатының баштагы чорында ул күбрәк Курчак театры өчен яза. Аның «Төш вакытындагы могҗиза», «Курай уйный бер малай» пьесалары Казанда гына түгел, Донецк, Саратов, Кемерово, Барнаул курчак театрлары сәхнәләрендә дә куела.

Рабит Батулла әдәбият сөючеләргә юмор-сатира әсәрләре авторы һәм үзенчәлекле драматург буларак та яхшы билгеле. «Туйлар узгач», «Өчәү юлга чыктык», «Кичер мине, әнкәй» пьесалары татар театрлары сәхнәләрендә куелды. Р. Батулла — «Юл буенда зәңгәр чәчәк» повесте, «Сөембикә» романы кебек тирән эчтәлекле, зур күләмле проза әсәрләре авторы да.

Әдәбият өлкәсендә ирешкән уңышлары һәм иҗтимагый эшчәнлеге өчен Рабит Батулла Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясенә лаек булды.

ДУСЛАР ДУС БУЛЫП КАЛА

(«Куян баласы Нуяк» әкиятеннән өзек)

Көннәр, атналар, айлар үтте. Карлар эреп, җәй килеп җитте. Быел туган куян балалары зур-зур куяннар булдылар инде. Күрше бакчаларга алма агачлары кимерергә барып, Карчыга, Төлкедән кача-кача йөреп, җәйнең үткәнен сизми дә калдылар куяннар.

Куян баласы Нуяк әрәмәлекләрдә, урман кырыенда, арышбодай басуларында күп тапкырлар булды. Урман кырыенда аны Ябалак-шаркүз тотып ботарлый язды. Нуяк, аркасы белән җиргә ятып, тәпиләре белән ябалакның кирәген бирде бирүен. Так кайбер куяннар алай итеп кенә дә котыла алмадылар, бичаралар.

Аннан соң куян баласы Нуяк арыш арасында булган бер фаҗигане үз күзләре белән күреп торды.

Урман авызына килгәндә, ул күрше Кыр тычканын гел-гел очрата иде. Ләкин соңгы килүендә Нуяк, Тычкан өне янында бөгәрләнеп яткан Кара еланны күреп, артка чигенде. Елан аны күрмәде. Шулчак тишектән ялт итеп Кыр тычканы килеп чыкмасынмы! Тычкан, Кара еланны күреп, кире кереп китмәкче булды. Елан башын өскә күтәрде. Мескен Тычкан дер-дер калтырый башлады.

— Кач инде, Тычкан, кач тизрәк! — дип кычкырды Нуяк эчтән генә.

Тик Кыр тычканы, Кара еланның сихерле карашыннан аерыла алмыйча, тик карап тора бирә. Кара елан, карашы белән Тычканны сихерләп, башын әле бер якка, әле икенче якка чайкалтып торды-торды да зур итеп авызын ачты. Тычкан теләмәсә дә, бөгәрләнә-бөгәрләнә, акрынлап-акрынлап, Кара елан авызына суырылып килә башлады. Менә Кыр тычканы Елан авызына килеп терәлде. Елан кисәк кенә һап итте дә капты да йотты мескен Тычканны. Тамагы туйгач, Елан акрын гына юлга таба шуышты.

Соңгы көннәрдә булган тагын бер вакыйга Нуякның күңелендә үлгәнче сакланыр. Төнлә белән, ай чыкмаган чакта булды бу хәл.

Куе бодай басуында Нуякны Төлке куды. Куянның хәле беткән иде. Төлке куянның муеныннан эләктерим дигәндә генә, әллә каян гына бытыр-бытыр итеп комбайн килеп чыкты да бодай ура башлады. Арттан Төлке куа. Алдан куркыныч комбайн килә. Комбайн өстендә һәрвакыт кешеләр була. Кая барырга? Үзе дә сизмәстән, куян яктылыкка килеп керде. Бу яктылыктан Нуякның күзләре сукырайды. Ул сукыр килеш кире йөгерә башлады.

— Әй егетләр, карагыз әле, кыр куянын төлке куа! — дип кычкырды кеше, комбайн тавышыннан да уздырып.

Куян йөгерде дә йөгерде. Бераздан аның күзләре күрә башлады. Тик Нуяк яктылыктан читкә тайпыла алмады. Комбайн яктылыгы беткән җирдә үк дөм караңгы упкын башлана, шул упкын кырында аны Төлке сагалап торадыр кебек тоелды Нуякка. Нуяк тәмам әлсерәде. Аны берничә кеше яктылык уртасында куарга тотындылар. Кешеләр бөҗрасы тарайганнан-тарая барды. Нуяк качарга мөмкинчелек тә, көче дә юклыгын сизде һәм, язмышына буйсынып, җиргә сеңде. Кешеләр аның өстенә иелде.

— Бичара куян! — диде кеше. Кешеләрдән комбайн исе аңкый иде.

— Өйгә алып кайтыйк...

— Кирәкми, бу арык куян белән ни эшлисең?

— Асрарбыз!

— Алып кайтып җиткергәнче йөрәге ярылып үләр... Төлке интектергән, мескенне, аннан соң без... Әй, Мәмәт!

Караңгылыктан:

— Әү! Нәрсә кирәк? — дигән тавыш ишетелде.

— Фараларыңны сүндер! Куян ут яктысыннан чыгып китсен!

карчыга — ерткыч кош
ябалак — зур күзле, йомры башлы төнге кош
фаҗига — бәхетсезлек
әлсерәү — хәлсезләнү

Сораулар

1. Куяннар җәйне ничек уздырганнар?
2. Куян баласы Нуяк Ябалак-шаркүздән ничек котыла?
3. Нуяк арыш арасында нинди фаҗига күрә? Ул кемгә ярдәм итәргә тели?
4. Кара елан нинди юллар белән Тычканны үз янына килергә мәҗбүр итә?
5. Төлке тозагыннан Нуякны кем коткара?

* * *

Яктылык сүнде. Кешеләр китте. Кешеләр киткәч тә, Нуяк байтак ятты. Күзләре караңгылыкка күнеккәч кенә, ул әрәмәлеккә таба чапты. Еракта калган комбайн тагын гөрелди башлады, утларын кабызды да бодай җиренә кереп китте.

Нуяк әнкәсе сүзләрен искә төшерде: «Аучы ул рәхимсез, аучыдан ерак йөр!» — ди торган иде ул.

Ә бу кешеләр Нуякны Төлкедән коткарып кына калмадылар, иркәли-иркәли ирекка җибәрделәр.

Шундый-шундый хәлләр, диген!

Куян баласы Нуяк шулай тормыш итә!

Ул кая гына бармасын, аның артыннан, бер карыш та калмыйча, Корусак белән Койрыксыз йөри. Алар Нуякка усак кайрылары, чәчәкләр, яшелчә яфраклары бүләк итәләр. Тик Нуяк аларның бүләкләрен алмый.

Бүреләр белән очрашу көтмәгәндә булды.

Нуяк яшелчә бакчасыннан кайтып килә иде. Әрәмәдән атылып-бәрелеп бер бүре килеп чыкты да куянга ташланды. Нуяк куркудан шырылдап акырып җибәрде. Авызына капкан чөгендер яфрагы җиргә төшеп китте. Куян кирегә таба йөгерә башлады. Бакчага якынрак барсаң, бәлки бүре, кешеләрдән куркып, кире китәр, дип уйлады Нуяк. Ләкин бүре, аны-моны уйлап тормыйча, Нуяк артыннан чаба да чаба. Шулчак Нуяк ян-яктан тагын бер бүре чапканын күрде. Бетте баш, дип уйлый Нуяк, бүреләр камалышыннан исән чыккан куян заты дөньяда юк! Тик яндагы бүре куянны алга үткәреп җибәрде дә арттан Нуякны куып килүче бүрегә ташланды. Бу Вартул иде. Нуяк ике бүре талашканын ерактан карап торды.

— Ах син, сатлык җан! — дип хырылдады беренче бүре.— Куркак!

— Мин куркак түгел! Тик куянга кагыласы булма! Бөтенегезгә ачу итеп мин куян белән дуслашам,— диде Вартул.

— Карарбыз! Мин чиругә кайтып бу эшеңне җиткерим әле. Аннан соң, күрербез! Сине чирудән куарга кирәк! — Беренче бүре Вартулга яный-яный урман ягына таба китте.

Вартул Нуяк ягына борылды.

— Нуяк! — диде ул.— Бар, сине әрәмәдә башка куяннар көтә! Бар, мин барында ул сиңа тимәс!

Нуяк, рәхмәт әйтеп, әрәмәлеккә томырылды.

Чынлап та, әрәмәдә аны куяннар көтә иде.

— Без барысын да күреп тордык...— диде Корусак.

— Ярый әле бәла-каза булмады...

Монысын Койрыксыз әйтте.

— Нуяк! — диде Корусак, өчесе калгач.— Менә синең алда Койрыксыз белән мин. Син үзең сайла!

Нуяк елмайды.

— Син яшерми-нитми генә әйт тә бир, Нуяк! — диде Корусак.— Без зурлар бит инде, авыр булса да үпкәләмибез!

— Корусак дөрес әйтә...— диде Койрыксыз.

Нуяк ниндидер бер карарга килде, ахрысы, иркен сулап куйды. Ул Корусак ягына күчеп утырды.

Койрыксыз сагышлы гына елмайгандай итте.

карыш — үлчәү берәмлеге: киерелгән кулның баш бармак очы белән урта бармак очы арасы
камалыш — чолганыш
ян-як — кырый, чит
чиру — *монда:* төркем
әрәмә — болын

Сораулар һәм бирем

1. Ни өчен кешеләр куянны иреккә җибәрәләр?
2. Куян баласы кешеләр турында ничек уйлый?
3. Нуякка кемнәр һәрвакыт ярдәм итәләр?
4. Нуяк бүредән ничек котыла?
5. Бүренең «куркак» дигән сүзенә Вартул ничек җавап бирә?
6. Куян баласы Нуяк дусларыннан кемне аеруча якын күрә?
7. Әкияттә дуслык, бердәмлекнең көче ничек тасвирлана?
8. Әкият геройларының рәсемен ясагыз.

Фәнис Яруллин

(1938 елда туган)

Фәнис Яруллин (Фәниз Гатаулла улы Яруллин) 1938 елның 9 февралендә Татарстанның Баулы районы Кызылъяр авылында игенче гаиләсендә туа. Җидееллык белемне туган авылында ала. 1957 елда армия сафларына чакырыла. Шунда хәрби радист булырга әзерләнә, спорт белән шөгыльләнә. Кызганычка каршы, спорт күнегүләре вакытында егылып имгәнә. Озак еллар урын өстендә ятуына карамастан, Ф. Яруллин бөтен тырышлыгын белемен тирәнәйтүгә, иҗат осталыгына ирешүгә бирә: 1963 елда урта мәктәпне, 1970 елда исә, читтән торып, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый. Бу елларда шигырьләр, хикәяләр яза. 1964 елда авторның беренче китабы — «Мин тормышка гашыйк» исемле шигырьләр җыентыгы, 1972 елда автобиографик материалларга нигезләнеп иҗат ителгән «Җилкәннәр җилдә сынала» исемле повесте дөнья күрә. Әдәби җәмәгатьчелек тә, укучылар да бу әсәрне яратып кабул итәләр. Автор бу әсәре белән киң катлау укучыларга танылa, повесть рус, казах телләрендә дә басылып чыга.

Ф. Яруллин — ике дистәдән артык шигырь һәм проза китаплары авторы. «Аерылмас дустым» һәм «Сулыш» шигъри җыентыклары өчен ул 1978 елда республикабызның Муса Җәлил исемендәге премиясенә лаек булды.

Ф. Яруллин драма әсәрләре дә иҗат итә. Аның «Әнә килә

автомобиль» комедиясе, республика театрлары сәхнәсендә куелып, тамашачы күңелен яулады.

Ул — балалар һәм өлкәннәр өчен әкиятләр язу остасы да. Татарстан китап нәшриятында 1990 елда аның «Зәңгәр күлдә ай коена» дигән әкиятләр җыентыгы басылып чыкты. 1996 елда «Мәгариф» нәшриятында «Өе — балчык, иясе — чарчык» һәм «Биюче бака» исемле әкият китаплары дөнья күрде.

Әдәбият-сәнгать өлкәсендә армый-талмый эшләгән өчен Фәнис Яруллинга 1985 елда Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән исем бирелде. 1995 елда ул Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

АНАМ ТЕЛЕ

Татар теле — анам теле,
Иң борынгы бабам теле.
Буыннардан буыннарга
Күчеп килгән заман теле.

Ничә гасыр чарлангансың,
Матурайган, яңаргансың.
Халкыбызның күңеленнән
Җыр алгансың, моң алгансың.

Изелгәнсең, тапталгансың,
Пычратсалар — пакьләнгәнсең.
Милләтемнең үлмәс җанын
Син үзеңдә саклагансың.

Сиңа безнең язмыш сыйган,
Син кайгы һәм шатлык теле.
Татарымны татар иткән
Беренче һәм актык теле.

Анам теле — телләр теле,
Милләтемнең бердәнбере.
Син булганга без дә исән,
Син булганга без дә тере.

пакьләну — чистару
чарлану — тәҗрибәле, үткен кешегә әйләну, остару, шомару

Сораулар һәм бирем

1. Туган телебезнең бай тарихлы тел булуы шигырьдә нинди сүзтезмәләр ярдәмендә бәян ителә?
2. Авторның
   Халкыбызның күңеленнән
   Җыр алгансың, моң алгансың дигән шигъри юлларын ничек аңлыйсыз?
3. Татарча нинди китаплар, газета-журналлар укыйсыз?
4. Татарча радио-телевидение тапшыруларын яратасызмы? Татар театрларында нинди спектакльләр караганыгыз бар?
5. Ана теле турында нинди җыр, мәкаль һәм әйтемнәр беләсез?
6. Шигырьне сәнгатьле итеп укырга өйрәнегез.

КОЯШТАГЫ ТАП

Еракта, бик еракта, Каф тавының аръягында, кояш һәр көн йокларга кайта торган җирдә яшәгән, ди, бер малай. Малайның бары тик әнисе генә булган, ди. Малайның әнисе кояш белән бергә торган, кояш белән бергә яткан. Ул көннәр буе нидер чәчкән, нидер урган, нидер төзәткән, нидер яңарткан...

Менә көннәрдән бер көнне малайның әнисе авырып түшәккә егылган. Шунда ул урамда болытларга ук атып йөрүче улын өенә чакырып керткән дә болай дигән:

— Улым, үзең күрәсең, хәлем кинәт начарланып китте. Хәтта суга барырга да өлгерми калдым. Ә минем бик-бик эчәсем килә. Иреннәрем кара көеп чыкты. Берәр чиләк су гына алып кайтчы, балам.

Малай үзен кызыклы уеннан бүлдергән әнисенә канәгатьсезлек белән карап:

— Суны иртән тору белән алып кайтып куйсаң булмый идемени? — дигән.

— Иртүк алып кайтсам көне буе җылынып бетәр дигән идем. Син бит кичләрен уеннан арып кайткач салкын су эчәргә яратасың,— дигән малайның әнисе.

Малай бик авырлык белән генә суга барырга ризалык белдергән.

— Улым,— дигән әнисе аңарга,— суны теге Көймә тавы артындагы чишмәдән ал. Аның суы тәмле дә, салкын да, шифалы да.

Малай чиләген күтәреп урамга чыккан. Кулын кашына куеп, Көймә тавына таба караган. Көймә тавы бик-бик еракта, зәңгәр офыклар артында булып күренгән аңа. Җитмәсә, кояшы өтеп алырдай итеп кыздыра икән.

«Мондый кызуда шул тиклем еракка барып йөргәнче, суны менә шушы якындагы чишмәдән алсам да ярар әле»,— дип уйлаган малай һәм, чиләген бер читкә куеп, өр-яңадан уйнарга тотынган. Үзенең дә бик каты эчәсе килгәч кенә, суга барырга кирәклеге исенә төшкән.

Менә ул бермәлне тирләп-пешеп судан кайтып кергән. Әнисе аның чәчләреннән сыйпап: «Рәхмәт, улым, бик зур рәхмәт»,— дигән. Һәм йотлыгып-йотлыгып суны эчә башлаган. Эчкән саен күкрәгендә көч арта баруын сизгән. Бераздан инде бөтенләй сәламәтләнеп җиткән. Малай сөенә-сөенә урамга чыгып йөгергән.

«Белмәде, әнием суның кайсы чишмәнеке икәнлеген белмәде»,— дип уйлаган ул. Шулай дип уйлавы булган, күктә яп-якты булып янучы кояш кинәт карала башлаган. Дөнья коточкыч ямьсезләнеп киткән. Кош-кортлар, куркышып, ояларына качканнар. Шомлы итеп, елап-елап этләр өрергә тотынган. Малай, ни уйларга да белмичә, курка-курка өенә чапкан.

— Әни,— дигән ул, сулышын көчкә-көчкә алып,— нишләптер, кояшның йөзе каралды. Әнә тышка кара әле.

Әнисе кояшка караган да болай дигән:

— Кемдер бу дөньяда ялган эш кылган булырга тиеш, улым. Кояшның шул кеше өчен оялудан йөзе каралып чыккан. Чөнки җирдә кояш күрмәгән бер генә эш тә юк.

— Әни,— дигән малай, башын түбән иеп,— мин суны Көймә тавы артындагы чишмәдән алмаган идем, гафу ит мине.

Малай мөлдерәмә яшьле күзләре белән әнисенә караган. Әнисе улын күкрәгенә кыскан. Шулвакыт кояштагы караңгылык кими башлаган. Дөнья әкренләп яктырган, кошлар, кереп поскан ояларыннан чыгып, агач ботакларына кунганнар, этләр елый-елый өрүләреннән туктаганнар. Бар нәрсә элекке хәленә кайткан, бары тик кояштагы кара тап кына бөтенләй бетеп җитмәгән.

Әйе, дөньяда бер генә яманлык та, бер генә ялган да эзсез калмый шул. Яманлыкны хәтта кояш та яндырып бетерә алмый икән.

Каф тавы — Кавказ тавы
шифалы — сихәтле, файдалы
офык — күкнең җир яки су белән тоташкан сыман күренгән сызыгы (горизонт)
шомлы — хәвефле, куркыныч
яманлык — начарлык

Сораулар һәм бирем

1. Әнисе улыннан нәрсә үтенә?
2. Малай авыру әнисенә ничек җавап бирә? Сез ничек җавап бирер идегез һәм нишләр идегез?
3. Кояшның каралу сәбәбен әнисе улына ничек аңлата?
4. *Дөньяда бер генә яманлык та, бер генә ялган да эзсез калмый шул* дигән җөмләнең мәгънәсен аңлатыгыз.

«Мин бакча яратам» темасына сөйләшү өчен сораулар

1. Безнең бакчаларда нинди җимеш агачлары, яшелчә, чәчәкләр үсә?
2. Сез бакчада әти-әниегезгә булышасызмы? Нинди эшләр башкарасыз?
3. Бакчада нинди эш кораллары белән эш итәләр?
4. Бакчачы җиләк-җимеш, яшелчә, чәчәк корткычларына каршы көрәштә нинди чаралар куллана?
5. Елның төрле фасылында бакчада нинди эшләр башкарыла?
6. Мәктәп бакчасында сез нинди җиләк-җимеш, яшелчә һәм чәчәкләр үстерәсез? Нинди тәҗрибәләр үткәрәсез?
7. Яшелчә, җиләк-җимеш, чәчәк исемнәрен русча һәм татарча әйтегез. Кем күбрәк әйтә алыр?

Шамил Маннапов
(1938 елда туган)

Шагыйрь һәм прозаик Шамил Мәгыйзь улы Маннапов 1938 елның 1 гыйнварында Татарстанның Әлки районы Татар Мулла авылында туа.

Бик иртә укырга-язарга өйрәнә, әнисе тәэсирендә шигырьләр яза башлый.

1957 елда Алпар урта мәктәбен тәмамлап, авылда механизатор булып эшләгән җиреннән солдатка алына.

Шамил Маннапов әдәбият мәйданына зур тормыш мәктәбен узып килә. Өч ел армиядә хезмәт итү, Казан дәүләт университетында уку, авылда балалар укыту, газета-журналларда корреспондент, журналист, редакторлык хезмәте...

Әдип, үз әсәрләрендә тормышның һәм заманның асыл сыйфатларын игътибар үзәгенә алып, аларның кеше күңелендә үзенчәлекне чагылышын тасвирлый, яхшылыкның — яманлыкны, яктылыкның караңгылыкны җиңеп чыгачагына ининуын белдерә.

Төрле елларда нәшер ителгән «Тугрылык алиһәсе», «Кайту», «Апрель авазы», «Җиргә сыенам», «Өндәге төшләр» исемле шигъри китаплары авторның туктаусыз эзләнүен, югары сәнгать камиллегенә ирешә алуын янә бер кат күрсәтте.

Шамил Маннапов иҗатына халыкчан гадилек, самими юмор, фәлсәфи уйланулар хас. «Эти урманы», «Ачы какылар», «Мәңгелектән елмаю» дигән проза китаплары да шуның ачык мисалы булып торалар.

Әтисе үрнәгендә бала чагыннан ук халык авыз иҗаты әсәрләрен җыю, туплау, язып алу белән кызыксынган әдип соңгы елларда аларны әдәби эшкәртеп, яңаларын җыеп, «Шаян яктылык яки Шаман мәзәкләре» китабын нәшер итте.

1979 елдан Язучылар берлеге әгъзасы Шамил Маннапов әдәби тәнкыйть һәм тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлы иҗат итә. Аңа 1992 елда, әдәбият һәм сәнгатьне үстерүдәге казанышлары өчен, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде.

МИН ГАРМУНГА НИЧЕК ӨЙРӘНДЕМ
(бабам хикәяте)

Уф! Килеп җиттем. Ләкин кулым ишек тоткасының боз кебек салкын тимеренә орынуга, калтыранып артка чигендем. Чү, ашыкма! Бу бит мунча. Әйе, алдымда, төн караңгылыгына төренеп, нәрсәдер сагалаган сыман, серле тынлыкта Гариф бабайлар мунчасы утыра. Бирегә ялгышып яки адашып килдемме соң? Юк шул, ялгышып та, адашып та түгел. Култыгымдагы шушы гармунны күтәреп, өченче төн килүем инде монда. Беренче килүемдә дә, икенчесендә дә менә шул каһәр суккан ишек бавы харап итте. Кулым тиюгә, салкыны, электр тогыдай, бөтен тәнемә йөгерә. Әчкә керергә йөрәк җитми. Ә бит мунчага керә алсам, күптәнге хыялыма — гармунга өйрәнү бәхетенә ирешер идем. Ничек, дисезме? Белмисезмени? Алайса, сезнең Гармунчы Гариф бабай турындагы хикәятне ишеткәнегез юктыр. Безнең якта аны яхшы беләләр.

Кичләрен Гариф бабай, үз бакчасындагы эскәмиягә утырып, саратский гармунын тартып җибәрүгә, яшьләр җыела башлый, безнең капка төбендәге әбиләр яшьләнгән күзләрен сөрткәлиләр.

— Әй өздерә дә соң, бу Гарифулланы әйтәм.

— Ул гармунга мунчада өйрәнгән шул.

— Аны мунча иясе өйрәткән, диләр бит. Әгәр дә мәгәр җиде төн уртасында гармун алып мунчага барсаң, мунча иясе шул ук төнне гармун уйнарга өйрәтеп җибәрә, имеш...

Бу сүзләрне тыңлаганда минем йөрәк кыбырсынып куя. Бер төн эчендә гармунга өйрәнү!.. Шүрләмәскә генә кирәк. Сез: «Әбиләр әкиятенә ышандыңмы?» — диярсез. Баштарак мин ышанмаган да идем. Ә Гариф бабайның үзен күреп сөйләшкәннән соң, шигем эреде дә бетте. Ике сүздән аңлашылды.

— Бабай, сине гармунга мунчада өйрәнгән, диләр. Шул сүз дөресме? —диюемә, ул эш арасында гына:

— Рас бу сүз, улым, рас,— диде.

Урра! Мин дә өйрәнәм гармунга. Өченче классны тәмамлагач әти бүләк иткән тальян гармун өстәлдә тын тартмыйча җитәрлек утырды. Өйрәнәм булгач өйрәнәм! Күңелне кытыклап торган сөенечне малайларга да әйтеп салдым:

— Фи,— мин әйтәм,— иртәгә минем гармунда уйнавымны тыңларга килегез.

Алар авыз гына ердылар.

Шулай да үзләре икенче көнне килделәр. Ә мин... Ул төнне мунчадан гармунның «г» хәрефен дә өйрәнә алмыйча кайткан идем. Гаеп үземдә булды, эчкә керергә курыктым.

Бүген соңгы төн. Я керәм мунчага, яисә малайлар алдында дәрәҗә бөтенләй төшәчәк. Эх, керәм дигәндә генә төн карасыдай шомлы уйлар башка килмәсә иде. Әйтик, кердем, ди. Керүгә мунча иясе өскә «гөрс» итеп сикереп төшсә... Әй, керәмме соң! Ә малайлар?.. Алар, белеп торам, иртәгә җыелышып килерләр дә:

— Кая әле, гармунчы, сыздыр булмаса,— дип авыз ерырлар. Эх, шул вакыт «тиндер-тиндер» иттереп уйнап җиппәрәсе!

Керәм! Гариф бабай да минем кебек вакытында кергән, үлмәгән бит.

Ишек үзеннән-үзе диярлек ачылып китте. Һәм мине мунчага гүя артымнан этеп керттеләр. Борынга каен себеркесенең юеш исе килеп бәрелде... Нинди кызу, бүген генә ягып кергәннәр, ахрысы. Капшанып, эскәмияне табам. Гармунны мең бәла белән тезгә күчерәм. Калтыранган бармакларым шома баскаклар өстендә шуыша башлыйлар.

— Тран-тран-трин!..

Бу ни хикмәт, мин «Көмеш телле гармун» көен уйнамакчы булам, ә гармунымның көмеш телләре майланмаган арба тәгәрмәче сыман шыгырдый да тора.

Чү, нәрсә ул ләүкәдән шап итеп идәнгә сикерде? Мунча иясе! Мөгаен, шул. Гармунны тагын да тырышыбрак тартырга тотындым:

— Бга, бга, бак-бак!..

Кинәт шундый ук икенче бер тавыш, минем гармуннан уздырырга теләгәндәй, шарран ярып салды:

— Бака-ка-как!

Тфү! Бака икән ләбаса.

Таң ата башлады. Тирә-якны яңгыратып, әтәчләр кычкырдылар. Мунчадан чыгуыма, мине тал-тирәктәге каргалар каркылдашып каршы алды. Гүя алар миннән шаркылдашып көләләр иде. Көләрләр дә шул, юк-бар сүзгә ышанып йөргәч. Ә соң Гариф бабай... Алдады микәнни? Туктале, үзен күрим әле.

Гариф бабайны бакчасында таптым. Ул: «Кара инде, яшь ботакларны кояш нурыннан тәмам томалаганнар бит»,—дип, алмагачларның корыган ботакларын кисеп йөри иде. Эшеннән тиз генә тукталмаячагын белгәнгә, мин аны бүлдерергә булдым:

— Бабай,— дидем,— мин ни дип... килгән идем...

Гариф бабай, миңа күтәрелеп карамыйча гына, җитен мыегы астыннан көлемсерәде:

— Күрәм. Йомышың култыгыңда.

— Бабай, син бит гармунга мунчада өйрәндем дигән идең...

— Рас әйтәсең, рас,— дип җавап кайтарды Гариф бабай, эшен дәвам итеп.

Мин түзмәдем:

— Расын рас, бабай, расың дөрес булып чыкмады бит әле менә. Төн буе мунча саклап кайтып киләм...

Гариф бабай эшеннән туктап миңа текәлде. Маңгаенда гармун кабыргалары кебек җыерчыклар хасил булды. Ул җитен сакалын бераз сыйпап-тарткалап алды. Йөзендәге җыерчыклар елмайды:

— Бәй, әнә син нәрсәгә ышангансың икән!

— Ничек инде ышанмаска, ди, синең сүзгә.

— Ә мин алдашмадым. Дөресе шулай. Мунчада өйрәндем мин гармунга. Әмма ләкин ник мунчада өйрәндем? Син бу хакта сорамадың бит. Тыңла алайса, үзем сөйлим.

Әйе... Сезнең хәзерге нигездә элек Насрый исемле кеше яши иде. Андыйларны Хода үзе күрсәтмәсен. Җыр-көй дигәнне җене сөймәс иде шуның. Гармун шыгырдатканны ишетте исә, таягын тотып тукмакларга ташланыр иде. Минем дә үткен чак. Әмәлен таптым: ярканат кебек, караңгы төшкәнне сагалап торам да элдертәм мунчага.

Насрый бабаң төнлә мунчага түгел, үз кирәгенә чыгарга да шүрлидер иде. Һе-һе. Тик яктыргач кына, урамга чыгып, әтәч кебек кагына-кагына, үткән-барганга кычкыра: «Задә малае мунчада шайтаннардан яәҗүҗ-мәәҗүҗ һөнәренә өйрәнә! Авылның бәрәкәтен качыра!»

Ә хәзер нигә мунчага качарга ди. Җыр-көйгә — хөрмәт, шуның өчен зур-зур мәптәкләр салынган. Маһирлыгың бар икән, рәхим ит, өйрән генә. Һай, заманасы башка, улым, хәзер, заманасы...

Чү, ник борыныңны салындырдың әле? Күрәм, гармунга һәвәслегең зур. Бик әйбәт. Килгәлә, үзем өйрәтермен. Кая әле, әбиең иртәнге чәйгә чакырганчы, икәүләп берәр көйне шыгырдатып карыйк әле...

...Гармунны теземә утырттым. Бармакларыма бабайның эштә кытыршыланган кулы кагылды, һәм сызылып кына Гариф бабай яратып уйный торган таныш көй чыга башлады.

йөрәк җитмәү — курку
кыбырсыну — тынычсызлану
шүрләмәү — курыкмау
тын тартмыйча — тыныч
дәрәҗә — *монда:* абруй, авторитет
баскак — гармун теле
шәрран яру — кычкыру
томалау — каплау
җитен мыек — *монда:* агарган, чал кергән мыек
рас әйтү — дөрес әйтү
нигез — йорт урыны
тукмакларга — кыйнарга
җене сөймәү — яратмау
әмәл — җай
маһирлык — сәләт

Сораулар

1. Гариф бабай кем ул?
2. Малай ни өчен мунчага төнлә бара? Ул нәрсә турында хыяллана?
3. Малай мунчада нәрсәдән курка? Ул куркуын ничек җиңә?
4. Малайны гармунда уйнарга кем өйрәтә?

Солтан Шәмси

(1946 елда туган)

Солтан Шәмси (Солтан Сәләх улы Шәмсетдинов) 1946 елның 10 февралендә Татарстанның Биектау (элекке Дөбьяз) районы Суыксу авылында колхозчы гаиләсендә дөньяга килә. Балалык һәм үсмер еллары шул районның Юртыш авылында уза. Анда җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казандагы һөнәр училищесында токарь белгечлеген үзләштерә. 1962 елда Мәскәүгә китә һәм ун ел башкала заводларында эшли. 1972—1977 елларда М. Горький исемендәге Әдәбият институтында укый.

Әдәбият өлкәсендә Солтан Шәмси тәрҗемәче һәм оригиналь проза әсәрләре авторы, сәләтле журналист, оста мөхәррир буларак та билгеле.

Аның «Көмеш чылбыр», «Җәяүле буран», «Еллар эзе» исемле хикәя җыентыклары, «Читлек» пьесасы, «Кубрат» исемле тарихи-драматик әсәре, «Ут хәйләсе» дип аталган фәлсәфи повесть-әкияте, «Идел Болгарстаны», «Ибне Фазлан сәяхәте» (татар һәм рус телләрендә), «Низаглы йортта» исемле татар халкы тарихына багышланган китаплары, публицистик һәм таихи язмалары дөнья күрде. Ул шулай ук Г. Ибраһимов, Р. Фәхретдин, М. Әмир, Л. Ихсанова һәм башкаларның аерым повесть һәм хикәяләрен — русчага, Н. Думбадзе, Г. Матевосян, С. Воронин, С. Данилов, А. Мифтахетдинов әсәрләрен татарчага тәрҗемә итте.

Автор үзен нечкә психологик хикәя остасы итеп күрсәтә алды. Аның «Каты чикләвек», «Табигатьнең газиз баласы», «Синеке булыр», «Соңгы юаныч» һ.б. хикәяләрендә тетрәндерә дә, уйландыра да торган күп төрле характер-образлар белән очрашабыз.

Татарстан Президенты указы белән, әдәбият-мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен, Солтан Сәләх улы Шәмсетдиновка Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде.

ТАБИГАТЬНЕҢ ГАЗИЗ БАЛАСЫ

Авылда Гаффә карчыкның яшь чагын бик аз кеше хәтерлидер. Күпләргә ул гел шулай ак чәчле, кулына шомарган таяк тотып йөрүче бөкрерәк бер карчык булгандыр төсле тоела. Аңа ничә яшь икәнен дә тәгаен белүче юктыр, мөгаен. Хәер, моның белән кем генә кызыксыныр икән. Кешедә бит, мәсәлән, йорт төзегәндә йомычка кайгысы түгел, аның өйне тизрәк салып бетерәсе, кереп утырасы килә. Ә авыл хәзер даими төзи, нәрсәнедер гел яңартып, тазартып тора, каядыр ашкына, кабалана... Гаффә карчык исә күптән инде авыл өчен төзелештәге йомычка кебегрәк бер нәрсәгә әверелде.

Элегрәк Гаффә карчык авылга кайта-китә йөри иде. Кайдадыр Ташкент якларында кияүдә аның бердәнбер кызы бар диләр,— шуның янына чыгып китеп, бер ярты елга күздән югалып торгалый иде ул. Хәзер хәл үзгәрде. Менә ике еллап инде гел авылда тора карчык. Әллә киявенә сыймаган, әллә инде соңгы баруында кызы ачык чырай күрсәтмәгән, бәлки ерак юлга чыгып китәргә хәленнән килмидер,— белмәссең. Кыскасы, шул кайтудан карчыкның авылдан чыгып йөргәне юк. Хәзер гомерен такта түбәсе яшел гөмбә белән капланган кечкенә өендә уздыра. Өй инде, аскы нигезләре череп, бер якка янтая да башлаган, болдыр такталарының да бер-икесе юк,— алар урынына кирпеч куелган. Кайчандыр ярыйсы гына булган сарай түбәсендә дә алабута үсеп утыра. Калтырап

торган капканы этеп җибәрсәң, ишегалдына күптән инде ир-ат басмавын, йортның таралып, ташландык хәлдә ятуын, бөтен җирне кычыткан каплап китүен күрәсең.

Карчыкның тормышы авыл халкы өчен сер дисәң дә арттыру булмас. Ничек яши ул, ни хисабына яши — берәү дә рәтләп белми. Кызыксына калсалар, бәлки алай сер дә булмас иде. Юк шул, үз мәшәкатьләре күп, вакытлары юк авылдашларының,— тормыш артыннан куалар. Ярыша-ярыша кара-каршы йортлар салалар, машина алалар, гаражлар төзиләр. Санап кына бетерерлекме соң хәзер авыл кешесенең мәшәкатен. Бер-бер артлы балалары үсә тора, барысын да укытасы, вакытында урнаштырасы, тормышлы итәсе бар. Берберeңнән уздырырга теләп туйлар үткәрү дә күпме көч, вакыт, сума сорый. Шуның өстенә үсә торган ул балалар затлыдан-затлы кием, мотоцикл, магнитофон, алтын-көмеш әйберләр дә таләп итеп кенә торалар. Алмасаң да яхшы түгел, иптәшләре арасында кимсенмәсен, күңеле кителмәсен, нәүмиз булып йөрмәсен дисең. Синеке генә сорамый, тәртибе шул...

Билгеле инде, боларның барысына да акча, акча кирәк. Ә акчаны тик утырганга гына бирмиләр. Аны табу өчен көнтөн йөгерергә, алны-ялны белмичә бөтерелергә, каядыр барырга, кемнәрнедер күрергә, икешәр сыер, тана, бозау асрарга, унбиш-егерме сарык, мамык кәҗәләре, кролик тотарга кирәк. Шулай булгач, кайда инде ул ялгыз карчык турында уйлау. Аның бит мөһимрәк, ашыгычрак, бүген өлгермәсәң яна торган эшләре дә санап бетергесез, көн туды исә чыга да тора...

Мәшәкатькә чумган авылдашларының вакыты ничек кенә тар булмасын, елына ике тапкыр Гаффә карчык йортында да чит тавышлар ишетелеп ала. Беренчесе — май урталарында — бәрәңге утырткан чакта. Ялтырап торган калай түбәле йортларда яшәүче ике як күршесе үз бакчаларын сукалаганда карчыкныкын да әйләндереп ташлыйлар, күмәкләшеп бәрәңгесен дә утыртып бирәләр. Билгеле, ярты бакчалык кына. Калган өлешеннән үзләре файдалана. Гаффә карчык шунысына да сөенеп бетә алмый, аңарга күпме кирәк соң? Рәхәтен күрсеннәр, карга канатыдай чем-кара җир кысыр ятмас бит инде.

Көз җиткәч тә шулай бер талпынып алалар. Үз бәрәңгеләрен алганда карчыкныкын да актарып ташлыйлар, хәтта кертеп тә бирәләр. Шуннан соң Гаффә карчык йортында тынлык урнаша. Яңгырлар башлана, салкыннар китә, җил-бураннар уйный. Шул авазларны тыңлый-тыңлый табигатьнең газиз баласы Гаффә карчык та тереклек итә. Күрше-күлән аның исән икәнлеген морҗасыннан чыккан зәгыйфь төтеннән белеп тора. Берәрсе чолан тәрәзәсеннән карчыкның кар басып китә язган өенә күз салып: «И бичара, исән икән әле, җанын ничек саклый диген»,— дип уфтанып куя, аннан кабат бетмәс-төкәнмәс эшләренә тотына.

Кайчакта Гаффә карчыкның колагына ниндидер тук тавышлар, җыр, музыка, көлү авазлары ишетелә. Иртәгесен аның янына, тастымал белән капланган тәлинкә тотып, күрше хатыны килеп керә, кунаклардан арткан бәлеш кисәкләрен өстәлгә куя да карчыкның тормышына хәйран калып бераз утыргач чыгып китә. Күршесен озаткач, Гаффә карчык, рәхмәтләр укый-укый, каткан бәлеш төпләрен чәендә җебетә, тансык, онытылып беткән ризыклар белән тамагын туйдыра. Ләкин мондый көннәр ел әйләнәсендә ике-өчтән артмый.

Авылның башка хатыннары да әллә нигә бер карчык янына сугылып чыккалыйлар. Ирләреннән калышмаска тырышып тормыш куучы ул хатыннар, бу ашкыну, барысына да өлгерергә, җитешергә тырышулар берәр фаҗига-мазар китереп чыгара күрмәсен тагын дип, садака итеп карчыкка аз-маз чәй-шикәр, берәр сабын яисә арзанлы яулык китергәлиләр. Шулай итеп, эчләрен тырнаган шик-шөбһәләрдән арынырга тырышалар, кайдалыгы билгеле булмаган иләһи көчләрдән мәрхәмәтлелек, гөнаһларын ярлыкау өмет итәләр. Ләкин ул хатыннар да карчык янына онытылганда бер — үзләренә

кирәктә генә керә. Шулай да андый көннәр, ялан кыр уртасында утырган ялгыз агач кебек, карчыкның хәтерендә уелып кала, ул аларга кабат-кабат әйләнеп кайта, кеше тавышы ишеткән көнне озак вакыт күңелендә саклый.

Атналар, айлар үтә, суыгы сөякләргә генә түгел, җанга хәтле үтеп кергән кыш, ниһаять, язга авыша. Түбә кырыйларында боз сөңгеләре күренә, тып-тып тамчы тама, яз килүгә сөенешеп, койма башларында чыпчыклар чыркылдаша. Яз сулышы сизелү белән, гомеренең чутын югалткан Гаффә карчык күңелендә дә ниндидер үзгәреш булгандай тоела. Ул тәрәзә янына ешрак килә, җемелдәгән карларга яшьләнгән күзләре белән озак итеп карап тора. Җылыга тилмергән бу дөньяга тиздән күяшлы көннәр киләчәген уйлый карчык, ул көннәр бәлки аның да җанын җылытыр, күңеленә якын авазлар ишетелер, бала-чаганың риясыз йөзен күрер.

тәгаен — анык, ачык
янтаю — читкә, янга авышу
алабута — чүп үләне
мәшәкать — борчылу, борчулы эш
сума — акча
җәйрәп — җәелеп
кысыр — утыртылмый, чәчелми калган
илаһи — серле, тылсымлы
чыркылдау —кычкыру, чырылдау
ниргә —нигез (фундамент)
болдыр — өйалды баскычы
җөпләү — хуплау
төбәлү — төпләнү
нәүмиз — күңелсез, боек
тереклек итә — яши
ярлыкау — гафу итү, аклау, кичерү
риясыз — эчкерсез, тугрылыклы, ихлас күңелле

Сораулар һәм бирем

1. Хәзерге авыл күренешен, авыл халкы тормышын, матди байлыгын Гаффә әбинең хәле белән чагыштырып сурәтләгез.

2. Өлкән яшьтәге әбинең үз эченә бикләнүенә, кешеләр белән аралашмавына нәрсәләр сәбәп булгандыр дип уйлыйсыз?
3. Соңгы елларда кешеләрдә мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек кебек матур сыйфатларның кимүенә китергән сәбәпләрдән кайсыларын аерып күрсәтә аласыз?

Җәйгә чыккач, карчыкның тормышында бер кечкенә вакыйга да булып алды. Каршы йорттан аңа дүрт яшьләрендәге бер сабый кереп йөри башлады. Гаффә карчык аны аркасыннан сөеп кенә тора, садакага килгән әйберләрен саклап тотып, малайны сыйлый, сөтле чәй эчерә һәм аның белән күңеле булганчы сөйләшә иде. Бала аңа тиз ияләште, урамга чыкты исә, карчыкның капкасын төртеп ачып, шундук кереп тә җитә. Әмма бу куаныч та озакка бармады. Беркөнне малайның анасы килеп керде дә баланы җилтерәтеп алып чыгып та китте. Шуннан бирле сабыйның күренгәне юк.

Бу хәлдән соң бер-ике атна үткәч, күрше кызыннан хат яздырып, аны почтага илтергә барган иде карчык. Бик мөһим, кадерле хат иде шул. Зур өметләр баглап яздырды аны Гаффә карчык, шуңа күрә почта әрҗәсенә үз кулы белән саласы килде. Гөнаһ шомлыгына күрә, йорт ишегенә йозак элеп киткән иде. Кайдадыр юлда ачкычын төшереп калдырган. Кайткач ишеген ача алмады. Тагын мәшәкать ясыйм дип, күршеләргә әйтергә дә яхшысынмады. Ярый әле янтайган якның тәрәзәсе ябылып бетми, өйгә шуннан керде. Шул көннән, аяк астына иске әрҗә куеп, тәрәзәдән йөри башлады. Күп тә үтми, Гаффә карчыкның мүкәләп тәрәзәдән кереп баруын чолан тәрәзәсеннән күрше хатыны күреп алды, гадәттәгечә, уфтанып: «И Ходаем, дөньялыгы бер дә калмаган, инде тәрәзәдән йөри башлаган»,— дип куйды. Өйгә кергәч, бу турыда ашап утырган иренә дә әйтте. Анысы тәлинкәдән башын күтәреп: «Ничек эләгеп тора диген... Өзелсә, ичмасам, малайны башка чыгарырга урын булыр иде... Мин хуҗа белән сөйләштем»,— дип җавап бирде.

Беркөнне көтү каршыларга дип капка төбенә чыгып баскан хатыннар Гаффә карчыкның кычытканга күмелеп утыр-

ган өеннән төтен чыгуын күреп алдылар. Шундук шау-шу купты: «Янгын! Янгын! Гаффәттәй яна!» — дип, карчыкның өенә таба йөгерделәр. Тавышка ирләр дә килеп җитте. Өй тулы төтен, ә ишектә йозак.

— Үзе кая соң, үзе? — дип кычкырды кемдер.

— Эчтәдер, тәрәзәдән йөри ул,— дигән җавап ишетелде. Сүз озайтып тормыйча, кемдер тәрәзәдән эчкә ташланды. Икенче берәү ишеккә китереп типте, атылып киткән йозак артыннан үзе дә төтен эченә кереп югалды. Эчтән ниндидер ыгы-зыгы, ауган әйбер тавышлары ишетелде. Аннан, ютәллиютәлли, керүчеләр кире атылып чыктылар.

— Юк ул анда,— диде беренчесе һәм кабат буылып ютәлләргә кереште.

— Карават асларына хәтле карадым, беркая юк,—диде икенчесе.

— Шунда инде, шунда, кая булсын! — диде кемдер. Ул арада хатын-кызлар су ташырга тотындылар. Ирләр исә умырып ташланган тәрәзәләр аша килгән бер чиләкне өй эченә тондыра торалар, кайберсе кереп үк сибә. Эчтән бөркелеп-бөркелеп әче төтен чыга, пар күтәрелә, тик ялкын инде күренми, чөнки ут карчыкның иске-москысына капкан, стеналарга үрләргә өлгермәгән иде. Кинәт өй эченнән:

— Монда! Монда ул! — дип кычкырдылар.

Берничә ир тагын өй эченә кереп китте. Күз ачып йомганчы карчыкны күтәреп тә чыктылар. Тереме, үлеме — беркем белми. Койма буена куймакчылар иде, кемдер каршы килде:

— Юк, юк, әнә бакчага кертеп салыгыз, һавада ятсын,— диде.

Карчыкны бакчага керттеләр, астына юрганын җәеп, әрекмәннәр арасына салдылар. Кайберәүләр әле һаман пыскып яткан әйберләр өстенә су коя, җиренә җиткереп сүндерә иде.

Бераздан бу эш тә тәмамланды, тик берәүнең дә таралասы килми, сүндергәндә булган кызык мизгелләрне искә төшереп, көлешә-көлешә сөйләшеп торалар.

Ирләрдән берсе:

— Ыңгырашкан тавышка борылып карасам, ята мич башында, мин сиңа әйтим...— дип, карчыкны ничек табып алуы турында сөйли.

Икенчесе:

— Бирсә дә бирер икән Ходай гомерне, билләһи... Ярый әле көне җилле түгел, бөтен авылың белән янып бетәрсең, җүләр,— дип башын чайкап куя.

Өченчесе аның сүзен җөпли:

— Әйе... Йортлар кысан урнашкан, бер дөрләп китсә, Алла сакласын...— ди.

Ул арада, сумкасын асып, фельдшер кыз да йөгереп килеп җитә. Аны бакчага алып керәләр. Кыз, карчык янына тезләнеп, күкрәген тыңларга тотына. Аннан башын чак кагып:

— Йөрәге тибә. Срочно больницага илтергә кирәк. Кем илтә? — ди, башын күтәреп, өмет белән, җыелган халыкка карый.

Берәү дә дәшми. Шунда кыз карчыкның күршесе Гыйниятне күреп ала.

— Гыйният абый, сезнең машина бар түгелме соң, илтеп куйыйк,— дип үтенә.

Гыйният бер урында таптанып ала.

— Худта түгел шул, аккумуляторларын сүтеп куйган идем,— ди, карашын читкә ала.

Аның иртәнге поездда офицер кияве белән кызын каршылыйсы бар, шуңа күрә бүген машинасын карап, утыргычларга җәелгән паласларны кагып куйган иде. Янгыннан калган карчыкны машинаның чиста салонына кертәсе килми.

— Алайса табып китерегез берәр нәрсә, болай ятмас бит инде! — дип, тавышын күтәрә төшеп әйтеп сала кыз, аннан кырысланып калган йөз белән бер ноктага төбәлеп тора.

Арадан бер егет ашыгып чыгып китә. Авыр тынлык урнаша. Җыелган халык карчыкның тузгыган чәчләренә, йомылган күзенә, көл төсле йөзенә төбәлеп басып тора. Барысының да моннан тизрәк китәсе, бу уңайсызлыктан котыласы килә.

Шулвакыт кайтып килүче көтү тавышы ишетелеп куя. Команда ишетелгәндәй, халык таралыша башлый. Кыз кабат карчыкның сөякчел кулына үрелә, пульсын тикшереп карый.

— Әйдәгез, капка төбенә алып чыгыйк,— ди ул һәм аягына торып баса.

Ирләр карчыкны саклык белән генә күтәреп алалар, капка төбенә алып чыгалар. Җиргә куйганда, тере әле мин дигәндәй, карчык ыңгырашып куя. Бу барысын да сискәндереп җибәрә.

Күп тә үтми, яннарына арбалы трактор килеп туктый. Арбадан баягы егет сикереп төшә.

— Башка нәрсә тапмадым. Әнә арба төбенә үлән җәйдек,— ди һәм бортларны ачарга керешә.

Карчыкны яшел үлән өстенә менгереп салалар. Фельдшер кыз, ярдәмгә ике егет арбага менеп утыралар, трактор кузгалып китә.

Халык җиңел сулап куя. Трактор күздән югалгач, таралып яткан йортка тагын бер борылып карыйлар да өйләренә тараlалар. Анда аларны моның ише нәрсәләрне тиз оныттыра торган таза тормыш, кайнар аш, телевизор, йомшак урын көтә.

Гаффә карчык иртән кояш чыкканчыга хәтле аңына килә алмады. Шул килеш өзелеп тә китте. Өзелгәндә йөзе тыныч, анда хискә охшаган бер нәрсә дә күренмәде. Тик иң соңгы мизгелдә генә, нәрсәдер әйтәсе килгәндәй, маңгаенда бер җыерчык артты, аннан соң, «Әй, кемгә кирәк...» дигәндәй, шундук юкка да чыкты. Моны карчыкның яныннан китми төн уздырган фельдшер кыз гына күреп калды.

Ул иртәне кояш сүлпән күтәрелде, нәрсәдәндер күңеле бизгәндәй, байтак вакыт болыт арасыннан читен генә күрсәтеп торды, гүя җәйрәп яткан авыл өстенә күз ташлап: «Эх кешеләр! Бер-береңнең кадерен дә белмәгәч, нинди максатлар өчен тырмашасыз?» — дип, шелтә белән сорый кебек иде.

садака — мохтаҗларга, гарипләргә, өлкән яшьтәге кешеләргә бирелә торган хәер
мүкәләп — тизләр һәм куллар ярдәмендә дүрт аяклап хәрәкәтләнү
уфтану — үкенү, үкенеп борчылу
дөньялык — чын тормыш
әрекмән — зур, киң, салынкы яфраклы үсемлек
сискәнү — кинәт булган борчу (курку һ.б.) тойгысыннан яки кичерешеннән кискен калтыранып кую
сүлпән — бик әкрен, бик басынкы, кыюсыз

Сораулар һәм бирем

1. Күрше хатынының дүрт яшьлек улын Гаффә әбисе янына керүдән тыюы сезгә ничек тәэсир итте?
2. Ачкычын югалткан Гаффә әбинең тәрәзәдән кереп-чыгып йөрүен күршеләре күп тапкырлар күрсәләр дә, аңа ярдәм кулы сузарга теләмиләр. Бу аяныч хәлне сез ничек бәялисез?
3. Матди яктан мул тормышта, яхшы шартларда яшәүче күршеләренең шәфкатьсезлегенә хикәядән мисаллар китерегез.
4. Гаффә әби хәсрәтенә битараф булмаган фельдшер кызга, аны больницага илтү өчен арбалы трактор алып килгән егеткә, янгынны сүндерүдә катнашкан авыл кешеләренә сезнең карашыгыз нинди?
5. Сезгә кешеләрдәге нинди сыйфатлар ошый, кайсылары ошамый? Өлкән яшьтәге кешеләргә тиешле игътибар, ярдәм күрсәтәсезме?

ЭЧТӘЛЕК

Татар халык авыз иҗаты 4
Әкиятләр турында 4
Зирәк карт 5
Җил арба 10
Мәкальләр турында 16
Әйтемнәр турында 18
Табышмаклар турында 19
Әкият-табышмаклар 20
Тизәйткечләр турында 21
Шарадалар турында 23
Габдулла Тукай 25
Тукай нигезләре. *Сибгат Хәким* 25
Эшкә өндәү 27
Сабыйга 28
Эш беткәч уйнарга ярый 29
Су анасы 32
Әнвәр Бакиров 35
Садри Ахунов 38
Тукай һәйкәле. *Мәхмүт Хөсәен* 39
Әхмәт Фәйзи 41
Тукай 42
Нәҗип Думави 56
Айлы төн 57
Син — кеше! 58
Нәкый Исәнбәт 60
Туган ил 62
Син сазыңны уйнадың 63
Гаяз Исхакый 65
Кәҗүл читек 67
Мәҗит Гафури 79
Гөлләр бакчасында 80
Кыр казы 82
Галимҗан Ибраһимов 93
Яз башы 94

Дәрҗия Аппакова 107
Йолдызкай 108
Шыгырдавыклы башмаклар 110
Гөлсем Сөләйманова 114
Фатих Кәрим 116
Гармунчы Аю белән җырчы Маймыл 117
Үлем уены 126
Абдулла Алиш 135
Сертотмас үрдәк 136
Чуар тавык 142
Фатих Хөсни 153
Малай белән солдат 154
Сөйләнмәгән хикәя 158
Нәби Дәүли 164
Бәхет кайда була? 165
Кар нинди җылы... 168
Нури Арсланов 175
Казан 176
Гасырлар тирәнлегеннән. *Гамирҗан Дәүләтшин* 178
Нинди ул Татарстан? *Гомәр Бәширов* 181
Сажидә Сөләйманова 184
Кайный, шаулый Казан урамнары 185
Шәүкәт Галиев 187
Алтын куллар 188
Хәзинә 189
Телләр белүче каләм 190
Магнитофон онытмый 191
Саумысыз, арышларым! 192
Рабит Батулла 194
Дуслар дус булып кала 195
Фәнис Яруллин 200
Анам теле 201
Кояштагы тап 202
Шамил Маннапов 206
Мин гармунга ничек өйрәндем 207
Солтан Шәмси 212
Табигатьнең газиз баласы 213

Учебное издание

Исламов Фанис Фатхылович
Закирзянов Альфат Магсумзянович

ТАТАРСКАЯ ЛИТЕРАТУРА

Учебник для 5 класса
средней общеобразовательной школы
с русским языком обучения
(для учащихся-татар)

Казань. Издательство «Магариф». 2004

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Исламов Фәнис Фәтхылович
Закирҗанов Әлфәт Мәгъсүмҗанович

ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең
5 нче сыйныфы өчен дәреслек
(татар балалары өчен)

Редакция мөдире *Р. И. Раскулова*
Редакторлары *Х. Г. Фәйзрахманова, Р. И. Раскулова*
Тышлык рәссамы һәм бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Дәреслектә *Ю. Б. Лысогорский, Л. Ә. Фәттахов* һәм *Ф. Г. Әминов*
рәсемнәре файдаланылды
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Л. Г. Зиргизова*
Корректорлары *Р. Ә. Фәйзуллина, Т. Н. Сәгъдуллина*

Басарга кул куелды 13.07.04. Форматы $60 \times 90^1/_{16}$.
Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма
табагы 14,0 + форз. 0,25. Нәшер-хисап табагы 11,06 + форз. 0,37.
Тиражы 23 000 д. Заказ К 4/109.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.

Фәйзерахман Әминов. Шүрәле.